Безнең МИРАС

07
июль 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

23 июньдә Болгар тарих-археология комплексы, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының Доха шәһәрендә (Катар дәүләте) узган 38 нче сессиясе карары белән, Бөтендөнья мирасы исемлегенә 1002 нче объект булып кертелде.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең Мирас 12 +
07(30)
июнь 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

4

ЭЧТӘЛЕК

28 **МИЛЛӘТНЕ КАЙГЫРТУЧЫ КИЛЕН.** *Хәмзә Бәдретдинов*

80 **СӨЙКЕМЛЕ СӨЯКЛЕ ФИРДӘВЕС.** *Әзһәр Шакиров*

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ
3 **Кадерлебез — мирас**

ТАРИХИ МИРАС
4 **Мең еллар элек...** *Әзһәр Мөхәммәдиев*
11 **Яңа төрек дәүләте уңчылары.** *Йосыф Акчура*
14 **Ататөрек мәктүбе.** *Әлфинә Сибгатуллина*
18 **Тарихи ташъязмалар белгече.** *Ирек Һадиев*
22 **Болгар-татар эпиграфикасында антропонимнар.** *Һарун Йосыпов*

ХӘТЕР САГЫНДА
28 **Милләтне кайгыртучы килен.** *Хәмзә Бәдретдинов*

КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛДА МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ
39 **Айшә ханым.** *Усеин Болатуков*

ҖИҢҮ — 70!
46 **Хатлар яздым утырып...**

ӘДӘБИ МИРАС
48 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
54 **Асыл шигырь югалмас!** *Әнвәр Шәрипов*
62 **«Ана күңеле дә ирешмәслек еракларга китеп барышым...»** *Рөстәм Акъегет*

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ
72 **Ташкыннардай ташкан еллар...** *Әхтәм Зарипов*

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ
74 **Заман утлары**
79 **«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы нигезнамәсе**

СӘНГАТИ МИРАС
80 **Сөйкемле сөякле Фирдәвес.** *Әзһәр Шакиров*

Баш мөхәррир —
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Марат Закир
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре:
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор —
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр —
Данил Салихов
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

86 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*
90 **Юлларыбызга изге капкалар ачылсын!** *Фирдәвес Гарипова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

96 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның июль ае.** *Ленар Гобәйдуллин*
101 **«Шура» журналыннан — мәзәкләр.** *Рәйсә Шәрәфиева*

ШАЯН МИРАС

112 **«Тынгысыз каләм» битләреннән...**

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

108 **Феномен.** *Расиха Фәизова*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

111 **Афәрин, «Идел»!**

МИРАС ҺӘМ ВАРИС

117 **Юрист киңәше**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы. Июль**

Заказ №А-1794. **Тираж** — 1507 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 3.07.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда З.Бәширов, Р.Якупов, Л.Гобәйдуллин төшергән һәм авторлар, «Мәдәни җомга» газетасы архивыннан алынган фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә — «Камка», 2011. Киндер, майлы буяу.
И.Мусин рәсеме

КАДЕРЛЕБЕЗ – МИРАС

Мөхтәрәм милләттәшләр, газиз кардәшләр!

Сезнең кулда — «Безнең мирас»ның яңа саны. Шөкер, кайбер җитди авырлыклар булуга карамастан, журналыбыз бер-бер артлы чыга тора, укучыларыбыз, ягъни абунәчеләребез, бөртекләп-бөртекләп булса да, арта бара. Ошбу урында, форсаттан файдаланып, «Безнең мирас»ны дус-юлдаш иткән, журналыбызга теләктәш һәм хәерхаһ булган барча абунәчеләребезгә, басмабызны чыгаруда хәл кадәри ярдәм иткән фидакяр затларыбызга зур рәхмәтләремне ирештерәм.

Шушы катмарлы, катлаулы заманда, күпләребез матди кыенлыкларга дучар булып яшәгән бер мәлдә, сезнең, хөрмәтле укучылар, журналыбызны үз итүегез — безнең өчен олы куаныч, зур мәртәбә.

Кадерле дуслар!

Сез, иншаллаһ, «Безнең мирас» белән озын-озак еллар бергә, һәрвакыт дустанә һәм эшлекле мөнәсәбәттә булырсыз, дип уйлыйм. Бай мирасыбызны, кадерле вә кыйммәтле ядкярләребезне барлауда, аларны басмабыз аша яктыртуда Сез һәрчак актив эшчәнлек күрсәтерсез, дип ышанам.

Әйткәнемчә:

Татар иле — безнең мирас бит ул,
Безнең мирас — барыбызныкы!
Синеке дә, минеке дә, димәк,
Безнең мирас — бары безнеке!

Әйе, безнең мирас — чит-ятныкы түгел, бары безнеке. Кадерен белик, кадерлик без аны!



МЕҢ ЕЛЛАР ЭЛЕК...

Әзһәр Мөхәммәдиев

Эжен Делакруа. «Аттила» фрескасыннан фрагмент. 1840 еллар тирәсе

Курганнарда табылган алтын-көмеш савытлардагы, балдаклардагы һәм тәңкәләрдәге антик чор һәм яңа дәвер язмалары.

Үзем мөэмин вә мөслим,
Әмма асылым кыпчак.
Бәркә Фәкыйһ (XIV йөз)

КЫПЧАК ТЕЛЕНДӘГЕ БОРЫНГЫ ЯЗМАЛАР

Һәрбер халыкның үз язма культурасы барлыкка килүе зур казанышлардан санала. Мисал өчен, узган гасыр урталарында Мәскәү археологлары X йөзгә караган рус торлагында «горухча» дигән бер сүз язылган чүлмәк тапкан иде. Әлеге сүзнең мәгънәсе бик үк аңлашылып бетмәсә дә, ул турыда нинди генә галимнәр горурланып язып чыкмагандыр.

Бераз гына соңрак исә Мәскәү университеты профессоры В.В.Янин җитәкчелегендә археологлар Новгород шәһәренең урта гасырларга караган ташландык урыннарында казу эшләре башкарды. Казу эшләре нәтиҗәсендә, очланган сөяк белән сыдырып язылган, бөгәрләнеп каткан күп санлы туз кисәкләре тапканнар. В.В.Янин әлеге язуларны химик матдәләр белән эшкәртеп, өйрәнеп һәм укып, саллы китаплар да бастырып чыгарды. Аңа шул хезмәтләре өчен академик исеме бирделәр...

Ошбу мәкаләдә сүз укучыларга таныш булган рун тамгалары турында түгел, ә ике мең елдан да элегрәк, ягъни б.э.к. III йөзләрдә барлыкка килгән гаҗәеп язма мәдәниятебез турында барачак. Бактриядән алып, заманында «Кыпчак уйсулыгы» дип аталган Идел-Чулман буйларын үз эченә алган, борынгы Пиерим (Бием) җирләренә кадәр таралган кыпчак телле күп санлы язмалар турында кеше ышанмаслык арттыру да, хата да юк... Мондый язмалар Босхар династиясеннән чыккан патшаларның һәм патшабикәләрнең курганнарында табылган алтын балдакларда, алкаларда, алтын-көмеш яки җиз савыт-сабаларда, бигрәк тә ислам кабул иткәнгә кадәр суктырылган күп санлы көмеш тәңкәләрдә сакланган...

Шулай итеп, Идел-Чулман буйларының зур әһәмияткә ия булган үз язма культурасы б.э.к.ге чорларга барып тоташа. Бу җирләр, күрәсең, шул заманнардан бирле «Кыпчак уйсулыгы» дип аталып килгән. Мисал өчен, XI йөздә яшәгән тел галиме Мәхмүт Кашгари: *«Этил — Кыпчак уйсулыгыннан ага торган елга. Башлануы рус җирендә. Болгар диңгезенә коя»*, — дип теркәп калдырган. Кыпчак атамасы үзе исә һунчак — «һун кешесе» дигән кушма сүздән килеп чыккан булса кирәк.

Археологик материалларга караганда, әле б.э.к. һәм б.э. башларында һунннар һәм аларга союздаш угро-фин кабиләләре Байкал, Чиләбе тирәләреннән колбиләүче Кытай гаскәриләренең коточкыч ерткычлыгына чыдый алмыйча төньякка, Боз океанына таба чигенеп, Пермь, ягъни һуннар Пиерим — «Бөек җир» дип атаган җирләргә килеп урнашалар. Бу тирәләрне алар Паскатир, ягъни «Бозкаты җир», «Боз океаны буйлары» дип атаган. Әлеге территория урта гасыр Европа чыганакларында да «Паскатир» дип йөртелгән. Казан археологы В.Ф.Генинг бирегә килгән кабиләләрнең күченү юлларын һәм Пермь тирәсендәге курганнарын картага төшереп, аларны шартлы исем белән «огорлар» дип атаган иде...

Рим легионерлары да кылычны кулга тотып, ат өстендә басып яу чабар өчен ияргә тагыла торган

җайланманы — өзәңгене белмәгән яки «гладиус»[1] дип аталган кыска кылыч белән файдаланган бер заманда әлеге «огорлар» антик чор өчен күрелмәгән озын кылычлар белән коралланган булган. Байкал күле буендагы Иволгино авылы янында да б.э.к. үк утрак тормыш алып барган һуннар торлагы археологлар тарафыннан казып өйрәнелгән. Биредә чүлмәкне кул белән әвәләп түгел, ә махсус станокларда ясаганнар һәм авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгәннәр. Шул ук һун торлагын казыганда археологлар чуен кою мичләре һәм утызга якын чуеннан коелган сукабашлары да тапкан.

Һуннарның язма культуралы кавем икәнлеген дәлилләүче чәшкеләр дә шактый күп табылган. Алар еш кына уку әсбаплары булып та хезмәт иткәннәр. Чулман буенда чәшкеләрне ясый торган бер останың дистәгә якын эш кораллары һәм чималы күмелгән хәзинәсе табылуы да мәгълүм.

«Кыпчак уйсулыгы», ягъни Идел-Чулман буйлары — V йөздә Европага яу чапкан, Рим легионерларын туздырып, Европадагы коллык халәтен юк иткән Аттиланың да туган һәм идарә кылган җирләре. «Рим дәүләтен туздырган» дигән гыйбарә, әлбәттә, Рим колбиләүчелек системасын юк итүгә генә карый. Укучылар арасында, Европага барып, Римне үз күзләре белән күреп кайтучылар да бардыр... Борынгы Рим каласының капка төбендә халыклар даһие булган Аттиланың аргамакка атландырып ясалган һәйкәле, ә аның каршында исә җиргә тезләнеп, күзләрен югарыга, Аттилага таба текәп, башкала шәһәре Римне җимертмәвен, халкын үтертмәвен, талатмавын үтенеп һәм ялварып сораган Рим папасы утыра... Аттилага дошманнарының ерак оныклары тикмәгә генә һәйкәл куймаганнардыр, әлбәттә. Аның колбиләүчеләр легионнарына каршы торырлык кавалериясе дә, герман кабиләләреннән торган җәяүле гаскәре дә, стена җимертә торган катапульталары да җитәрлек булган. Ә шулай да ул, кайбер урта гасыр вәхшиләре кебек, шәһәрне яндыртмаган, җимертмәгән, халкын талатмаган һәм үтертмәгән бит!

Һуннар халыкларны изү, талау, газаплау, мыскыл итү, дуамалланып гаепсезгә кеше үтерү кебек колбиләүчелек гадәтен бер дә яратмаган... Аттила үзен үтерергә дип, Рим императоры тарафыннан җибәрелгән һәм үзенә тотып китерелгән бер сатлык җанны хәтта җәзага да тартмаган. Ләкин һуннарга хас нык янау белән янаган: «Әгәр дә, — дигән ул аңа, — яныңда улың булмаса, мин сине бу пычрак эшең өчен казыкка утыртып, күзләреңне кошлардан чукыттырган булыр идем, әмма улың кызганыч!» Аттила аңа штраф кына салган. Штрафка дигән алтыннарны (анысын император Аттиланы үтерергә дип биргән!) Римгә кайтып алып килгәнче дип, аның улын үз сараенда калдырып торган...

Европа халкы патшалары исә Рим колбиләүчеләреннән азат булып, иркле һун патшаларының антик чорлардан бирле килгән шанлы «киңг» — кинг (king) титулын алалар. Аның борынгы мәгънәсе «Кояш тарафыннан бар кылынган» (король) дигәнне аңлаткан[2]. Ә «киңг», ягъни корольгә буйсыну вассалитеты исә, барча халыкны акрынлап коллык системасына караганда бер-ике баскычка югарырак булган феодал бәйләнешләр системасына алып килгән... Киңг (king, король) титулын бүген дә Англиянең тәхет варислары горурланып йөртә!

---

[1] Шул сүздән «гладиатор» атамасы килеп чыккан.

[2] Безгә кояшның, чынлап та, бик борынгы заманнарда, «киңг» дип әйтелүенә ышану өчен, моннан 40 мең ел чамасы элек, ягъни таш гасырда яшәп, Азиядән Америкага күченгән майя кабиләләре язмаларына игътибар итәргә туры килде.

АНТИК ЧОР КЫПЧАК ТӘҢКӘЛӘРЕ

Аттила кебек колбиләүчелеккә нәфрәт белән караган, б.э.к. II гасырда яшәгән Босхар исемле[3] һун короле мәгълүм. Ул хәзерге Әфганстан җирләренә бәреп кереп, Александр Македонский варислары — грек генераллары тарафыннан төзелгән колбиләүче Бактрия дәүләтен туздыра, юк итә, анда төрле реформалар үткәрә. Шул исәптән, беренче мәртәбә һун әлифбасы кертеп, б.э.к. 140 елларда идарә иткән Бактрия патшасы Эвкратид рәсеме урынына үз портретын ясатып, баштарак хаталы булса да, латинча язылган иске язуларны калдырып, (күрәсең, әле үз әлифбасы булмаган) тәңкәләр суктыра. Соңрак, үз портреты астына, арамей алфавиты нигезендә, кыпчак теленең ә, ү, ө, ң, җ, һ, к, г авазларына яңа билгеләр булдыра һәм исем-титулларын яздырып, өр-яңа тәңкәләр дә суктыра башлаган. Һун патшаларының «киңг» («кояш тарафыннан бар кылынган») титулы да, мөгаен, шул чорлардан башланган.

Колбиләүчелек өстенлек иткән Бактрия дәүләтен басып алып, колбиләүчеләрне туздырганнан соң, Босхар, үз бурычын үтәгән юлбашчы буларак анда калмаган, ә яудан кайтышлый ике елга арасында урнашкан бер гүзәл урынны сайлап, Хәрәзем шәһәренә нигез сала һәм үз исеменнән тәңкәләр дә суктыра башлый...

Бактриягә мондый яу чабулар бер генә мәртәбә дә булмагандыр. Босхар реформаларына кадәр үк сугылган (шул ук нәсел тамгалы!) тәңкәләр арасында өлкән яшьтәге һун патшасы рәсеме белән булганы да бар. Аның да таҗына кечкенә булса да кош рәсеме дә төшерелгән, ләкин ул вакытта әле үз әлифбасы булмаганга, күрәсең, аның исеме сугылмаган, ә бозык латин хәрефләре генә сакланган.

[3] Бүзкош (Карчыга ир).

Шунысы игътибарга лаек, Идел буенда идарә иткән Аттиланың да, аның борынгы бабасы Босхарның да (ике арада 6 гасырдан артык дәвер ятса да!) тел яки ул суктырган тәңкәләрдәге әлифба, ягъни язма культуралары гына түгел, хәтта нәсел тамырларының бер үк икәнлеген күрсәткән тамгалары (герблары) һәм титуллары да бер үк төсле!

Босхар рәсеме төшерелгән көмеш тәңкә

ИДЕЛ БУЕ КЫПЧАКЛАРЫ

Бу урында бернәрсәне ачыклап китәргә кирәк. Аттиланың үз гаскәре белән Кыпчак уйсулыгыннан шактый еракта урнашкан Римгә кадәр барып җиткәнлеге чыганаклардан мәгълүм. Ә аның ерак бабасы булган Босхар кайсы һәм нинди җирләрдән чыгып, ерак көньякта һәм буддизм киң таралган Һиндстанга якын урнашкан Бактрия биләмәләренә кадәр барып җитте икән? Идел буен эченә алган Кыпчак уйсулыгыннанмы? Әллә инде, Кытай чыганакларына карап фикер йөрткәндә, мең еллар дәвамында һун-төрки кабиләләре яшәгән Алтай буйларыннанмы? Ләкин, Алтайдагы йөзләгән таш плитәләрдә сакланган төрки (угыз) рун язмалары яки уйгыр язуы һәм әлеге безнең игътибарны җәлеп иткән һун-болгар, ягъни кыпчак алфавиты хәрефләре арасында бернинди уртаклык юк! Болай дип катгый итеп әйтү бик үк урынлы да түгелдер. Төрки (угыз) рун билгеләренең кыпчак әлифбасына караганда биш йөз ел чамасы соңрак барлыкка килүен исәпкә алганда һәм

Аттила улы Диггизих ауда. Алтын йөгертелгән һәм язулы көмеш табак: Киңкег Диггизих киссәкәю сак-сак бул Гүр тәңриг! (Королевич Диггизих чапса, сак-сак бул Гүр тәңреңнән!)

Аттиладан соң идарә иткән һәм курганнарда табылган патша һәм патшабикәләрнең алтын балдаклары

игътибар белән өйрәнгәндә, аларның күбесенә, киресенчә, кыпчак әлифбасының йогынтысы сизелә.

Озын сүзнең кыскасы: мондый әлифба беренче мәртәбә б.э.к. Бактриядә сугылган Босхар тәңкәләрендә очрый. Соңрак инде, һун-кыпчаклар төзегән Хәрәзем шәһәре тәңкәләрендә һәм Кыпчак уйсулыгында, ягъни Идел һәм Чулман буйларында табылган тәлинкәләрдә киң таралыш алган. Шуңа күрә Босхар җайдакларының да Аттила кебек үк Кыпчак уйсулыгыннан чыгып, колбиләүчеләр дәүләте Бактрияне туздырганнан соң, бер өлеше үзләре нигез салган Хәрәземдә калып, ә бер өлеше исә, йөзләгән алтын, җиз һәм көмеш тәлинкәләргә язылган язуларны (индуизм уку әсбапларын) алып, үз туган җирләренә әйләнеп кайтканнардыр, дип уйларга кирәк.

«Хәрәзем» атамасының килеп чыгышын Мирфатыйх Зәкиев һун теле белән бәйләп, Һуарасм, ягъни «ике су арасы», дип аңлаткан иде. Урта гасыр чыганакларында ул, чынлап та, шулай дип атала. Игътибар итсәгез, бу сүз алда телгә алынган һуннарның, Чиләбе тирәләреннән төньякка таба килеп, беренче урнашкан биләмәләре Пермь (Биерим — «Бөек җир») яки Паскатир («Бозкаты җир» — «Боз океаны») кебек үк таныш атама...

Шулай итеп, кыпчак телле Хәрәземнең барлыкка килүе һәм үсеше, күрәсең, Кыпчак уйсулыгының акрынлап көчәюе һәм халкының көньякка Хәрәземгә таба күченүе белән турыдантуры бәйләнгән.

Әлеге ике өлкәнең дә бердәм рәвештә үсешенең үз сәбәпләре булган, әлбәттә. Иран яки Һиндстан кебек үз чоры өчен алга киткән илләр белән күрше булган Хәрәземдә Босхардан соң идарә иткән «корольләр» б.э. башларыннан алып, VIII йөз башында ислам кабул иткәнгә кадәр, һәркайсы үз әлифбалары нигезендә һәм үз исемнәреннән меңләгән тәңкә суктырган.

Кызганыч ки, гасырлар дәвамында суктырылып килгән күп санлы кыпчак телле тәңкәләр, аларның язулары безнең тырышлык белән фәкать хәзерге заманда гына «телгә килде» һәм үз серләрен ача башлады...




Болгар короле Кубратның алтын балдагы

ДИНИ ЯЗМАЛАР

Болгар-татар телендәге моңа кадәр беркем дә укый алмаган язулы дистәдән артык тәлинкәләр, борынгы Бактрия дәүләтенең Кыпчак уйсулыгы һәм бигрәк тә Паскатир (Идел-Чулман буе) белән тыгыз бәйләнеше булганлыгына ышанычлы дәлил булып тора.

Хикмәт шунда ки, аерым шәхесләргә багышланган текстларны искә алмаганда, кыпчак язмаларының кайберләре ислам кабул иткәнгә кадәр яшәп килгән буддизм белән бәйле. Ягъни безнең ерак бабаларыбыз Бактрияне тар-мар иткәннән соң, Һиндстаннан буддизм тәгълиматын да өйрәнеп кайта. Шунлыктан кыпчак әлифбасына нигезләнгән язмаларны уку һәм аңлау өчен, башта буддизмны, аның тарихын һәм катлаулы йолаларын гына түгел, ә аның кыпчак телендәге атамаларын да белергә кирәк.

Дини язмалар шәхси текстларга караганда шактый катлаулырак булуга карамастан, шул ук кыпчак телендә язылганлыгын укучыларга да аңлатыр өчен, бер тәлинкәдәге Борһан (Будда) исеме белән бәйләнгән язманың башлангыч сүзләрен генә укып күрсәтәм: «Увкы, им Борһан коты, күрк меңизи»... Ягъни: «Укы, Будда коты (бәхете) имен (символын), күрк меңизи...(«үз кичер» — перевоплощайся)...» Язмадагы: укы, кот (котлы булсын), им (дәва, символ) кебек алтын бөртекләре кебек сакланган сүзләр, 2 мең ел элек язылган булса да, хәзер дә аңлашылып тора. Мондый язмалар исә дистәдән артык ...

Мең еллар элек, әле кәгазь булмаган бер дәвердә, төрле металл савыт-сабаларда, тәңкәләрдә сакланган мондый язмаларны горурланып, бик борынгы мәдәниятебезнең ислам индерелгәнче үк барлыкка килгән бер үрнәге итеп карарга мөмкин...

ШӘХСИ ЯЗМАЛАР

Римгә яу чапкан чагында Аттиланың



Арганда каңг – (Арганда атакайныкы)

Арһандач өгүкег (Арһандач анакайныкы)

Кыпчак уйсулыгында яшәп яткан болгар, хазар, сувар кебек һун кабиләләре белән идарә итәр өчен үзенең өлкән улы Иллекне туган иленә кайтарып җибәрергә ниятләгәнлеге язма чыганаклардан билгеле. Аттила кинәт кенә вафат булганнан соң, үзара башланып киткән ызгышларда Иллек тә һәлак була. Ул үлгәннән соң, «төп йортка» идарә итәргә дип Аттиланың уртанчы улы Диггизихнең кайтып киткәнлеге дә мәгълүм.

Аттиланың Идел-Чулман буйларында V йөздә идарә иткән улы Диггизихнең аргамакка атланган килеш озын туры кылыч белән кабан дуңгызына чапкан сюжет төшерелгән рәсеме янына: «Киңкег Диггизих киссәкәю[4], сак-сак бул Гүр тәңриг!» — дип, дошманына янап язган сүзләренә игътибар итегез. Бу юллар моннан 1600 ел чамасы элек язылган булса да, аларда болгар-татар теленә ят яки аңлашылмый торган бер генә чит сүз дә юк.

Төрле язулы тәлинкәләр Идел-Чулман буйларында гына түгел, Көнчыгыш Европада да шактый күп табылган булып чыкты, ләкин андагы язуларны, тарих өчен бик кирәкле һәм әһәмиятле булсалар да, кызганыч ки, әле моңа кадәр беркемнең дә укый алганы юк иде…

Мондый уңышсызлыкның сәбәбе кайбер хөкүмәт әһелләренең махсус указлар чыгарып, галимнәр юлына киртәләр салып куюы белән дә бәйләнгәндер. Әлеге язуларны төркитатарча укып карарга омтылучыларны «туранчылык» сәясәтендә гаепләп, йә булмаса, «антиисторическая попытка» дип авызларын «шап» итеп яптырып куялар иде…

Игътибар белән укып карасаң, антик чорлардан бирле килгән борынгы кыпчак тәңкәләрендәге «төрүг» яки «төргән» (русча әйтелештә «туран») дигән атамаларда бернинди сәясилек яки милләтчелек юк. Аны һун корольләре (киңг) тәңкәләреннән укып, фарсы тәңкәләре белән чагыштырып караганда, ул бары тик борынгы фарсы тәңкәләрендә «дәүләт» дигәнне аңлаткан һәм аңа тәңгәл килгән кыпчак атамасы гына икән…

Кызганыч, халкыбызның шундый дөньякүләм әһәмияткә ия булган борынгы антик чорлардан бирле килеп җиткән язма тарихына бернинди дә игътибар булмады диярлек. Һуннар тарихын шактый яхшы белгән Европа галимнәренең дә әлеге гаҗәеп әлифба һәм язма сәнгатьнең әһәмиятен аңлатып, үз фикерләрен әйтеп, язып чыга алганнары юк. ■

[4] Урта гасырларда кисемче — оста чабучы.

ЯҢА ТӨРЕК ДӘҮЛӘТЕ УҢЧЫЛАРЫ

Йосыф Акчура

КАВКАЗ, КЫРЫМ ҺӘМ КАЗАН ТӨРКИЛӘРЕНДӘ МИЛЛИЯТ ФИКЕРЕ

Көнбатыш төрекләрендә миллият фикеренең икенче дәвере җанланган көннәрдә, ягъни 1876-1883 елларда бу фикернең Кавказ, Кырым һәм Казанда да мәйданга чыкканын күрәбез. Бу төбәкләрдә миллият фикере билгеле сәяси, иҗтимагый, икътисади шартларның һәм Төркия, Россиядәге фикри хәрәкәт тәэсирен дә үзендә нык сиздерә.

Мин Русиянең фикри тәэсиренә караганда, Истанбулдан килгән тәэсир өстенрәк булган, дигән караштә торам. Миллият фикеренең госманлыларга якын яшәгән Кавказ, Кырым мөселманнарында, Идел буенда яшәгән төркиләргә караганда, алданрак башлануы шуны күрсәтә.

Кавказ һәм Кырымда миллият, ягъни төркичелек фикере, баштагы елларында, Истанбулдагы кебек үк, исламчылык һәм яңару фикерләре белән укмашкан хәлдә мәйданга чыга. XIX йөз урталарында иҗат иткән азәрбайҗанлы Ахунзадә Фәтх Алинең фикри һәм әдәби эшчәнлегенә тукталган идек[1]. Мирза Фәтх Али ачыктан-ачык төрек миллиятчелеге фикерен таратучылардан түгел. Бу идея аның саф төрки телдә комедияләр язуында һәм хәреф ислахы ясарга омтылуында гына чагыла.

РУСИЯДӘ БЕРЕНЧЕ ТӨРКИ ГАЗЕТА — «ИГЕНЧЕ»

Ахунзадә вафатыннан өч ел әүвәл, ягъни 1875 елда Бакуда азәрбайҗанлы Мәликзадә Хәсән бәй Зәрдәби бөтен Русиядә беренче төркичә атналык «Игенче» газетасын бастыра башлый. Хәсән бәй туган җирендә гарәпчә һәм фарсыча укыганнан соң, Тифлис гимназиясен һәм Мәскәү университетының табигать факультетын тәмамлый. Ошбу төрки газетаны Баку гимназиясендә табигать белеме укытучысы булып эшләгәндә чыгара башлый. Табигать фәннәренә бирелгәннән, газетасын да «Игенче» дип атый. Газетада җир эшләре һәм, гомумән, матди, икътисади мәсьәләләргә күп әһәмият бирә. Хәсән бәйнең миллият басуына игергә теләгән орлыклары — алгарыш, яңарыш орлыклары. 1877 елда төрек-рус сугышы башлангач, газетаны чыгару патша тарафыннан туктатыла. «Игенче»нең ике-өч еллык төпләмен күздән кичерсәк, Хәсән бәйнең, иҗтимагый, икътисади, сәяси мәсьәләләрдән бигрәк, Дарвинның галәм яшәеше нигезе итеп күрсәткән «Struggle for life» принцибына иң зур кыйммәт бирүен, милләтенә шул хакыйкатьне ныклап аңлатырга тырышуын күрәсең. Зәрдәби моны — «хәят өчен гауга» (яшәү өчен көрәш), «көчлелек өчен сугыш» дип тәрҗемә итә. Аның барлык мәкаләләрендә «дәртле рухлы була белү сугышы» дигән сүзләрне

* Дәвамы. 2014 елның 1 нче санынннан басылып килә.
[1] Чын мирас. — 2014. - №3. — Б.21-23.

«Игенче» газетасы

күпләп очратып була. Зәрдәби шул көрәштә милләтенең, аның сүзләре белән әйткәндә, мөселманнарның җиңелеп юкка чыгу хурлыгына юлыкмаска тиешлекләрен искәртә.

«Игенче» сәясәткә, сәяси вакыйгаларга бик аз кагыла. Моңа бәлки ул заманның цензура кырыслыгы мөмкинлек бирмәгәндер. Соңрак акрынакрын гына сәяси тема да җанлана башлый. Газетаның азаккы саннарындагы сәяси мәкаләләрдә беркадәр төрки миллиятчелеге сиземләнә. 1876 елгы 26 сентябрь (№14) санында төрки телләрне берләштерү мәсьәләсенә кагылган бер мәкалә урнаштырылган. «Үз телебездә» фән һәм әдәбият мәйданга китерү турында язылган икенче бер мәкалә дә шул ук санда. Соңрак та кайбер мәкаләләрендә кабат тел мәсьәләсенә туктала. Хәтта мәктәпләрдә һәм гимназияләрдә (ягъни Азәрбайҗандагы рус гимназияләрендә) ана теле (төрки тел) кертелергә тиешлеге турында сүз дә кузгалта.

Төрек-рус сугышы башланганнан соң, «Игенче»нең бу темага мөнәсәбәттә тотрыклы булмаганы сизелә. Әлеге тема кайбер саннарда байтак яктыртыла, ә кайберләрендә бөтенләй күренми диярлек. Шул мөнәсәбәт белән Хәсән бәй борчылып, газетасының хөрриятсезлегеннән зарлана. Сугыш хәлләре турындагы язмаларда госманлы төрекләренә теләктәшлек сиземләнгән җөмләләр дә юк түгел.

Беренче саннарыннан ук «Игенче» укучылары аз булудан зарлана. Кавеменең укуга һәвәссезлегеннән борчылып, укучыларына шелтә белдерә: «Әй, кардәшләр, «Игенче» — бердәнбер газета лабаса?!.» Газета чыга башлагач, алдыручылар саны 600гә җиткән. Тора-бара 283кә, ә сугыш башлангач, 200гә төшкән. Газетаның мондый шартларда яши алмаячагы табигый инде. *(«Игенче» турындагы мәгълүматлар Исмәгыйль бәй Гаспралы өендә булган коллекциядән алынды.)*

ӨНСИЗАДӘЛӘР МАТБУГАТЫ

«Игенче» тукталган елларда (1877) Закавказьенең идарә мәркәзе булган Тифлис шәһәрендә, агалы-энеле Сәед һәм Җәлал Өнсизадәләр тарафыннан бер төрки матбага оештырылып, «Зыя» («Зыя-и Кавказия») исемле атналык газета чыгарыла башлый. Сәед Өнсизадә әфәнде ул чакта Ширванда Шәмәха шәһәренең казые була. Җәлал бәк Өнсизадә — Көнчыгыш мәктәбендә һәм бер үк вакытта шәһәрнең рус мәктәбендә белем алган егет. «Зыя-и Кавказия» 18 ел дәвамында чыга. Газета чыгарылуның унынчы елында наширләр аңа кушымта рәвешендә «Кәшкүл» исемле атналык бер журнал да чыгара башлый. «Зыя-и Кавказия»нең ике нөсхәсе китапханәмдә бар. «Кәшкүл» белән күреп танышу насыйп булмады. Кулымдагы нөсхәләреннән «Зыя»ның Кавказиядә яшәгән төркиләрне дөнья хәлләре һәм төбәк хәбәрләре белән таныштырып тору теләге белән чыгарылганы аңлашыла. Мөселман һәм Госманлы илләренә кагылышлы ниндидер карашлар бу нөсхәләрдә сизелми.

«Кәшкүл» журналы исә атнага бер, 30-40 битле журнал рәвешендә биш ел чамасы дөнья күргән. Җәлал бәй Өнсизадә сүзләренә караганда, «Кәшкүл» азәри шивәсен Истанбул төрекчәсенә якынайтуны максат итеп куйган, имеш. Бу журналда азәри, чыгатай, нугай (татар) һәм госманлы шивәләрендә төркичә мәкаләләр, гарәп һәм фарсы телләрендәге язмалар басылган, имеш. Хәтта мәрхүм Әбүз-зыя Тәүфикъ бәй, ул чакта Тифлистә Иран консулы булган принц Эрфуддәүләләр дә, мәкалә язып, «Кәшкүл»гә биргәләгәннәр. Шул рәвешчә, төрле телдәге мөселман халыклары язмаларына киң урын биргәне өчен журнал наширләре бу басмага «Кәшкүл» дип исем куйганнар. Әзәри шивәсен Истанбул төрекчәсенә якынлаштыру максатын алга куйганнары өчен патша чиновниклары «Зыя» һәм «Кәшкүл» наширләрен һәм мөхәррирләрен эзәрлекләгәннәр, җавапка тарткалаганнар, дип сөйләде Җәләл бәй. Хәтта Сәед әфәнде белән Җәләл бәйнең ватаннарын ташлап китүе дә шул эзәрлекләүнең нәтиҗәсендә булган, имеш. Алар госманлылар дәүләтенә күчеп килгәннәр. Сәед әфәнде Төркиядә «Мәҗлес-и Кәбир-и мәгариф һәм «Мәҗлес-и тәдкыйкать»кә әгъза була. 1912 елда Төркиядә вафат. Җәләл бәй исә Матбугат һәм чит илләр идарәсендә, газетачылык эшендә эшләде. Соңгы елларда Әнкара матбугат идарәсендә хезмәт итте. Яшенең олылыгына да карамастан, яшьләр кебек тәртипле һәм тырыш хезмәтче иде. Ара-тирә шук, юмор шигырьләре дә язгалады. Бүген инде ул да дөньяда юк.

Минемчә, «Зыя-и Кавказия» һәм «Кәшкүл», төрки милләтпәрвәрлегеннән күбрәк, «Бөтен төреклек» (төркиләр берлеге) хәрәкәтенең бер баскычы булган «Ислам берлеге»н оештыру, тарату, саклауга хезмәт иткәнгә охшый. Шәхсән, Җәләл бәйнең миңа язган бер хатында «Кәшкүл»не бөтен мөселман илләреннән — Госманлыдан, Төньяк Кавказдан килгән төрекчә, гарәпчә, фарсыча мәкаләләр җыентыгы, дип күрсәтүе минем бу фаразым дөреслегенә дәлил була ала. Минемчә, Өнсизадәләрнең төрек милләтпәрвәрлеге белән төп бәйләнеше Исмәгыйль Гаспралының мәкаләләрен үз басмаларына урнаштыруда. Чынлап та, Исмәгыйль бәй, берничә мәкаләсен рус телендәге газеталарда, Кырымдагы ташбасмада бастырып чыгарганнан соң, Өнсизадәләр матбугатына мөрәҗәгать итә.

Шулай итеп, XIX гасыр азакларындагы «Бөтен төрки» хәрәкәтенең иң күренекле һәм атаклы шәхесләреннән Исмәгыйль бәй Гаспралы биографиясенә һәм эшчәнлегенә килеп чыгабыз.

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе* ■

АТАТӨРЕК МӘКТҮБЕ

ЗАКИР КАДЫЙРИ БИОГРАФИЯСЕНӘ КАЙБЕР ДЕТАЛЬЛӘР

Әлфинә Сибгатуллина



2013 елда күренекле дин галиме, тарихчы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Кадыйрины (1878-1854) якташлары, Самара өлкәсе татарлары, зурлап искә алды. Нәселен дәвам иттерүче И.Сәйфиев һәм Римма Вилданова галимнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктырткан, мәкаләләрен туплаган китап бастырды[1]. Римма ханым, хәтта гыйльми хезмәт язып, диссертация дә яклады[2]. Фотосурәтләр, өстәмә материаллар, биографик, библиографик белешмәләр белән баетылган әлеге китапта галимнең нәсел-нәсәбе, туган җире Абдул авылы хакында да бай мәгълүмат бирелгән.

[1] Сайфиев И., Вильданова Р. Закир Кадыйри: Возвращение к истокам. Биографический очерк. – Ульяновск, 2013.
[2] Вильданова Р.К. Закир Кадыйри (1878-1954): общественно-политическая и журналистская деятельность. Автореферат дисс. кандидата истор. наук. – Казань, 2013.

Төрле елларда газета-журналларда бастырган кайбер мәкаләләрен рус теленә тәрҗемә итеп бирүне дә бер казаныш дип санарга кирәк. Шулай да Закир Кадыйриның тормыш юлы һәм эшчәнлеге бар яктан да өйрәнелеп бетте, дип нокта куярга ерак әле. Атаклы гарәп философы Ибн Хәлдунның (1332-1406) «Мөкатдимә» әсәрен һәм башка галимнәрнең хезмәтләрен төрек теленә тәрҗемә иткән, хәдис гыйлеме, дин тарихы буенча әһәмиятле хезмәтләр язган Закир Кадыйри биографиясендә «ак тап»лар шактый күп, ә мирасы исә, гомумән, әлегә татар укучысына аз билгеле[3].

Самарада дөнья күргән әлеге китап белән танышканда, игътибарымны Закир Кадыйриның язмышындагы бер деталь җәлеп итте. Анда татар галиме белән Төркия Җөмһүриятенә нигез салучы Мостафа Кәмал Ататөрек арасында аңлашылмаучылык килеп чыгуы турында бәян ителә. Моның сәбәбе итеп, З.Кадыйринең фәнни рецензент буларак, Ататөрек тарафыннан язылган хезмәтне, аныкы икәнен белмичә тәнкыйть итүе аркасында, хөкүмәт алдында дәрәҗәсе төшүе, хәтта эшсез калуы хакында әйтелә. Соңрак Финляндиягә китәргә мәҗбүр булуы һәм Төркиягә Мостафа Кәмал үлгәч кенә кайтуы турында хәбәр ителә.

Төрекчә чыганакларны өйрәнә башлагач, Төркиядә соңгы елларда чыккан бер китап күземә чалынды. 2011 елда Истанбулда Атилла Орал дигән кеше, матбугатта сенсация ясау максаты белән, «Ататөрекнең цензураланган мәктүбе»[4] исемле кечкенә генә күләмле бер китап бастыра. Анда Ататөрекнең үз кулы белән язылган, ләкин бу көнгә кадәр билгеле булмаган, кемнәрдер тарафыннан махсус рәвештә яшереп сакланган бер хатының факсимилесы һәм хәзерге төрекчәгә күчерелгән тулы тексты бирелгән. Китапны бастырган кешенең бар игътибары Ататөрекнең автографы булган бу кыйммәтле тарихи документның кешегә күрсәтелмичә саклануы һәм соңыннан, ни өчендер, чыгарып ташлануы сәбәпләрен ачыкларга тырышуга юнәлтелгән. Безне исә бу хатның эчтәлеге турыдан-туры Закир Кадыйри Уган хакында булуы кызыксындырды. Ул күпмедер күләмдә Ататөрек һәм галим арасында булып узган хәлне ачыкларга ярдәм итә кебек тоелды.

1930 еллар башында Төркиядә яңа фәнни оешмалар барлыкка килә. Боларның иң әһәмиятлеләре арасында бүгенге көндә дә актив эшләп килүче Төрек тарих җәмгыяте бар. Ул мөһаҗир татар галимнәре дә катнашкан Төрек оҗаклары (учаклары) җәмгыятеннән үсеп чыга һәм дәүләт карамагындагы фәнни оешмага әверелә. Төрек тарих җәмгыяте алдына гаять катлаулы бурыч — рәсми төрек тарихын язу эше куела. Моның өчен башта тезислар языла, аннары шуларга нигезләнеп тарих җәмгыятенең программасы төзелә. Бер төркем галимнәр тарафыннан гомуми төрек тарихын язу эше башланып китә. 1931 елның җәенә югары сыйныф мәктәп укучылары өчен дүрт томлык тарих китабы язылып бетә, яңа уку елы башлануга басылып та чыга. Аннары башлангыч һәм урта сыйныф балаларына да дәреслекләр хәзерләнә.

Төрек җөмһүриятенең яңа гына төзелгән елларында җәмәгатьчелектә культура революциясе ясарга омтылыш күзәтелә. Моңа кадәр булган тарихка өр-яңадан ревизия ясау, «искелек калдыклары»ннан баш тарту, күп кенә

---

[3] Самаралылар бастырган китапта бирелгән биографик очерк, нигездә, моңа кадәр билгеле булганнарны «искә төшерү»гә охшый. Өстәвенә, китерелгән өземтәләрдә чыганакларның да күрсәтелмәве хезмәтнең фәнни кыйммәтен шактый төшерә. З. Кадыйриның тормыш юлы хакында бүген билгеле булган фактларның күбесе Төркиядә яшәгән тагын бер атаклы татар галиме Хәмит Зөбәер Кошай тарафыннан, 1954 елның декабрь аенда «Төрек йорды» журналында басылган мәкалә-некрологка нигезләнгән.

[4] Atilla Oral. Atatürk'ün Sansürlenmiş Mektubu. – İstanbul: Demkar Yayınevi, Haziran 2011.

мәсьәләләргә карата нигилистик караш оешу — Россия тарихы өчен дә, аеруча аның пролетариат диктатурасы чорында, гаять таныш бер күренеш. Кемализм дәвере дип аталган бу чорда төрекләрдә дә инкяр итү фәлсәфәсе күзгә күренеп киң тарала: гарәп әлфибасыннан, госманлы теленнән, хәлифәлек традицияләреннән баш тарту — бу чорга хас инкярләрнең иң өстә ятканнары гына. Мостафа Кәмал Ататөрекнең Төркияне Аурупаның алга киткән илләр арасына кертү, төрек милләтен модерн бер милләт хәленә китерү максатында күп кенә революцион үзгәрешләр ясавы һәркемгә мәгълүм. Атилла Орал тарафыннан нәшер ителгән хат та, шул катлаулы чорның бер дәлиле булып, Ататөрекнең илдә барган әлеге реформаларны турыдан-туры үзе контроль итеп торуын күрсәтә. 1931 елда яңа төрек тарихы дәреслекләрен хәзерләгәндә, ислам тарихы белән бәйле булган материалларны язу эше Закир Кадыйрига йөкләнә. Чөнки ул заманы өчен ислам дине һәм әдәбияты белгечлеге буенча иң яхшы хәзерлекле галимнәрдән хисапланган. Ләкин, кызганыч ки, эш барышында аның ислам дине турындагы карашларының революцион чор үзгәрешләре китереп чыгарган идеология белән бик үк тәңгәл килеп җитмәве ачыклана. Бу эштә Закир Кадыйриның төп «хатасы» итеп, тарихка кемалистлар теләгән «үзәктә төрек милләте торган» карашны якламыйча, «үзәктә классик ислам торган» караш ягында торуын әйтергә була.

Нәтиҗәдә, төрек тарихы буенча язылган һәр тезисны укып раслап барган Ататөрек Закир Кадыйри язганнарны бөтенләй кабул итми һәм Тарих җәмгыятенең рәисе булган профессор Тәүфик Быйыклыоглу адресына галимне сүгеп ике хат җибәрә. Менә шуның икенчесен Атилла Орал, ниндидер сәбәп белән чүплеккә эләккән җиреннән очраклы рәвештә табып алып, бастырып чыгара.

Ататөрек тарафыннан бу хат 1931 елның 16-17 августында Йалова шәһәреннән Төрек тарих җәмгыятенең югары рәислегенә атап язылган. Баш өлешендә үк бу хатның әлегә билгесез булып калучы беренче хатка постскриптум (хашия) рәвешендә язылганлыгы искәртелә. Моннан исә беренче хатның Закир Кадыйри тарафыннан эшләнгән гыйльми материалга тулы бәяләмә бирелгән төп хат булуы аңлашыла. Кызганыч, аның бүгенгә кадәр дөнья күргәне юк.

Инде басылып чыккан әлеге сенсацион мәктүбкә килик. Ул өч бит ярымнан гыйбарәт һәм анда Закир Кадыйри исеме бер генә тапкыр телгә алына. Әмма аның Мисырда атаклы Әл-Әзһар университетында укуына ишарәт итеп, яратмыйча, әче тел белән әйтелгән «Җәмигы Әзһар качкыны» гыйбарәсе биш (!) тапкыр кулланыла һәм «җаһил» (надан) кебек ямьсез сыйфатлар өстәлә[5]. «Гыйлем өлкәсендә шикләнү, Җәмигы Әзһарны бетергәннәргә ышанудан яхшырак», дип раслый Ататөрек һәм Төрек тарихын тикшерү җәмгыятенең рәисенә мондый гаеп тага: *«Җәмигы Әзһар качкынын сез таптыгыз. Әнкарадан аерылып китәсе соңгы көнне аның әсәре дип алдыма куйган үрмәкүч кебек гарәп хәрефле чүпрәк язмасына сез укый башлау белән үземнең ризасызлыгымны белдергән идем. Моны күз уңында тотачагыгызны вәгъдә иткән идегез! Сез тикшереп җибәргән материалларның Җәмигы Әзһар качкыны өлгерткән нәрсә булуын күрү белән, сезне рәнҗетмәс өчен бер сүз дәшмәдем, бу чүпрәкне яңадан анализларга мәҗбүр булдым. Бу сүзләрне сезне оялтыр өчен язмыйм. Боларны киләчәк хезмәтегездә*

[5] XX гасыр башында, гомумән, төрки-хәнәфи җәмгыятьтә Мисырда укып кайткан дин галимнәренә мөнәсәбәт сәеррәк булуы күзгә ташлана. Ататөрек хатын укыганда, Муса Бигиев хакында иске фикерле Казан татарлары арасында «Мисыр каргасы» дигән кушамат кулланылуын искә төшерик. «Чын мирас» журналында бу хакта мәкаләбез дә басылып чыккан иде: Ә. Сибгатуллина. Кадимчеләр дийарыннан бер әсәр // Чын мирас. – 2012. – №2-3.



Мостафа Кәмал Ататөрекнең хаты

игътибарлы һәм уяу булырсыз, дип язам», — ди. Хатта Ататөрекнең Закир Кадыйрига бу кадәр каты һөҗүм итүенең нигезендә аның миллиятчелек карашлары һәм гарәпләргә булган нәфрәте ап-ачык ярылып ята. Мисал өчен: исламият туган дәвердә гарәпләрнең «ком чүлендә» яшәве, ә төрекләрнең инде алга киткән, «бай мәдәни мохитләрдә» гомер итүе фикере алга сөрелә, алга таба әлеге надан һәм тәрбия күрмәгән гарәпләрнең төрекләр яшәгән җирләргә басып кереп, бар нәрсәне ватып-җимерүен, тар-мар итүләрен әйтә, исламга кадәр үк универсаль төрек мәдәниятенең гарәпләр тарафыннан урлануы хакында фикерләр белдерә.

Исламның башлангыч чорында пәйгамбәр һәм сәхабәләрнең бик гади һәм тыйнак тормыш алып барулары хакында төрле риваятьләр һәм гыйбрәтле хикәяләр биргән Закир Кадыйрины тәнкыйть итеп, мәктәп баласы өчен, ди Ататөрек, пәйгамбәрнең хәлифәсе хәзрәти Гомәрнең яланаяк, ямаулы күлмәк кигән килеш гаскәре белән Иерусалимга керүе хакындагы кыйссада, суфиларның «бер хырка, бер хөрмә» дигән аскетик фикерләре дә сабак була алмый, ди. Аның гаскәре, гарәпләрдән тыш, югарырак мәдәниятләргә ия кавемнәрдән (ягъни төрекләрдән) тора иде, ди. Хат авторының хәзрәти Гомәрне «чыплак (ялангач) һәм чыфыт» (яһүд) дип атавы да гаять эмоциональ яңгырый. Гарәпләрнең Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәлифәсе исемен йөртү «мәсхәрәсенә» ия булып, төрекләрнең исә аларның әмер һәм боерыкларына буйсынырга мәҗбүр булуына үкенеч белдерә[6].

Шулай итеп, бу хатта Закир Кадыйрига тискәре мөнәсәбәт гарәпләргә карата булган нәфрәт белән бергә килеп киткән. Төрек миллиятчелеген югары күтәрергә тырышу рухы ап-ачык сизелеп тора. Әлеге документның бүгенгә кадәр ни өчен яшереп саклануының һәм киң катлау халыкка билгеле булмавының сәбәбен, әлбәттә, бик яхшы аңларга була. Бөек лидер булган Ататөрекне яратучылар арасында күп мөселман бар, аның бу хатын укыганнан соң, аларда кирәкмәгән шик-шөбһәләр пәйда булмасын, юлбашчының ислам диненә карата карашы тискәре булган икән, дигән фикер тумасын өчен бу шулай эшләнгәндер, мөгаен. Ататөрек исә, үз чиратында, бу хатның киң җәмәгатьчелеккә ирешмәячәгенә ышанган булса кирәк, шуңа күрә үз фикер һәм хисләрен бер дә яшермичә-бизәмичә, каты һәм авыр сүзләр кулланып язган.

Бөек лидердан шундый «бәяләмә» алган Закир Кадыйрига, әлбәттә, шунда ук Төркиядә бар ишекләр ябыла, галим илдән китәргә мәҗбүр була, хәтта Финляндиядә яшәп кире кайткач та, гап-гади укытучы булып эшләргә рөхсәт ала алмый интегә... ■

[6] Halil Berktay. Sansürün sansürü // Taraf gazetesi. 21/08/2011.

ТАРИХИ ТАШЪЯЗМАЛАР БЕЛГЕЧЕ

2014 елның 22 июнендә тюрколог, этнограф, эпиграфика галиме, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты Һарун Вәлимөхәммәт улы Йосыповның тууына 100 ел тулды.

Һарун Йосыпов 1914 елда Казан шәһәрендә приказчик гаиләсендә туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң хезмәт юлын хисапчы, электромонтёр булып башлый. Бер үк вакытта, 1936-1941 елларда, Казан университетының география факультетында укый.

1942-1945 елларда Һ.В.Йосыпов Ватанны саклый — Воронеж, Сталинград янында, Курск дугасында барган иң авыр сугышларда катнаша. Авыр яралануына да карамастан, ул 1945 елның октябренә кадәр армия хезмәтендә кала.

1946-1949 елларда ул Казан уни-

верситетының этнография музее мөдире була. Аның музей тарихы, И.М.Симоновның этнографик күзәтүләре һ.б. турында язган беренче фәнни мәкаләләре шушы чорга туры килә. Ул вакытта ук Һ.В.Йосыпов үзенең төп фәнни юнәлеше булган болгар-татар эпиграфикасын өйрәнә башлый. Гарәп палеографиясен генә түгел, татар халкы телен, көнкүрешен һәм мәдәниятен бик яхшы белүе аңа кыска вакытта (1948-1952 елларда СССР ФАсенең Казан филиалында аспирант була) борынгы болгар-татар ташъязмаларын уку осталыгына ия булырга мөмкинлек бирә. Моны аның 1951-1956 елларда «Эпиграфика Востока» җыентыгында басылган, XIV-XVI йөзләрдәге болгар-татар эпиграфик ядкярләрен классификацияләгән, язуларын укып тасвирлаган һәм фәнни аңлаткан (ачыклап биргән) мәкаләләре дәлилли.

Һ.В.Йосыпов аспирантураны тәмамлап, «XIII-XVII гасыр болгар-татар эпиграфик һәйкәлләре (Казан татарларының килеп чыгуына карата)» («Булгаро-татарские эпиграфические памятники XIII—XVII вв. (к вопросу о происхождении казанских татар») дигән темага кандидатлык диссертациясен уңышлы яклаганнан соң, 1952-1958 елларда СССР ФАсенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында археологик төркем оештыра һәм Башкортстанда археологик тикшеренүләрне җитәкли. Башкортстан җирлегендәге борынгы Кормантау, Имәндәш, Табын, Касьянов, Воскресенское шәһәрлекләренең ачылышы һәм нигезле өйрәнелүе Һарун Йосыпов исеме белән турыдан-туры бәйле. Параллель рәвештә ул этнографик эшләрен дә дәвам итә, С.И.Руденко белән берлектә Башкортстан буйлап этнографик экспедицияләрдә йөри, татарларның һәм башкортларның рухи мәдәниятенә караган бай материал туплый. Хәтта махсус археологик һәм эпиграфик экспедицияләргә чыккач та этнографик, шулай ук топонимик, диалектологик күзәтүләр ясарга вакыт таба.

1958-1968 елларда Һарун Вәли улы СССР ФАсенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. 1960 елда «Болгар-татар эпиграфикасына кереш» («Введение в булгаро-татарскую эпиграфику») дигән монографиясен бастыра. Бу хезмәтендә ул Идел буе һәм Урал алдының 200дән артык эпиграфика ядкярләренең беренче фәнни җыелмасын төзи һәм аларны җентекләп классификацияли. Әлеге китапның дөнья күрүе нәтиҗәсендә, тарихчылар һәм шәркыять белгечләре ифрат әһәмиятле, әмма моңа кадәр фәнни әйләнештә булмаган ташъязма чыганаклардан, аларга бәйле лингвистик, палеографик, топонимик мәгълүматлардан файдалану мөмкинлегенә ия булды.

Һ.В.Йосыпов болгар-татар эпиграфик истәлекләрен эзләүне һәм гыйльми җәһәттән тикшерүне дәвам итә, ташъязмаларның тел һәм стиль үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Идел буеның һәм Урал янының барлык төбәкләренә диярлек оештырган дистәдән артык экспедицияләрендә ул XIII-XVI гасырга караган 600гә якын кабер ташъязмаларын таба һәм терки.

Бер үк вакытта галим этнография өлкәсендә дә эшли. Аның татар халкының рухи мәдәниятенә караган тикшеренүләре аеруча әһәмиятле.

Һарун Вәлимөхәммәт улы Йосыпов 1968 елның 26 июнендә Казанда вафат була.

1994 елда, вафатыннан соң, Һ.В.Йосыпов «Татарстан Республикасының археология картасы»н эшләүгә һәм төзүгә керткән хезмәте өчен Татарстанның Дәүләт премиясенә лаек була.

Замандашлары һәм хезмәттәшләре Һарун Йосыповны ару-талуны белмәс эшсөяр, әйбәт дус һәм иптәш, тыйнак һәм яхшы күңелле ир-егет, шул ук вакытта үзенә һәм тирәсендәгеләргә карата таләпчән кеше буларак исләрендә калдырган.

Һ.В.ЙОСЫПОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ БИБЛИОГРАФИК ИСЕМЛЕГЕ

Басылган хезмәтләре:

Юсупов Г.В. Этнографические наблюдения И.М.Симонова на островах Тихого океана / Н.И.Воробьёв, Е.П.Бусыгин, Г.В.Юсупов // Известия Всесоюзного географического общества. Том 81. – 1949. – №5. – С.497-504.

Юсупов Г.В. Булгарские эпиграфические памятники, найденные летом 1947 г. / Г.Юсупов, Г.Хисамутдинов // Эпиграфика Востока. Выпуск IV. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1951. – С.68-75: ил.

Юсупов Г.В. Татарские эпиграфические памятники XV в. (К вопросу о происхождении казанских татар) / Г.В.Юсупов // Эпиграфика Востока. Выпуск V. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1951. – С.78-94: ил.

Юсупов Г.В. Простой способ фиксации надписей / Г.В.Юсупов // Эпиграфика Востока. Выпуск V. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1951. – С.134.

Юсупов Г.В. О некоторых булгарских эпиграфических памятниках / Г.В.Юсупов // Эпиграфика Востока. Выпуск VII. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1953. – С.26-29: ил.

Юсупов Г.В. К вопросу об истории и классификации булгаро-татарской эпиграфики / Г.В.Юсупов // Эпиграфика Востока. Выпуск XI. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1956. – С.44-53: ил.



Юсупов Г.В. Две надгробные надписи с древнего башкирского кладбища / Г.В.Юсупов // Вопросы башкирской филологии: сборник / Академия наук СССР, Башкирский филиал, Институт истории, языка и литературы. – Москва: Издательство АН СССР, 1959. – С.120-122: ил.

Юсупов Г.В. Древнейшие поселения Гафурийского района БАССР / Г.В.Юсупов // Башкирский археологический сборник / Академия наук СССР, Башкирский филиал, Институт истории, языка и литературы. – Уфа, 1959. – С.58-87: план-схема.

Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В.Юсупов; ответственный редактор М.Х.Гайнуллин; Академия наук СССР, Казанский филиал. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1960. – 332 с.

Юсупов Г.В. Историко-этнографические исследования населения северо-западных районов Башкирии / Н.И.Воробьёв, Г.М.Хисамутдинов, Г.В.Юсупов // Советская этнография. – 1962. – № 6. – С.124-130.

Юсупов Г.В. Новые находки эпитафий периода Казанского ханства / Г.В.Юсупов // Эпиграфика Востока. Выпуск XVI. – Москва-Ленинград: Издательство АН СССР, 1963. – С.72-78.

Jussupov G.W. Totemistische Relikte bei den Kasaner Tataren / G.W.Jussupov // Különlenyomat a Glaubenswelt und Folklore der Sibirischen Völker Cimü Kiadvanybol. – Budapest: Akademiai Kiado, 1963. – P.209-222.

Юсупов Г.В. К вопросу о тюркской топонимике в ТАССР / Г.В.Юсупов // Тезисы аннотированных докладов на Учредительном съезде Общества истории, археологии и этнографии при КГУ. – Казань, 1964. – С.7.

Юсупов Г.В. Итоги полевых эпиграфических исследований (1961–1963 гг.) / Г.В.Юсупов // Итоговая научная сессия Казанского Института языка, литературы и истории АН СССР за 1963 год: краткое содержание докладов. – Казань, 1964. – С.69-71.

Юсупов Г.В. Антропонимы в булгаро-татарской эпиграфике / Г.В.Юсупов // Личные имена в прошлом, настоящем, будущем: Проблемы антропонимики: сборник. – Москва: Издательство «Наука», 1970. – С.248-252.

Юсупов Г.В. Булгаро-татарская эпиграфика и топонимика как источник исследования этногенеза казанских татар /Г.В.Юсупов // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / Академия наук СССР, ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова. – Казань, 1971. – С.217-231.

Юсупов Г.В. Итоги полевых эпиграфических исследований 1961-1963 гг. в Татарской АССР / Г.В.Юсупов // Эпиграфика Востока. Выпуск XXI. – Ленинград: Издательство «Наука», Ленинградское отделение, 1972. – С.48-55.

Юсупов Г. Эпиграфические памятники Атнинского района Республики Татарстан / Г.Юсупов; автор введения и примечаний М.Ахметзянов // Татарская археология. – 2005. – №2. – С.71-87.

Басылмаган хезмәтләре:

Юсупов Г.В. Эпиграфические памятники XV в. (К вопросу о происхождении казанских татар и чувашей). — 1949. — Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (г.Казань); фонд 72.

Юсупов Г.В. Отчёт по исследованию эпиграфических памятников Чишминского района БАССР летом 1953 г.: рукопись. — Институт истории, языка и литературы Уфимского научного центра Российской академии наук (г.Уфа).

Юсупов Г.В. Эпиграфические памятники западных районов БАССР: рукопись. — 1957. — Институт истории, языка и литературы Уфимского научного центра Российской академии наук (г.Уфа).

Юсупов Г.В. Отчёт об исследовании эпиграфических памятников в северо-западных Татарской АССР в 1959 г. — Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (г.Казань); фонд 72, опись 1, единица хранения 295.

Юсупов Г.В. Отчёт о работе эпиграфического отряда археологической экспедиции КФАН СССР 1961 г. в районах правобережья Волги. — 1961. — Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (г.Казань); фонд 72, опись 1, единица хранения 298.

Юсупов Г.В. Отчёт об исследовании эпиграфических памятников в закамских районах ТАССР в 1962-1963 гг. — Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (г.Казань); фонд 72, опись 1, единица хранения 296.

Юсупов Г.В. Полевой дневник № 2 эпиграфической экспедиции за 1966 г. — Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (г.Казань); фонд 72, опись 1, единица хранения 386.

Юсупов Г.В. Эпиграфические памятники Болгарского городища. — 1967. — Научный архив Института археологии Российской академии наук; фонд Р-21, единица хранения 2015.

БОЛГАР-ТАТАР ЭПИГРАФИКАСЫНДА АНТРОПОНИМНАР

Һарун Йосыпов

Болгар-татар эпитафияләре — кайсы заманга караганлыклары үзләрендә күрсәтелгән тарих, тел һәм сәнгать ядкярләре — борынгы исемнәрнең, титулларның һәм этнонимнарның да бай чыганагы. Әлеге эпитафияләр Идел-Чулман төбәге топонимикасы килеп чыгышын белүгә ачкыч булып тора.

Казан татарларында да, башка кайбер төрки халыклардагы кебек, балаларга ике исем кушу күзәтелә, мәсәлән: *Тимер-Гали, Нур-Гали, Гали-Әхмәт, Мөхәммәт-Гали, Вәли-Мөхәммәт, Гали-Баян, Дәүләт-Гәрәй* һ.б. Мондый хәл борынгы бабаларыбызның мөселманлыкка кадәрге чоры эпитафияләрендә дә чагылыш таба, мәсәлән: *Әрталиб-Шәүшәфар, Галәй-Әмәт, Биккай-Сакай*. Бер болгар эпитафиясендә хәтта өч исем дә бар: *Гафифә-Заһидә-Көбра*. Бу фактлар ислам кабул ителү белән мәҗүси исемнәрнең шунда ук юкка чыкмаганлыгын, мөселман исемнәре белән беррәттән кулланылышта булуын аңлата.

Бала тууга кендек әбисе тарафыннан кычкырып исем бирү гадәте кызыклы. Мондый исемне «кендек исеме» дип атаганнар да. Мөгаен, бу мәҗүси замандагы исем кушудан калган йоладыр. Бераз вакыттан соң балага, мулла, кунаклар чакырып, шушы уңайдан табын әзерләп, рәсми төстә исем кушылган. Кайбер очракларда баланың «кендек исеме» сакланып калган яки башка исем кушылган. Элегрәк ике исем шушы йола нигезендә барлыкка килгән булса, соңрак мулла тарафыннан ук ике исем кушу да гадәти хәлгә әйләнгән.

Битендә чуан, кутыр яки шеш булып, ул озак төзәлмәсә, баланың исемен «боза» торган булганнар. Бу очракта исемне яки бөтенләй башкасына алмаштырганнар, яки аңарга миң кисәкчәсе өстәгәннәр: *Миңзифа, Миңнехан-Миңлехан, Миңтаһир, Миңнегол, Миңлегөл* һ.б.ш. Ырым буенча, моннан соң миң юкка чыгарга тиеш дип саналган. Башлангыч чорда әлеге йоланың мең кабиләсендә кулланылган булуы бик мөмкин. Кабилә атамасының йогынтылы көч-куәте явыз көчләр җибәргән яманлыкны җиңәргә тиеш булган. Вакытлар узгач, кабиләләр таркалгач, йола гомуми кулланылыш алган. Шуңа күрә, *миң* кисәкчәсен тәндә тумыштан була торган тап-төерчек мәгънәсендә генә аңлау ялгыш булырга да мөмкин[1].

Явыз көчләрне, җен-пәриләрне алдау өчен төрле халыкларда таралган гореф-гадәт — баланы «сату» һәм «сатып алу» йоласы — казан татарларына да хас булган. Әгәр дә гаиләдә балалар үлеп бара икән, соңгы туган баланы чит кешеләр аркылы «сатарга» тәкъдим иткәннәр. Һәм ата-анасы аны «сатып алган». Бу эш тәрәзә аша башкарылган. Мондый балага исемнең дә читтән тыш көчле тәэсир итәрдәй дип уйланганын, мәгънәлесен кушканнар, мәсәлән: *Үлмәс, Тимер, Туктар, Сатый* («сатылган»нан кыскартылган), *Торсын* һ.б. Башка бер очракта баланы чүплектән алып кайткан кыяфәт ясаганнар, аның бу бәхетсез йортта тумаганлыгын явыз рух күрсен, янәсе.

[1] Смирнов А.П. Волжские болгары. — Москва, 1951. — С.66; Ефимов А.М. Могильник на Бабьем бугре // Материалы и исследования по археологии СССР. №80: Труды Куйбышевской археологической экспедиции. — Москва, 1960. — С.190; Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. — Москва, 1965. — С.154-161.

XIV гасыр, шулай ук XV—XVI гасырлар эпитафияләрендә шәхси исем урынына титуллар һәм этнонимнар куллану очраклары күзәтелә. Моның ачык чагылышына XIV гасыр болгар эпитафияләрендәге *Бәк, Әмир* һәм *Хәлфә* (мәдрәсәдәге остаз, мөгаллим мәгънәсендә) исемнәре мисал булып тора.

Болгар чорында кулланылган этнонимнардан *Ашлы, Ашыт* һәм башкаларны да күрсәтергә мөмкин. Берничә тапкыр *Мухшы* һәм XVI гасыр истәлегендә *Мухшеват* теркәлгән очраклар бар. Элекке һәм соңгырак чор болгарларының мордва-мукшылар белән археология материаллары нигезендә дә исбатланган тыгыз мөнәсәбәтләрен искә төшерсәк, Мухшы этнонимының кулланылышы ачык аңлашыла.

Кеше исеменең ләкаб-тәхәллүс белән бергә кулланылу очраклары еш күзәтелә. I өслүбкә караган болгар эпитафияләрендә ләкаб мәрхүмнең исеменнән соң килә: *Йосыф әл-Болгари.* Ләкабнең мондый гарәби шәкеле алга таба XX гасыр башларына кадәр татар руханилары һәм зыялылары катлавы өчен хас булган. II өслүб эпитафияләрендә исә ләкаб исемнең алдына куела: *Болгар Тутай* (ягъни Болгарда яшәгән, Болгарныкы булган Тутай). Бу шәкел алга таба татар халкының киң катлавына мирас булып күчә. Мисал өчен Шыңардан булган Вәли дә нәкъ шулай *Шыңар Вәли* рәвешендә, Ашыттан булган Сибгат *Ашыт Сибгат* рәвешендә кулланыла. Шушы тәртиптә шәхси исемгә кушаматлар да ияртелә: *Кәҗә Якуб, Бозау Галиулла, Әтәч Фәхри.*

XIII-XIV гасырларның болгар эпитафияләрендәге күп исемнәр турында әйтеп тә торасы юк, алар казан татарларында соңгы заманнаргача киң кулланылган. Мәсәлән: *Әбәк-Абак, Афак, Арыс, Ашан, Алмыш, Миңкә, Мәмәк, Мәчке, Кушай, Котлыг, Мәмек-Мамык, Тутай, Җөри, Турай, Түнтәр, Биктимер* һ.б. Мондый исемнәр гади кешеләрдә генә түгел, муллаларның үзләрендә дә булган[2]. Бу казан татарлары арасында болгар чорыннан ук калган исем кушу традициясенең ныклыгын күрсәтә.

Болгар эпитафияләренә хас мондый мәҗүси исемнәр топонимнарда — Татарстандагы татар авыллары атамаларында — күп тапкырлар очрый. Мәсәлән: *Мәмәт, Мамык, Ашыт, Мирҗәм, Өбрә, Талкыш, Тутай, Аппак* һ.б. Болар әлеге татар авылларының килеп чыгышы болгар чорына караганлыгын белдерә.

Шунысы игътибарга лаек, бик борынгы татар авыллары, мәсәлән, Әтрәч, Колгына һәм Адәм авыллары атамалары шушы авыл зиратларында сакланган XVI гасыр болгар эпитафияләрендәге кеше исемнәре белән туры килә. Бу фактлар шушы җирләрнең хуҗалары булган болгарларның исемнәрен һәм болгар-татар халкының дәвамчанлыгын күрсәтә. Әлеге җәһәттән тагын бер кызыклы күренеш бар: Октябрь инкыйлабына кадәр татар җәмәгатьчелегендә, аның югары катлавында болгар чорында ук оешкан, аларның бабаларының милке булган борынгы авыллар атамаларын кабатлаучы фамилияләр йөргән. Мәсәлән: *Алкиннар* — Алкино авылы, *Мәмлиевләр* — Мәмле авылы, *Апаковлар* — Аппак авылы, *Борнаевлар* — Борнай авылы һ.б. Әҗемовлар, *Аитовлар, Борнашевлар* да шушы ук төркемгә карый.

Бу урында шунысын да әйтергә кирәк: Татарстан топонимиясендә эпитафияләрдәге исемнәр типологиясе белән уртаклыклар шактый. Мәсәлән: Суламыш, Еламыш, Кармыш, Атылмыш белән Кармыш, Мамадыш, Кадыш арасында, шулай ук Тугаш, Камаш, Әгъмәш белән Кодаш, Орнаш, Кадыш арасында яки Сәүмәр белән

[2] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. II җилд. — Казан, 1900; Фәхретдин Р. Асарь. I, II җилдләр. — Оренбург, 1904.


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ

УКАЗЫ БЕЛӘН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ

Әҗмәр, Елауш белән Кушлавыч арасында һ.б.ш.

Ләкин эпитафияләрдәге антропонимнардан һәм Татарстан топонимиясеннән барлап алынганнарның иң кызыгы шул, болар — төрки ыруг-кабилә атамалары. Татарларда алар, инде күптәннән утрак тормыш алып барулары сәбәпле, онытылганнар. Кайбер тикшеренүчеләр татарларда мондый атамаларның барлыгын инкяр итәләр иде. Казан татарларының борынгы бабаларында булган, төрки халыклар өчен уртак ыруг-кабилә атамаларының төп һәм икенчел вариантлары барысы да диярлек хәзер ачыкланды. Казан шәһәренең исеме дә шушы ук атамалар төркеменә карый.

Үз заманында профессор Газиз Гобәйдуллин татарларда мондый дүрт атама барлыгын күрсәткән иде: ширин, барын, аргын, кыпчак. Хәзер ышаныч белән түбәндәгеләре дә булганлыгын әйтергә мөмкин: Кытай, Мең, Суван, Татар, Өрем, Көек, Кардәр, Табын, Ашлы, Төрекмән, Балимәр, Бүләр, Ар, Мухшы, шулай ук елъязмаларда очрый торган Берсулә, Болгар, Аскыл, Чөлмәт, Тәмтөз, Күл һәм билгеле булган Сувар. Тагын мондый этнонимнардан Тоба, Мөндеш, Теләс (Теләчә), Төркәш, Сарайлы, Кәче, Көкрат, Бәрән, Салтыган, Нократ һ.б. ачыкланды. Соңгы икесе төрекмәннәрдәге шуларга охшаш Салор һәм Нухрлы этнонимнары белән якын тора. Төрекмәннәрдәге Казанҗык безнең Казанга нәкъ шулай ук аваздаш.

Казан топонимы Казан этнонимына барып тоташа торгандыр, моны татарларда элек «Казан тау җыены» уздырылганлыгы раслый. Билгеле булганча, җыен аларга ыруг-кабилә заманнарыннан ук мирас булып калган[3].

Казанка, Казанская топонимнары Кубаньда, Украинаның көньягында, Каспий диңгезенең төньяк-көнбатыш ярларында киң таралыш алган. Төркиянең төньяк-көнчыгышында Казан дигән шәһәр бар, ул — бирегә сәлҗуклар белән килгән төрекмәннәрнең үзәге. Кара диңгезнең төньяк яр буйларына һәм Азов диңгезе буйларына казан кабиләсенең Төрекмәнстан җирлегеннән килгән булуы бик мөмкин, ул төрекмәннәрнең шәҗәрәсендә Казан-Салор буларак гәүдәләнгән. Урта Иделгә исә ул Азов буйларыннан болгар кабиләләре рәтендә килгән һәм Болгар дәүләте составында алга таба аерым кенәзлек оештырган. «Казан кенәзлеге»нең тарихта булганлыгын Н.Ф.Калинин исбатлады[4].

«Личные имена в прошлом, настоящем, будущем» китабыннан (Мәскәү: «Наука» нәшрияты, 1970) алынып тәрҗемә ителде.

Биографик мәкаләне, фәнни хезмәтләрнең библиографик исемлеген һәм Һ.В.Йосыповның үз мәкаләсен журнал өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары ***Ирек Һадиев*** *әзерләде.*

[3] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. — Москва: Наука, 1967. — С.198-199.

[4] Калинин Н.Ф. Булгарская перстневая печать XIV века в фондах музея: Доклад на Краеведческих чтениях 1955 года / Редактор Х.Г.Гимади. — Казань: Издательство Государственного музея ТАССР, 1956. — С.17.

НУРЛЫ ЙӨЗЛЕ ГАИЛӘ

1919 елда төшерелгән бу фоторәсемдә минем газиз туганнарым сурәтләнгән: әбием Мәүгузә, бабам Вәлимөхәммәт, басып торганнары — әнием Рокыя (башына калфак кигән), Һарун абыем, туп кочаклаганы — Суфия апам, әбинең итәгендә утырганы — Асия (ул нәни чагында вафат була). Соңрак Мансур абый белән Галия апа дөньяга килгән.

Әнием гаиләдә иң олысы була, мин дә — әниемнең олы кызы, Казандагы Каюм Насыйри урамындагы әби-бабам йортында үстем. Аларда торып, балалар бакчасына, мәктәпкә йөрдем. Әти-әни көне буе эштә, ә без туганнан-туганым Илгиз белән әби-бабайга хуҗалык эшләрендә булышабыз. Сугыш чоры балаларына эләккән бөтен нужа вә мәшәкатьләр безне дә читләтеп үтмәде. Әбиебез бик оста тегүче иде, аның бик затлы тукымалардан кием-салым тегүен хәтерлим. Безне — биш баланы да киендерде, заказга да текте. Аның гаҗәеп матур итеп бизәлгән, чигелгән калфаклары вә түбәтәйләре күз явын алырдай иде. Әби гомере буе өйдә намаз укыды, безне дә өйрәтергә тырышты. Моның өчен мин аңа аеруча рәхмәтлемен. Бабабыз Вәлимөхәммәт исә Мәрҗани мәчетенә йөрде, үтә диндар, гарәп телен вә язуын бик яхшы белә иде, улларын да өйрәтте. Олы улы Һарунның тарихчы галим булып китүендә аның да биниһая өлеше бар, дип уйлыйм. Гомумән, нурлы йөзле, иманлы гаиләдә үстек без!

Роза Йосыпова

Нәни Һарун. 1916 ел

Электрик булып эшләгән чагында. 1934 ел

КАДЕРЛЕ ХАТИРӘЛӘР

Моннан нәкъ ун ел элек — үзенең телевидениедә алып бара торган «Знай наших» сәхифәсендә, әтинең тууына 90 ел икәнен әйтеп үткәндә, туган як тарихын өйрәнүче, журналист Константин Куранов бик кызыклы чагыштыру китергән иде. Әтинең туган елы — 1914 — Беренче Бөтендөнья сугышы башланган ел. Туган көне — 22 июнь — Бөек Ватан сугышы башланган көн. Тарихчы өчен гаять символик мәгънәгә ия ләбаса бу саннар!

Революциягә кадәр әти Саба районында яшәгән. Бабай, әтинең әтисе Вәлимөхәммәт, сәүдәгәр Мусиннарда приказчик булган, аның визит карточкасы бездә бүген дә саклана. Алар җитеш тормышта яшәгән. Күмәкләштерү елларында аларны «кулак» дип, сөргенгә дә сөрә язганнар. Әмма бөтен авыл аларны яклап чыккан. Тату вә тырыш гаиләнең малына кул сузарга юл куймаганнар. Хәер,

Фронтта

районнан килгән вәкилләр дә, халык сүзенә колак салып, мәрхәмәтлелек күрсәткән.

Тора-бара гаилә калага күченә һәм алар Мәрҗани мәчете белән янәшә

Улы Василий һәм кызы Софья белән. Уфа, 1956 ел

йортта, хәзерге Каюм Насыйри урамында яши башлый. Шушы йортта балалар дөньяга килә, тора-бара алар мәктәптә белем ала. Аннары әтием электрик һөнәрен үзләштерә һәм бу белгечлегендә беркадәр вакыт эшләп тә өлгерә. Соңрак рабфакта укый, университетның география факультетына керәп, аны сугыш башланыр алдыннан тәмамлап чыга. Үзе теләп фронтка китә. Сталинград һәм Курск дугасындагы хәтәр яуларда катнаша, башы каты яраланып, госпитальгә эләгә... Шуннан соң Казанга кайтып, университетта үз кафедрасында эшли башлый. КДУның этнография музеен яңадан ачуда зур өлеш кертә. Биредә ул шулай ук география факультетын тәмамлап, кафедрада эшкә калган әнием белән таныша. Бераз вакыт узгач, алар Ленинградта очраша. Ул елларда әни ГЕОЛНЕРУДТРЕСТта эшләгән, геология экспедицияләренә йөргән. Алар 1951 елда Ленинградта өйләнешә, мин исә 1952 елда Казанда туганмын.

Казанга кайткач, әти татар халкының тарихы, аеруча этнографиясе белән ныклап кызыксына башлый. Гарәп телен яхшы белүе дә борынгы кабер ташларын өйрәнгәндә бик ярап куя. Хәер, аның фәнни эшчәнлеге хакында галимнәр үз сүзен әйтерләр. Безгә, аның балаларына, ул иң әүвәле — кадерле, газиз әти иде!

Софья Йосыпова (Хәмидуллина)

Василий Йосыпов әтисенең һәм әбисенең кабере янында. 2014 ел, 24 июнь

Һарун Йосыповның атасы Вәлимөхәммәт Низаметдин улы Йосыпов кабер ташы. 1945 ел

1. һуәл-хәййе әлләзи лә йәмүт
2. вә көлли хәййе сәйәмүт
3. Низаметдин улы
4. Вәлимөхәммәт Йосыпов
5. фани дөньядан бакый
6. ахирәткә күчте
7. рәхмәтуллаһи галәйһи
8. рәхмәтән уасигатән
9. тарих мең дә өч
10. йөз алтмыш дүртдә
11. рәҗәб аеның ун
12. ... ...

Сүзлекчә:

һуәл-хәййе әлләзи лә йәмүт вә көлли хәййе сәйәмүт — ул (Аллаһы) мәңге исән, үлми; һәр тереклек үлә

фани — вакытлы

бакый — мәңгелек

рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән уасигатән — аңа Аллаһының киң рәхмәтләре ирешсен

1364 нче һиҗри елның рәҗәб ае милади ел исәбе белән 1945 елның июнь аена туры килә.

Кабер ташының бизәлешендә борынгы татар эпиграфикасы традицияләре чагылыш тапкан. ■

МИЛЛӘТНЕ КАЙГЫРТУЧЫ КИЛЕН

Хәмзә Бәдретдинов

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ МОХИТ

Гаилә мохитенең тәэсире тиз сизелә. Пенза өлкәсе кызы Альмира, атаклы галим — Санкт-Петербург университетының Көнчыгыш факультеты профессоры, филология фәннәре докторы Габдрахман Таһирҗановның (07.02.1907-18.12.1983) улы Мөхәммәткә кияүгә чыккач, илнең Төньяк башкаласындагы үзенчәлекле татар дөньясына аяк баса. Күренекле тел белгеченең рухы ике бүлмәле фатирның һәр почмагында яшәгәнлектән, кызыксынучан килен мәрхүм каенатасының мирасы белән көн саен очраша. Тарихи фотоларны кулына алып, мәртәбәле шәхесләр белән таныша. Акыл иясенең хезмәтләрен укып, төрки халыкларның сокланырлык яшәешенә якыная. Ире Мөхәммәттән (1949) дә, гәрчә аның Иоффе исемендәге физика-техника институтын тәмамлавын, инженер булып эшләвен белсә дә, шөһрәтле татар милләте турында сораша. Каенсеңлесе Асияне (1955) дә, Көнчыгыш факультетның фарсы филологиясе кафедрасында югары белем алуын, СССР Фәннәр академиясенең этнография институтында гыйльми хезмәткәр вазифасын башкаруын белгәнгә күрә, әңгәмәгә бик еш җәлеп итә. Төп киңәшчесе исә каенанасы — дин белгече, мәгърифәтче Муса Бигиев кызы, Габдрахман Таһирҗанов хатыны Фатыйма ханым (06.08.1918-03.08.2006). Ул, күпне күргәнлектән, күпне кичергәнлектән, гаҗәеп четерекле сорауларга да шартлатып җавап бирә. Мондый яшәү шартлары, билгеле, Ленинград суыткыч сәнәгате технологиясе институтын тәмамлаучы Альмира Наим кызы Таһирҗанованы (1957) милләтпәрвәргә әйләндерә дә куя. Үзе генә түгел, улы Азат та, кызы Гөлнара да нинди нәсел дәвамчысы икәнлеген яхшы белә. «Ике бабабыз — Муса Бигиев тә, Габдрахман Таһирҗанов та даһи булган бит! — дип горурланалар оныклар. — Кызганыч, аларның берсен дә күреп калмадык. Шулай да, иҗатлары белән соңарып булса да танышабыз!»

КУЛГА АЛЫНУ КУРКЫНЫЧЫ

Их, исән чакта аларның кадерләре булмаган шул. Мәсәлән, өйдә татарча аралашуны яшәү рәвешенә әйләндерүче Габдрахман Таһирҗанов ике балалы гаиләсе белән гомерен озак еллар бер бүлмәле фатирда уздыра. Шунда телевизор сөйли. Идәндә бала-чага уйный. Китаплы-дәфтәрле өстәлгә, ашау-эчү вакыты җиткәч, ризык куела. Галим исә, боларны күрмәмешкә салышып, онытылып утыра. Укый һәм яза. Урындыктан аркасы гына күренеп тора. Билгеле, ул яшәү шартларын яхшыртырга омтылышны кат-кат ясый. Әмма яклау тапмый. Аптырагач, квартбюро хезмәткәрләренә: «Әгәр профессор булмыйча, футбол тубы типсәм,

Әфганстан падишаһы Аманулла-ханның СССРга визиты вакыты. Муса Бигиевнең сул ягында – Аманулла-хан. Ленинград. Җамигъ мәчете. 1928 ел

хоккей алкасы тәгәрәтсәм, әллә кайчан иркен фатир алыр идем инде», — дигән үзәк өзгеч сүзләрен җиткерә.

Өстәвенә, татар сантехнигы да фатирына еш сугыла. Гел милли темаларга кагылып маташа. Әмма галим, сораштыручының кемлеген чамалап, сүзне кыска тота. «Мин сиңа эшләргә комачауламыйм бит, син дә юк-бар белән башымны катырма», — дип әңгәмәне тиз өзә.

Җитмәсә, хатынының әтисе Муса Бигиевнең чит илдә яшәве дә аңа гел кара шәүлә төшереп тора. Югыйсә, ул аның остазы бит! Туган җире — Апас районының Морзалар авылында яшәгәндә, Санкт-Петербургка хат язып, рөхсәт алып, дин белгеченнән укырга килергә чакыру алучы шәкерт ул. 1925 елларда, бертуганы Абдулла, күрше Буа районындагы дусты (булачак галим) Бакый Халидов белән аның өендә гарәп теленнән дәресләр ала. Ул аның каенатасы да бит әле. Сабакка йөргәндә, кызы Фатыйма белән таныша, аның кияве була. Шушы туганлык исә дөнья таныган галимне урынсыз җәберләү корбанына әйләндерә. Кулга алыну куркынычы фән докторын гомер буе эзәрлекли. Фәкать көчле белгеч булуы, янәшәдәге хезмәткәрләрнең аның эшен тиешенчә бәяләве генә Габдрахманны зиндан кысанлыгыннан саклап кала.

Дөрес, аңа берчакны «иркенлек» вәгъдә ителә. Әмма моның өчен бер шарт куела. Остазы Муса Бигиевнең чит илдә яшәүче дусты — Төркиядәге татар профессоры Әхмәтзәки Вәлиди (1890-1970) белән элемтә урнаштырырга, ышанычка керергә, секретаре булырга, мәгълүмат алырга кушыла. Тик намуслы Габдрахман мондый түбәнлеккә төшми. Шымчылыгына вәгъдә ителүче уңайлыклардан баш тарта. Әмма үзе, әлеге тыңлаусызлыгы өчен, йокысыз төннәр кичерә. Кечкенә чемоданына кирәк-яракларын салып, кулга алырга килүчеләрне көтә. Бәхеткә, Сталин үлгәч, хәвефле көннәр артта кала.

БИГИЕВЛӘР ТОКЫМЫ

Нык хәтерле Фатыйма ханымның күңел пәрдәсе ачылгач, чит илгә китеп башын саклап калган әтисе Муса Бигиев (06.01.1873-28.10.1949) турында да маҗаралы кыйсса җанлана.

Ул, кайбер документлардан күренгәнчә, Дондагы Ростов шәһәрендә туа. Казанда — Күл буе мәдрәсәсен, Ростовта рус телендәге һөнәр училищесын тәмамлый. Чит илләрнең Истанбул, Каһирә, Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә укый. Белем эстәп кайткач, Петербург университетының юридик факультетында ирекле тыңлаучы була. Әмма чуалышлар башлангач, югары уку йорты кыска вакытка ябыла. Муса моннан китә.

Фикерле егет Николай Бухарин белән Е.Преображенскийның «Азбука коммунизма» әсәренә мөнәсәбәтен белдерә. «Ислам әлифбасы» язмасын әзерли. Тик аны бастыра алмый. Аптырагач, мөселман илләре нәширләренә мөрәҗәгать итә. 1923 елда, Финляндия татарлары теләктәшлегендә, Гаяз Исхакый ярдәмендә теләгенә ирешә. Әмма кулга алына.

Төрмәдән чыккач, Муса Бигиев Төркестан аша Әфганстанга кача. Һиндстан аша Мисырга килә. Каһирәдә вафат була.

Дин белгече, турыдан-туры булмаса да, үзенең халыкара абруе белән гаиләсен яклый.

Үзара сөйләшкәндә, аның искитәрлек мәхәббәт тарихы да яратып искә төшерелә. Ул Каһирәдә Чистай ишаны Мөхәммәтзакир Камалов улы Ибраһим белән укый. Аңа сеңлесе Әсмагалия (1884-1975) җибәргән хатларга игътибар бирә.

— Ибраһим, сеңлең бигрәк акыллы хатлар яза, үзе белән таныштыр әле, — ди ул.

Чистайга кайта, өйләнергә рөхсәт ала, 1905 елда шунда туйлары уза. Бик матур яшиләр. Хатын сәфәрдән кайтып керməүче ирен озатып кала, сагы-

Муса Бигиев. 1908 ел

нып каршы ала. Мәхәббәт җимешләре булып, алты бала туа. Иң олы кыз — Мәрьям (1907-1993). Ленинград педагогика институтын тәмамлый. Химик-лаборант була. 1931 елда Вологдага сөрелә. Шунда Касыйм татары Госман Акбулатов белән таныша. Ул исә — Мәскәү энергетика университеты студенты. Татар зыялыларының хатына кул куя. «Солтангалиевче»лектә гаепләнә. Сөргеннән соң гаилә Ярославльгә кайта. Уллары Тимур, кызлары Камилә туа. Тик шатлыклары озакка бармый. Госман икенче тапкыр кулга алына. Атыла. Мәрьям Красное бистәсенә күченә. Сыра кайнатуда катнаша. 1946 елда Уфага күченә. Чернигов сыра заводында баш технолог булып пенсиягә чыга. Икенчесе — Зәйнәп (1908-1967). Казанда 1931 елда кулга алына. Ленинградка китерелә. Педагогия институтында югары белем ала. Биолог. Үзлегеннән чит тел курсларына йөри. Инглиз, немец, француз телләрендә сөйләшә. Казанга кайта. Свердловскига күченә. Монда Мәскәүдән күчерелгән институтта эшли. Патент бюросында тәрҗемә белән шөгыльләнә. Институт хезмәткәрләре белән башкалага кайта. Гаиләсе булмый. Үзе генә яши. Өченчесе — Мөхәммәт (1909-1941). Беренче тапкыр 1931 елда кулга алына. Ленинград дәүләт университетында укый. Физик. Юллама белән Свердловскига җибәрелә. Сөргеннән соң Түбән Новгородка кайта. Сугышка кадәр Мәскәүдә эшли. Хәрби хезмәткә чакырыла. Имеш, комиссариаттан чыкканда трамвайга эләгеп үлә. Хатыны ирен күмүдә, нишләптер, катнашмый. Дүртенчесе — Һинд (1911-1962). 1931 елда тоткарлана. Ленинградта Габдельхак Карамышевка кияүгә чыга. Химия-технология институтының кичке бүлегенә укырга керә. Әмма тәмамлый алмый. «Социаль яктан куркыныч зат» буларак, Ленинград өлкәсеннән читкә җибәрелә. Курганга Фатыйма янына барып төшә. Моннан Уфага китә. Игезәкләре Алия һәм Юрат туа. Авырып, яшьли үлә. Бишенчесе — Әхмәт (1912-?). Ленинградта заводта тимерчелектә эшли. 1931 елда кулга алына. Фатирында татар милләтчеләре белән җыен үткәрүдә гаепләнә. Вологдада, сөргендә чакта, клубтагы музыкант Татьяна Пастуховага өйләнә. Уллары Искәндәр һәм Борис туа. Мәскәү механика-машина төзелеше институтын

Әсма ханым балалары белән. Сулдан уңга: Мөхәммәт, Әхмәт, Һинд, Мәрьям һәм Зәйнәп. Чистай шәһәре. 1912 ел

читтән торып тәмамлый. Ленинград өлкәсендәге Колпинода атаклы Ижор заводында инженер була. «Советлар Союзы тимерчеләре» китабын язарга, фәннәр кандидаты диссертациясен якларга җыена. Әмма 1936 елда икенче тапкыр кулга алына. «Контрреволюцион милли шпионлык-диверсия оешмасындагы эшчәнлектә» гаепләнә. Хәрби трибунал тарафыннан ике елга ирегеннән мәхрүм ителә. Ябык конструкторлык бюросында эшли. Иреккә чыгарына бер көн калгач, тагын «советка каршы эшчәнлектә» гаепләнә. Гомере киселәчәкне фаразлап, 1938 елның 24 ноябрендә әнисенә мондыйрак эчтәлектәге хат яза: *«Әнием! Миңа яшәү күренми. Никадәр кыргый булса да, бу шулай. Миңа ышанмыйлар, куркыныч дип табалар. Әмма мин тыныч: чөнки намусым чиста. Үзеңнең намусыңны югалтмау — зур казаныш бит ул! Гаепләү карары белән ризалашмыйча, Калининга хат яздым.*

Ачыктан-ачык әйтәм: яшисем килә. Тик насыйп түгел — кырыс чынбарлыкны кабул итәргә туры килә.

Минем үлемемдә үзеңне яки әтине гаепли күрмә тагын. Юк-юк-юк! Һәркемнең үз үлеме. Минем вакыт җитте һәм бетте…

Таняга хат язарга рөхсәт бирмәделәр, аның миннән баш тартуын әйттеләр. Бу ничек була инде, әни? Мин аны яраттым бит, сез каршы булсагыз да, аңа өйләндем. Аны гаепли алмыйм. Күрәсең, минем белән бәхетле булмаган.

Сезнең аша балаларыма да мөрәҗәгать итәм, алар үсеп җиткәч, хатымны күрсәтерсез.

Ышанам, әни, вакыт җитәр, мин акланырмын. Сез дә моңа ышаныгыз…»

Шөкер, бу юлы үлем аны читләтеп уза. 1939 елның җәендә Әхмәт тоткынлыктан азат ителә. Инженерлар сафына баса. Ә сугыш башлангач, армиягә

алына. Авиация остаханәсендә хәрби инженер йөген тарта.

Аның сугыштан соңгы язмышы табышмакка әйләнә. Чөнки илгә әйләнеп кайтмый. Германиянең Мюнхен шәһәрендә яши. Саклану чарасына санаганлыктанмы, хат язмый. Документаль кино төшерүче туганы Йолдыз Карамышеваны өендә дә кабул итми. Телефоннан: «Сезне мине күзәтергә җибәрделәрме?» — дип кенә әйтә. Ә икенче юлы телефонны аның хатыны — немка ала. Иренең 1990 нчы еллар башында үлүен әйтә.

Төпчек кыз — Фатыйма. 1930 елларга кадәр Ленинградта яши. Әтисе чит илгә киткәч, гаиләләре өч елга Вологдага сөргенгә җибәрелә. Аннан кайткач, 1934 елда Казанда 10 классны бик яхшы билгеләренә тәмамлый. Әмма КДУга кабул ителми. «Муса Бигиев кызы мондый уку йортында белем алырга лаеклы түгел», — диләр. Рәнҗетелгән кыз апасы Мәрьям янына Ярославльгә килә. Сталинның «әтисе өчен улы җавап бирми» дигән сүзләре кайбер каршылыкларны чигендергәнлектән, Мәскәү химия-технология институты курсларында кичен укый. Сугыш башланганда диплом ала. Юллама белән Курган ит комбинатына җибәрелә. Лаборатория мөдире була. 1947 елда Габдрахман Таһирҗанов аны кияүгә алырга килә. Биредә язылышалар. Бераздан парлы тормыш коммунал фатирның бер бүлмәсендә тернәкләнә. Фатыйма иренең алыштыргысыз ярдәмчесенә әйләнә. 86 яшенә җиткәнче, 45 ел китапханәдә эшли. Гомер кояшы баегач, Волков исемендәге мөселман зиратында ире янәшәсенә җирләнә.

Муса Бигиев балаларының берсе дә әтисеннән баш тартмый. Ялган җиңеллеккә кызыгып, иманын сатмый. Сигез оныгы да, югары белем алып, бабалары рухын шатландырып яши. Уналты оныкчыгы да тормышта үз урыннарын таба.

ГАЕПНЕ ДИННӘН ЭЗЛӘМӘГӘН

Кызыксынучан Альмира ханымга Казанда (1999 елның 17-18 декабрендә) ТР Фәннәр академиясе, Диния нәзарәте Төркия университетлары белән берлектә үткәрелгән «Муса Бигиев — дин һәм җәмәгать эшлеклесе» дигән симпозиумда да катнашырга насыйп була. Ул озак көтелгән, Коръәннән дога укып башланган бу чарага үзе генә түгел, каенанасы Фатыйма Муса кызы белән бергә килә. Чыгышларны дикъкать белән тыңлый. Төрле фикерләр ишетә.

— Күренекле шәхесләр иҗатын бик соңарып өйрәнү — безнең зур кимчелегебез, — ди профессор Яхъя Абдуллин.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Госман хәзрәт Исхакый белдергәнчә, М.Бигиевне борчыган иң мөһим мәсьәлә — шәрык дөньясының көнбатыштан артта калуы. Ә моңа дин түгел, надан муллалар гаепле.

— Без Муса Бигиевне үзе язган хезмәтләре аша танырга тиешбез. — Монысы Төркиядән килүче галим М.Гёрмез сүзләре.

Язучы Рабит Батулла болай ди: «Муса Биги башына түбәтәй кими, озын чәч белән йөри. Аны күп белгәне, үзен иркен тотканы өчен дошман күрәләр. Бүген дә зиһенле имамнарыбызны наданнар кыса түгелме?»

Төрек галиме Айше Суджу дин белгеченең хатын-кыз мәсьәләсен бөтен дөнья күләмендә күтәрүен искәртә. Ул: «Мәҗүсилеккә таянмыйча, Коръәнгә нигезләнеп фикер йөртсәк, ир-ат һәм хатын-кыз хокуклары сакланырга тиеш», — ди. Шушы фикере белән зур бәхәс китереп чыгара. Әмма еллар үткәч, аның хаклы булуы раслана.

Мөнбәргә Казаннан Фәрит Шакиров та күтәрелә. Симпозиумга 90 яшьлек әнисе тәкъдиме буенча килүен әйтә. Ул 1929 елда Әстерханда европача киенгән сөйкемле Мусаның чыгышын тыңлаган икән. «Дин әһелләренә

Фатыйма Бигиева. Курган шәһәре. 1946 ел

халыктан аерылмаска кирәк, — дигән нотыкчы. — Сезнең кулда милләтне дин белән саклау мөмкинлеге бар. Халкыбыз тырыш булганлыктан, безнең киләчәгебез матур. Бу сыйфатны сакларга, үстерергә ярдәм итегез!»

Соңыннан, әлбәттә, резолюция дә кабул ителә. Муса Бигиевнең китапларын бастыру уе хуплана. Исемен урамга бирү фикере куәтләнә. Каһирәдәге зиратын төзекләндерү, Санкт-Петербургта музей-йортын ачу, Казанда фондын булдыру кебек мәсьәләләр күтәрелә.

КОРЪӘН ТӘРҖЕМӘСЕ

Русча, татарча, гарәпчә, төрекчә, фарсыча яхшы белүче Муса Бигиевнең Коръәнне татарчага тәрҗемә итүе турында да сүзләр күп йөри. Аның бүгенге көнгә кадәр саклануы хакында да әйтәләр. Бу чыннан да шулай икән бит: хатыны Әсмагалия дин кысылган хәтәр заманнарда да аны юкка чыгармый. Ә нәшриятта бер данәдә басылган текстны кызы Фатыймага да биреп куя. Фатыйма Таһирҗанова, үзгәртеп кору еллары башлангач, билгеле, аны күбәйтеп басарга омтылыш ясый. Әмма изге ниятне гамәлгә ашыру өчен акча табылмый. Санкт-Петербург этнография һәм антропология институты директоры урынбасары, көнчыгыш белгече Ефим Резван уе да ярты юлда кала. Финляндиядәге милләттәшләр дә хыялланудан уза алмый. Ләкин тарихи мирасны хөрмәтли белүче килене Альмира Таһирҗанова, ире Мөхәммәт исеменнән эш йөртеп, төенләнгән мәсьәләгә чишелешне барыбер таба! Дөресрәге, аңа бу изге эшендә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, Президент аппаратының тышкы элемтәләр департаменты җитәкчесе Тимур Акулов теләктәшлек күрсәтә. Нәтиҗәдә, бер гасырга якын вакыт узгач, 1912 елда Муса Бигиев тарафыннан эшләнгән Коръәни Кәрим тәрҗемәсенең репринт басмасы (Казан, 2010, 792 бит, 1000 данә) дөнья күрә. Шулай итеп, үз заманында дини җәмәгатьчелек тарафыннан күрсәтелгән каршылыкка, тәрҗемә бер кешенең генә эше булмаска тиеш дигән акыл сатуга, әле моңа вакыт җитмәде диюгә, мөфти фәрманы белән белдерелгән тыюга чик куела.

Мөхәррир, кереш сүз авторы Нурия Гәрәева искәрткәнчә, үз вакытының танылган Коръән белгече Муса Бигиевнең тәрҗемәсе бүген дә гаять зур кызыксыну уята һәм җентекләп өйрәнүне сорый.

Моннан тыш, аның Коръәнне төрекчәгә тәрҗемә итүе дә мәгълүм. Ни кызганыч, дин белгече аны да үзе исән чагында нәшер иттерә алмаган.

ЭШСЕЗ КАЛГАН МӘГЪРИФӘТЧЕ

Хәтер сагында торуда зур мәгънә күрүче Альмира ханым Санкт-Петербургның архив, китапханә киштәләренә дә үрелә. Төньяк башкала тарихында эз калдырган милләттәшләр тормышын җентекләп өйрәнә. Аерым алганда,

шәһәр төзергә килүчеләр яшәгән Татар бистәсе турында мәгълүмат туплый. Мәчетне сафка бастыруга, мәхәллә язмышына, мөселман корылтайларына кагылышлы елъязмаларны укый. Дәүләт Думасындагы мөселманнар фракциясе депутатларының чыгышларын өйрәнә. Якыннары Муса Бигиевкә, Габдрахман Таһирҗановка кагылышлы документларның күчермәләрен ала. Белгәннәрен киң җәмәгатьчелек белән уртаклашырга теләп, «Мөселманнар Петербургта» дигән экскурсияләрен башлап җибәрә. Ачышлары турында «Петрополь» милли мәдәниятләр йорты фәнни үзәгендә сөйли. Мәкаләләрен төрле газета-журналларда, энциклопедияләрдә, сүзлекләрдә дә бастыра. Эзләнүләрнең хисабын халкына җиткерергә теләп, каенанасы Фатыйма Муса кызының якты истәлегенә багышлап, «Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках» («Муса әфәнде, ул яшәгән чор һәм аның замандашлары турында китап», Казан, 2010, 559 бит, 1000 данә) дигән хезмәтен чыгара.

Әлеге сәяси тупланма, мавыктыргыч итеп язылганлыктан, маҗаралы хикәя кебек бер тында укыла. Күз алдына милли сәясәт тарихы бик ачык шәйләнә. Аның хәтәрлегеннән тәннәр чемердәп китә.

Сүз иреге кысылган шартларда, мәсәлән, 1914 елның 15-25 июнендә узган IV Бөтенроссия мөселман съездына 34 делегатның катнашуы Россия эчке эшләр министры һәм Дәүләт Думасы депутатларының мөселман фракциясе белән килештерелә. Матбугат вәкилләренә исә әлеге чарада катнашырга бөтенләй рөхсәт бирелми. Дин белгече — реформатор Муса Бигиевнең мондагы чыгышы исә, кысылган мөселман халыклары язмышын кайгыртканга күрә, «начар эчтәлекле» дип бәяләнә. Аның, милләтче булганлыктан, «сәяси яктан ышанычсыз»лыгы тагын да «арта». Тора-бара ул Россия мөфтие кандидатлары исемлегенә кертелми. Күзәтелүен белә торып, уйлаганын

Габдрахман Таһирҗанов. Ленинград. 1983 ел. Х.Бәдретдинов фотосы

ачыктан-ачык әйткәнлектән, Мәскәүгә (1924-1926) сөрелә.

Аеруча зур каршылык совет дәүләте һәм партия эшлеклеләре Н.Бухарин белән Е.Преображенскийның «Азбука коммунизма» әсәренә тискәре мөнәсәбәт белдергәч башлана. Чөнки М.Бигиев яңа социалистик җәмгыять төзүне күздә тоткан дәреслектә динне урынсыз тәнкыйтьләүне кабул итә алмый. Ул, белгеч буларак, мөселман җәмгыятен ничек үзгәртеп кору зарурлыгы турында үз сүзен әйтергә-язарга мәҗбүр була. *«Интернационализм исеме белән барлык милләтләр һәм халыклар, аларның диннәре, гыйбадәтханәләре, судлары, кануннары каһәрләнде,* — ди автор 1923 елда Германиядә басылган хезмәтендә. — *Хәрби трибуналлар, гадәттән тыш комиссияләр тарафыннан тетрәнүләрдә Россиядә шәригать гыйлемен һәм нигезләрен корал көче белән яңа дин — коммунизм җиңде.*

Әмма коммунистик сугышчанлык — большевиклар армиясе — беркайчан да төркиләр дусты, мөселманнар дусты, мөселман илләре дусты була алмый».



Р.Фәхреддиннең М.Бигиевкә язган хаты. 1909 ел

Муса Бигиев монда мөселман дөньясын үзгәртеп коруга кагылышлы 236 тәкъдимен кертә. Ә югары максатын болай билгели: *«Безгә үзара танышырга һәм төрки телле эшкуарлар арасында эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырырга хезмәт итәрлек Югары Төрки Җәмгыять, шулай ук төрки телләрне, тарихны, әдәбиятны, мәдәни-тарихи һәйкәлләрне яңартырга хезмәт итүче фәнни «Төрки» җәмгыять оештырырга кирәк»*. Кызганыч, әлеге фикерләр «Коммунизм әлифбасы»н өйрәнүче Россия халкыннан, аеруча яшьләрдән күп дистә еллар дәвамында яшерелә. Аларны курыкмыйча әйтергә батырчылык итүче фикер иясе (1923 елның 12 ноябрендә) Мәскәү вокзалында кулга алына. Советка каршы агитациядә, дәүләтнең абруен төшерүдә, контрреволюцион мөселман төркемнәре белән җинаятьчел элемтә урнаштыруда гаепләнә. Ике елга Мәскәүгә сөрелә. Әмма нык ихтыярлы дин белгече, зирәк мәчет имамы, уйларын киң җәмәгатьчелек белән бик теләп бүлешүче хәбәрче урынсыз дәгъваны кабул итми. Үзенең халыкка Коръәнне өйрәтүен, диннең төрле юнәлешләре тарафдарларын дуслаштырырга тырышуын искәртә.

Финляндия татарлары Төркиягә телеграмма җибәргәч, *«Россиядә бөтен мөселман дөньясына билгеле хөрмәтле галим Муса Бигиев кулга алынды. Совет хөкүмәтенә аны төрмәдән азат иттерүгә йогынты ясавыгызны сорыйбыз»*, дигән сүзләр Анкара һәм Истанбул газеталарында басылгач, җәза йомшарса да, эзәрлекләү боҗрасы барыбер көннән-көн кысыла. Имамга мәчеттә вәгазь сөйләүләр тыела, китабын таратулар чикләнә. Аптырагач, Каһирәдә һәм Мәккәдә (1926 елның маенда) Бөтендөнья мөселман конгрессында катнашучы, Хаҗга баручы (1927) дин эшлеклесе, фәнгә хезмәт итәргә теләвен белдереп, академик Крачковскийга гарәп телендә (1928 елның 11 июнендә) хат язып карый. Әмма җавап алмый. Финляндия имамы Гомәр Салига язган хатында исә ул: *«Соңгы ике елда минем финанс хәлем бик начарайды,* — ди. — *Мин барлык яктан да кысынкылык халәтендә. 1929 елда хокукларымнан мәхрүм ителдем. Нинди дә булса эш тә таба алмадым»*. Эшсез мәгърифәтче, алласызларның «чистарту» шаукымы корбаны Мәскәү илчелеге аша Әфганстан хөкүмәтенә фарсы телендә юллаган мөрәҗәгатендә исә болай ачыла: *«Минем төп өстенлегем Исламга ышануымда һәм ул ышаныч бик нык. Әмма мин эшсез һәм яшәр өчен ярдәмсез калдым. Кулымда фәкать каләм генә калды. Мин ислам илләрендә эшләргә, ислам дәүләтләрендә хезмәт итәргә*



М.Бигиевнең көндәлек-дәфтәре һәм күзлеге

телим. Сездән эш сорыйм». Ул 1930 елда Крачковскийга тагын хәленең авырлыгын хәбәр итә. Гарәп, фарсы, төрек телләрен укытырга әзер икәнлеген сиздерә. Әмма бәладән баш-аяк дигәндәй, галим аны эшкә чакырмый. Күпләрдән өметен өзгән Муса Бигиев, яхшы киләчәк көтмәвен ачык фаразлап, 1930 елның ноябрендә Мәскәү аша чит илгә чыгып китәргә карар кыла. Ленинградтагы гаиләсенә, ташлап китүе өчен гафу үтенеп, соңгы хатын яза да мөһаҗирлектәге тормышына юл ала. Четерекле мәсьәләләргә чишелеш эзләп, илләр-җирләр гизә. Бер яктан — гаиләсен, икенче тарафтан мәхәлләсен югалту кайгысын, хәсрәтен җиңеләйтергә теләп, яза да яза.

— Мине ачы аерылышу газабы яндыра, — ди ул 1947 елда Каһирәдәге танышы Йосыф Уралгәрәйгә. — Мин хатынымны һәм балаларымны ташладым. Белмим, алар хәзер ничек яшиләрдер? Мин, үлем көтүен чамаласам да, Россиягә кайтырга карар иттем.

Тик Уралгәрәй танышын күрәләтә үлемгә җибәрми. Дустын, киңәштабышөчен, Төркиягә озата. Монда, ни кызганыч, ул саулыгын югалта. 1948 елда, бик хәлсезләнеп, кабат Каһирәгә әйләнеп кайта. Картлар йортына урнаштырыла. Шунда, китапларын Анкара милли китапханәсенә тапшыруны сорап, васыятен яздыра. Африкадагы Король зиратына соңгы юлга озатыла. Кырыгы, елы, йөзләп кеше катнашында, Финляндиядә билгеләп үтелә. Аның истәлегенә китапчык та чыгарыла.

Күренгәнчә, эзләнүчән Альмира Таһирҗанова каенанасы Фатыйма ханымның әтисе Муса Бигиев язмышын бик ныклап өйрәнгән. Аның ислам тәгълиматына, Коръәнне аңлатуга, хәдисләрне шәрехләүгә, сәяси һәм иҗтимагый мәсьәләләргә мөнәсәбәт белдерүгә, төрки әдәбиятлар тарихына кагылышлы йөз иллеләп хезмәтенә игътибар юнәлтә алган. Күңел күп дистә еллар буе көткән кузгалу ноктасы бу! Ул берүк дәвамлы гына була күрсен! Халкыбызга дөнья таныган Муса Бигиев әсәрләренең тупланмасы белән дә танышырга насыйп булсын! ■

Хөрмәтле укучы!

«Айшә ханым» пьесасын укыганда хәзерге вакытта безгә аңлашылмаган сүзләр, гыйбарәләр дә очрарга мөмкин. Мәсәлән, морза (титул, аксөяклелек дәрәҗәсе). Алтын Урдага һәм соңыннан Россия империясенә кергән төрки-татар халыкларында эре феодал яки аерым ыруг, кабилә башлыгы титулы. Бәк, яки русларның дворян дәрәҗәсенә тиң аксөяклелек билгесе (ТЭС. Казан, 2002 ел. 437 бит.). Пьесада әйтелгәнчә, алар үзләре татар булып та, татарларга, дин кардәшләренә түбәнсетеп карыйлар. Моны, үз милләтен кимсетеп әйтү дип түгел, ә байлар белән ярлылар арасында булган каршылык, дип кенә аңларга кирәктер. Шунысын да истән чыгармыйк, әсәрдә тасвирланган вакыйгалар, персонажлар егерменче гасыр башында революцион хәрәкәт канат каккан елларга туры килә. Искелек белән яңалык көрәше. Карт морзалар белән яшь морзаларның, югары катлам белән түбән катлам кешеләренең уй-фикерләре капма-каршы килгән чак. Драматург бу пьесасын язганда шул халәтне күз алдында тота да инде. 40 яшьлек иргә, 500 дисәтинә җире булган Хәсән морзага Фатма кебек ярлы, хезмәтче татар кызы кирәк түгел, ә үзе надан булса да, акыллы, чибәр, сөйкемле яшь кыз, биш вакыт намаз укып, аңа тәлинкә тотып торучы бай кыз — Айшә кирәк.

Драматург Хөсәен бәй Болатуков (Усейн Болатуков) үз чорын, кешеләрен, аларның дөньяга карашларын, аталар һәм балалар арасында булган конфликтны бер дә күпертмичә, талантлы каләм иясе буларак тасвирлый. Мөхәммәт морза, сеңлесе Айшә, энесе Али морза әти-әниләрен хөрмәт итсә дә, яратса да, дөньяга карашлары үзгә. Русча укырга, язарга, белем алырга омтылалар, татарча шигырьләр дә укыйлар, гомумән, замана балалары булып яшиселәре килә. Бу очракта драматург кырым татар мәгрифәтчесе Исмәгыйль Гаспринский идеяләрен алга сөрә. Бу Мөхәммәт морза сөйләмендә бик ачык күренә. Халык, милләт, дин хакында Мөхәммәт морза, Али морза, Айшәнең сүз алып барулары — моңа ачык мисал.

— Синең кебек намазсыз татар егетләре хайваннан яхшымы? — дигән сорауга Мөхәммәт морза болай ди:

— Ни өчен мине хайваннан ким күрәсең? Ни өчен фанатизм бусагасын атлап чыга алмыйсың? Ни өчен татарларга пычрак атасың, ә морзаларны күккә чөеп мактыйсың? Башында акылы булмаса, морзадан ни файда?

Али морза белән Фатма сөйләшкәнгә колак салсак, шул ук хәбәрне ишетербез. Фатма (башын чайкап): — Юк, морзам, мин ярлы татар кызы, Хәсән морза мине алмас, — ди.

Пьесаның финалында Али морзаның оптимистик хыялы: «Үсеп кенә җитим, алырмын бер кылыч, татарлардан беренче булып, бу иске дөньяны егармын!»

Хәзерге укучыга бу әсәр бераз гадиерәк күренсә дә, чынлыкта, драматург Хөсәен бәй Болатуков олы фәлсәфи, сәяси, социаль проблемаларны күтәргән, дип әйтергә хакыбыз бар. Чөнки бу проблемалар бүгенге көндә дә, вакыйгаларга йөз елдан артык вакыт үтсә дә, бик актуаль әле.

Нурулла Гаптуллин, *тәрҗемәче.*
Түбән Кама шәһәре

АЙШӘ ХАНЫМ*

Усеин Болатуков

(ӨЧ ПӘРДӘЛЕК ПЬЕСА)

Катнашалар:
Морза.
Ханым.
Мөхәммәт морза — *аларның улы, гимназист.*
Айшә ханым — *Мөхәммәт морзаның кыз кардәше, сеңлесе, 18 яшьтә.*
Али морза — *морзаның кече улы.*
Хәсән морза — *алпавыт, 40 яшьтәге тол ир, 500 дисәтинә җир иясе.*
Әсма ханым — *Хәсән морзаның кыз кардәше, сеңлесе.*
Фатма — *хезмәтче кыз.*
Хәнифә ханым — *Әсма ханымның күршесе.*
Мәрьям ханым — *шәһәр ханымнарыннан.*
Риза морза — *Әсма ханымның улы.*

* Усеин Болатуковның (Хөсәен бәй Болатуков) әлеге пьесасын рус теленә тәрҗемә итүне сорап, Кабарда-Балкар Республикасының Нальчик дәүләт университеты профессоры Альбек Чамир улы Абазов Татарстан журналистлар берлеге әгъзасы Нурулла Гаптуллинга мөрәҗәгать итә. 2013 елда бу эш башкарыла. Ә инде 2014 елда әсәр татар теленә дә тәрҗемә кылына.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Вакыйга Кырымда бара

Язгы кич. Туганнар ишегалдында үсеп утыручы әстерхан чикләвеге агачы күләгәсендә урнаштырылган өстәл тирәсенә җыелышып утырган. Морза йә авызыннан, йә борыныннан төтен чыгарып утыра. Морзабикә стаканнарга лимон җимеше тураклый, ә Айшә ханым кайнар чәй сала. Али морза бер шакмак шикәр суырып утыра.

Морза. Кыз-ы-ы-м!

Айшә ханым. Нәрсә, әти, әйтегез!

Морза. Беләсеңме?

Айшә ханым *(төшенмичә тора).* Йу-у-у-к... Әйтегез соң!

Морза. Тырышып карасаң, төшенерсең!

Айшә ханым. Мин ничек төшеним ди. Әти, җаным, тилмертмәгезче, әйтегез!

Морза. Әйтмим, үзең уйлап кара.

Айшә ханым *(уйга батып торганда, стакан тулып ташый).* Ах, кулым! *(Кычкыра-кычкыра кулын селкегәндә Али морзаның аягына чәй түгә.)*

Али морза. Уф-уф! Яндым, пешердең син мине, кызый!

Ханым *(түгелгән чәйне улының аягыннан сөртеп).* Ах, син, мәлгунь, ах, син дуңгыз! *(Айшә ханымның аркасына йодрыгы белән суга.)*

Фатма *(өйдән килеп чыгып).* Ни булды, ә, ни булды, җаныем? *(Али морзаны кочаклап.)* Еламагыз, морзам.

Морза *(көлемсерәп).* Афәрин, кызым, булдырдың!

Ханым. Менә, кире, бер генә дә акылың юк. Бала елап ята, ә бу көлә...

Морза. Сөбханалла, синеке шикелле! Әгәр чәй түгелгәннән генә бала үлсә, башта мин үлгән булыр идем. Яшь чагымда минем өскә илле чүлмәк су түккәннәрдер, ни булды шуннан? Аллага шөкер, беркемнән дә ким түгелмен!

Али морза *(күзләреннән яшен сөртеп, әтисенә).* Сез кайчан бала булдыгыз? Мин беләмме аны?

Морза. Заманында мин дә бала идем, заманында мин дә кечкенә идем, заманында мин дә елый идем, бар да булды инде.

Али морза. Минем белән күрешә идегезме?

Морза *(бармакларын күрсәтеп).* Боларга карачы!

Айшә ханым. Сез ни әйтмәкче идегез, әти?

Ханым. Әйтәчәк сүзеңне әйт инде, юкса, безне дә кайнар чәй белән пешерер.

Морза. Менә сиңа бер әйбер! Икенчесе кайда? Уйла да тап, үскәнем!

Ханым. Куй шуны! Калдыр! Балачага кебек табышмак әйтеп уйныйсың.

Али морза *(кулларын бер-берсенә ышкып).* Әйтимме?

Айшә ханым. Әйтче, энекәем, әйт!

Али морза. Абыем кайтачак, шулаймы? *(Куанып.)* Таптыммы?

Ханым. Дөресме?

Морза. Дөрес! Мөхәммәт хәзер кайтып җитәр. Бүген аның соңгы имтиханы.

Ханым *(утырган җиреннән күтәрелеп).* Класстан күчтеме икән?

Морза. Һич хафаланма, Мөхәммәт тә күчмәсә, кем күчәр, ә?

Ханым. Йә, Ходаем, үзеңә тапшырдым, баламны саклый күр!

Айшә ханым. Шулкадәр тыныч сез, әнием. Мин башымны кистерер дәрәҗәгә килеп җиттем...

Ханым. Юк-барны сөйләп утырма. Әгәр Аллаһы Тәгаләдән ярдәм булмаса, башыңны түгел, борыныңны, колакларыңны, телеңне кистерсәң дә файда булмас. Син ахмак сүз сөйлисең. Аллаһка ялварыр идең.

Айшә ханым *(көлемсерәп).* Йә, Раббым, абыемны класстан күчер!

Ханым. Күрәсезме, бу кыз акылын югалткан. Моны укытырга кирәк. *(Али морзага карап.)* Улым, иртәгә учительне чакыр әле.

Али морза. Ә ул ни эшләячәк?

Ханым. Бу наданны укытыр!

Али морза. Диннән читләшмә, ханым, намазны хөрмәт итәр идең.

Айшә ханым. Мин, туганым, динне истән чыгармыйм. Синнән дә күбрәк хөрмәтлим мин динебезне.

Морза. Җитте, булды, бәхәсләшмәгез. Кеше төсле һич бер-берегезне хөрмәтләп, тынычлап яши алмыйсыз.

Ханым. Фатма, бар, капкадан карап тор. Мөхәммәт кайтса, шундук безгә кереп әйтерсең.

Али морза *(урыныннан торып)*. Мин дә барам.

Айшә ханым. Мин дә! *(Чыгып китәләр.)*

Морза *(бераз тынып торганнан соң)*. Карчык, баладан да татлы нәрсә бармы икән дөньяда? Мин балаларымны шулкадәр яратам ки, алар өчен үләргә дә әзер.

Ханым. Минем кадәр сөйми торгансыздыр әле. Мин аларны шулкадәр яратам, алар өчен җаным фида кылам, тик менә алар мине әни дип санлап җиткерми кебек. *(Уйга калып.)* Моны беләсезме?

Морза. Ә? Нәрсә, карчык?

Ханым. Әгәр Мөхәммәт кайтса...

Морза. Йә, нәрсә булыр?

Ханым. Айшәне әйтәм әле, оялмый да. Иртән Коръән укымас, намазны да кирәгенчә башкармас. Я, Тәңрем, балаларымны тугры юлдан яздырма.

Морза. Үзең гаепле. Әгәр дә син теләмәсәң, мин Мөхәммәтне гимназиягә бирмәгән булыр идем. Синнән торды.

Ханым. Шулаен шулай да, тик бер кәгазь гариза яздыру өчен хәрәмче казакка яки җитер-җитмәс татарга ялыну эшмени? Мин уйладым, әгәр дә Мөхәммәт укыса, үзебезгә уңай булыр дип. Бер учительгә көнебез калмас дип. Әмма Мөхәммәт казак ягына тартыла. Айшәне дә юлдан чыгаруы бар. Йә Раббым, уку кешене никадәр боза икән.

Морза. Боза дип үк әйтәсе килми. Гимназия — белем коесы. Аның төбенә берәү дә төшеп бетә алмый. Тик бераз ялгыштык, ахры. Татарның акылы төштән соң шул.

Ханым. Сез ни сөйлисез? Аллаһыма шөкер, без татар түгелбез.

Фатма *(чабып килеп)*. Мөхәммәт морза кайтты!

Ханым *(аягүрә баскач, Мөхәммәт морзаны күреп алып)*. Ах, үземнән биек улым! *(Муенына сарылып.)* Класстан күчтеңме?

Мөхәммәт морза. Странно. Саулыгымны сорамыйча, класстан күчтеңме, дип сорыйлар. Удивительный хәл.

Али морза. Менә тагын, әни тиешмени беренче булып саулыгың турында сорарга?

Ханым. Улым, яхшысыңмы соң? Арыдыңмы? *(Мөхәммәт морзаның беләкләреннән тотып.)* Күрәле, сөякләре генә калган.

Али морза. Бу кадәр укып поп булачаксыңмы инде?

Мөхәммәт морза *(анасының кочагыннан чыгарга теләп)*. Җибәр, әнием, барып әтием белән дә поздороваться итим. *(Әтисенең битеннән үбә.)* Яхшы гынамы, әтием?

Али морза. Яхшы булмаса, түшәктә булыр иде.

Айшә ханым. Ай-ай, син дә телеңне озынайттың.

Али морза. Ни эшлием, озынайтмыйча?

Айшә ханым. Теш арасында тот.

Али морза. Синең телең үзеңдә, минекенә кагылма.

Ханым *(Айшә ханымга карап)*. Ташла шуны, булды! *(Мөхәммәт морзага карап.)* Сөйлә, улым, Акмәчеттә ниләр бар?

Мөхәммәт морза. Эшләр бара, хәбәрләр бик күп. Нәрсә сөйлим соң?

Ханым. Мин беләм Акмәчеттә күп эшләр эшләнгәнен. Берәр яңа хәбәр юкмы, дим?

Айшә ханым. Зурмы соң ул

Акмәчет дигән калагыз? Унсигез яшемә җитеп, мине бер тапкыр да шәһәргә алып бармадыгыз. Гомердә бер генә тапкыр күрә алсам иде Акмәчетне, аннан үлсәм дә үкенмәс идем!

Морза. Шөкер ит, кызым, аны күрмәгәнеңә һәм теләмә дә. Шәһәргә бер барсаң, улитсасына чыксаң, хәтта качып китәргә җитешә алмассың.

Айшә ханым. Ни өчен?

Морза. Син ни беләсең соң? Йә?

Айшә ханым. Әлбәттә, берни белмим. Мин дә кешеләр кебек чыксам, йөрер идем, бәлки, кешеләр кебек тегесен-монысын белеп торыр идем.

Ханым. Беләм мин синең ни беләчәгеңне, син башта хатын-кыз тәкъдирен белер идең. Ах, син, оятсыз, ах, син, җирбит! Карагыз-кара, ни сөйли бит.

Морза. Аның бер нидән хәбәре юк. Барса иде ул шәһәргә, чыкса иде урамга, күрер иде дөнья хәлен.

Али морза. Ни бар анда, әтием?

Морза. Андамы? Һә-ә-әй! Качып котылырсың хур кызларыннан!

Айшә ханым. Ә ни эшлиләр, әти?

Морза. Басып китәчәкләр, басып. Үзеңә юл таба алмассың. Әгәр дә бер әфитсәр үтеп китсә, артыннан илле хур кызы тагылыр. «Син тегеләй, син болай» дип танышып та китәрләр. «Әйдә, анда, әйдә, монда» дип бульварга алып китәрләр, аннан — театрга. Өйләренә төн уртасында гына кайтып җитәрләр. Соң бу яхшы эшме? Бу мөселманчамы? Бу — нәрсә бу? Өс киемнәре дисәң, җәймәгә охшаган, башларында синеке кебек эшләпә, итәкләре тездән *(әкрен генә)* ап-ачык, ялангач. *(Айшә ханымга карап.)* Соң син дә шуларга охшаячаксыңмы? Син дә шулай кызлыгыңны, намусыңны аяк астына салып таптаячаксыңмы?

Айшә ханым. «Мин шундый күлмәк алам», дигән сүзем юк бит әле. Мин бит шәһәр күрү теләген генә әйтәм.

Ханым. Балам, акылыңа кил! Акланма. Судан коры чыгарга уйлыйсыңмы? Шәһәргә барып та кыска итәк алмас, имеш. Синме? Башта муеныңа тәре тагарсың, ботларыңны урамда күрсәтерсең. Сине дә йә тегеләй, йә бу якка тартырлар. Син дә казак булырсың, җанкисәгем. Булма казак, синдәй кызга нәрсәгә кирәк шәһәргә барырга? Мин бервакытта да бармадым. Аннан ни булды? Кемнән ким? Сиңа минем кадәр булсаң, җиткән, минем сүздә йөрсәң, җиткән. Җаныңа урын тапмасаң, эчең пошса, ал кул эшен, чигү чик. Телисең икән, бакчада йөреп кер. Йә, әнә, ал китап, укы.

Айшә ханым. Кайсы китапны укыйм? Укысам, каршы килмәссезме?

Ханым. Кайсы китапнымы? Бездә булган китапларны укысаң, җәннәтнең төбенә төшәр идең. Ләкин ни файда? «Әхмәдия» шкаф өстендә тузанланып ята, «Мөхәммәдия» полка өстендә. Ә мәхәббәт турындагы китаплар? Кәрәми булсын, Умери булсын... Ни өчен укымыйсың? Бездә булган китаптан дивар салсаң, яхшы бер йорт килеп чыгар иде. Берсе дә укымый. Мөхәммәт саф, чиста, син дә шундый. Без әле кайбер чакта ачып карыйбыз, укыйбыз. Син дә укы, ишетәсеңме? «Мине укыттырмыйсың», дигәнең нинди сүз ул?

Айшә ханым. Оныттыгызмы? Сез түгелме соң минем китапны утка яккан?

Ханым. Нинди китап? Мин китап яктыммы? Син нәрсә, акылдан шаштыңмы?

Айшә ханым. Ә агам биргән китапны?

Ханым. Син ни сөйлисең? Акылың урыныңдамы?

Айшә ханым. Әйе, урынында. Оныттыгызмы? «Нидән бу хәлгә калдык?» белән ни булды? Көлгә әйләнмәдеме?

Мөхәммәт морза *(аягүрә басып).* Это ужасно! Мин ни ишетәм? Бу тиклем глупость. Кем терпеть итәр бу

кадәр акылсызлыкны? Иң яхшы китапны ал да утка як!? Хорошее дело.

Морза. Тукта беразга! Төрек кебек кинәт кабынып кызма. Нәрсә, Коръән битләрен якмагансыздыр бит? Бер ахмак чыгарган китап инде. Адәмне бозып, юлдан яздырган, юлда-а-н!

Ханым. Менә, кара, ахырзаман балалары нидән файда барын белмиләр. Мин «Әхмәдия»не яккан булсам, бу кадәр сүз әйтмәс идең әле, әлбәттә. Ә бит «Әхмәдия»не укыган кеше җәннәткә эләгәчәк, ул дөньялыкта да рәхәт күрәчәк, рәхәт!

Мөхәммәт морза. Белмисең, әнием! Кайсы китапны алырга белмисең. Теләсә кайсын алып, аңламыйча укып кара, һич пользасы булмас. Аңлап укырга кирәк! «Әхмәдия»дә дә, например, күп кенә яхшы нәрсәләр бар: «…мәхәббәттә яшәгез, һичкемне кыерсытмагыз…», диелгән. Сез дә боларны мең кат укыгансыз. Ә ни өчен исполнять итмисез? Ни өчен сүзгә керәсез? Ни өчен сплетничать итәсез?

Морза. Булды инде! Безне өйрәтергә син кем әле, ә? Кичә туып, бүген безгә акыл өйрәтә башлаган. Без дөньяны алдык-чөйдек, һич берәүдән сорамадык. Беләбез, кирәк түгел! *(Бераз тынычлангач.)* Туктагыз, зинһар! Берәрегез ястү намазын укыймы? *(Сәгатенә карап.)* Әйе, ястү җиткән икән. *(Ханымның кулыннан тотып.)* Әйдә, карчыгым, барып ястү намазын кылыйк. *(Ханым белән чыгып китә.)*

Али морза *(йокымсырап, башын кашый).* Бу йокыдан да татлы әйбер бар микән, кешеләр? Йокы анадан да, атадан да, аштан да, судан да татлы.

Мөхәммәт морза. Ну что, йокың килдеме?

Али морза *(күзләрен бармаклары белән уып).* Сез чистый казак булгансыз, «что»сыз-«муто»сыз сөйләшмичә һич булдыра алмыйсыз, синең әйткәнне берәү дә аңламый. *(Фатмага.)* Чур, кызыкай, чыгып ятыйк! *(Чыгып китәләр.)*

Мөхәммәт морза *(берәр минут торганнан соң).* Ну, нәрсә эшләргә, кардәшем?

Айшә ханым *(авыр сулап).* Беләсең бит инде, агам: көн дә кырык рәкагать намаз кылып, биш сурә намаз укыйм. Кайсы көннәрдә ураза тотам. Ашарга әзерлим.

Мөхәммәт морза. Йә, ни өчен золотое времяны булыр-булмас эшкә тратить итәсең? Җитмәдемени бүгенгәчә страдать иткәнең?

Айшә ханым. Йә анам, йә атам?..

Мөхәммәт морза *(кулларын маңгаена куеп).* Бу ни бу? Просто фанатизм! Кыз кешегә өеннән чыгып йөрергә тыела, кыз булганы өчен ул дөньяны, кешеләрне күрмәсен, имеш. Что это такое? Кыз булганга, аңа укуязу хәрәм булсын, көне буена уймак киеп чигеп утырсын икән! Ей богу, не понимаю.

Айшә ханым. Бераз акрынрак бул, ишетерләр.

Мөхәммәт морза. Вот тебе на! Ишетсәләр, дөнья бетәрме?

Айшә ханым *(Мөхәммәт морзаның муенына сарылып).* Агам, ялварам сиңа, тыныч бул! Дөнья да бетмәс, без дә, ләкин… *(Күзләрен куллары белән каплый.)*

Мөхәммәт морза. Айшә! Син авырмыйсыңдыр бит? Әллә инде влюбиться иттеңме? Что с тобой?

Айшә ханым *(күз яшьләренә чыланып).* Акрын. Әгәр ишетсәләр, минем хәлем мөшкел. Кимсетерләр.

Мөхәммәт морза *(кулларын селтәп).* Чепуха! Мин сине кыерсыттырмам. Син, дорогая, беспокоиться итмә. Карале күземә.

Айшә ханым. Фәрештә син, агам. Мин сине яратам. *(Агасын кочаклый.)*

Мөхәммәт морза. Мин фәрештә булсам, син фея, кардәшем. Фея! Феялар һичбер нәрсәдән курыкмас. Син бернигә внимание обращать итмә. *(Торып баса.)* Әйдә, минем белән бер бак-

чаны әйләнеп киләсеңме? *(Икесе дә чыгып китә.)*

Фатма *(әкрен-әкрен генә кереп, өстәлдәге шикәр савытыннан бер уч шикәр каба да җырлый башлый).*

Әйлән, әйлән, җил тегермән,
җил булганда,
Ах, Осман, кая барасың,
мин булганда,
Ах, мин торганда.
Үрмә гөлләр баганага сарылачак, ах!
Аллаһ мине Осман белән
кавыштырачак-чак,
Кавыштырачак!
Әйләнерме тегермән сусыз, канатсыз?
Мин дөньяда нишләрмен ярым
Османсыз-сыз,
Ярым Османсыз?
(Торып бии башлый.)

Бер күрүдән сөйде җаным сине,
Османым,
Мине сиңа язганмы Тәңрем,
Аллаһым-һым,
Тәңрем, Аллаһым...

Ханым *(өстенә туры килеп).* Син тилердеңме әллә?

Али морза. Фатма, акылыңнан яздыңмы?

Фатма *(ханым белән Али морзаның килгәнен күрмичә уенын дәвам итә).* Әтием бирсә, мин бармам һичкемгә, ах! Үзем теләп барачакмын шул Османга, ах, ах! Шул Османга... *(Ханым белән Али морзаны күрә.)* Мин ни күрдем, ни күрдем! Ниләр күрдем, ах! Әйтиемме мин сезгә ни ишеттем, ах, ниләр ишеттем?

Ханым. Әйт инде! Ниләр күрдең, ниләр ишеттең?

Фатма. Ә монда килсәләр?

Али морза. Бу лыгырдыкның авызыннан бер юньле сүз чыкканчы кыямәт көне башланачак.

Фатма. Тыңлагыз, менә ни әйтәм. *(Әле бер якка, әле икенче якка карый.)*

Ханым. Тизрәк бул, кызыкай, җанымны-гомеремне ашама.

Али морза. Телисең икән — әйт, теләмәсәң — кит. Маймылланып торма!

Фатма *(тирә-якка күз атып).* Барысын да ишеттем, барысын да күрдем. Айшә ханым Мөхәммәт морзаны кочаклап алды да: «Мине монда җәберлиләр, намаз кылдыралар», — ди. «Мине өйдән чыгармыйлар», — ди. *(Мөхәммәт морза белән Айшә ханымның килгәнен күреп, Мөхәммәт морзага эндәшә.)* Иртәгә чиберек пешериемме? Сагынгансыздыр.

Мөхәммәт морза *(Фатманың ни әйткәнен аңламыйча).* Айшәнеме? Әлбәттә, сагындым. Айшә кебек кардәшең булсын да, сагынма ди.

Али морза. Фатма синнән ни сорый да, син ни әйтәсең?

Мөхәммәт морза. «Айшәне сагындыңмы?» — ди. Так?

Али морза. Так, түгел. «Чиберек сагындыңмы?» — ди.

Мөхәммәт морза. Сагындым. *(Әнисенә карап.)* Знаешь, анам? Минем йокым килә. Йокларга кирәк. Ә әтием кайда?

Ханым. Ул инде ярты төнен йоклый. Әтиең ястү намазыннан соң ук йокыга ята. *(Айшәгә карап.)* Бар, Фатма белән йокы түшәкләре әзерләгез.

Айшә ханым *(Фатманы тотып).* Әйдә, Фатма. *(Икесе бергә чыгып китә.)*

Ханым *(бераз торганнан соң).* Улым, Айшә ничек, бик үскәнме? Һәркөн бер-беребезне күргәнгә, бик сизмибез.

Мөхәммәт морза. Правду говоря, Айшә ябыгып киткән, әллә авырдымы, хастасы юктыр бит?

Али морза. Беләсеңме, агай, Айшә апаның йөрәге авырта. Йөрәктән җәфалана.

Ханым. Ни булса да, әйтмә шуны. *(Мөхәммәт морзага.)* Колак салма шуның сүзенә.

Али морза. Агай ишәкме әллә, колак салмаска.

Мөхәммәт морза. Әйтче, Али, ни булды?

Али морза. Айшә апай синең дустың Ашыровка үлеп гашыйк булган. Көне буе Ашыровны исеннән чыгармый. «Ашыров болай, Ашыров тегеләй, Ашыров кебекләр дөньяда юк», — дип йөри.

Мөхәммәт морза. Дөресме бу? Какая радость! Юк, син мине алдыйсың.

Али морза. Нигә мин сине алдыйм ди. Хак, дөресе шул.

Мөхәммәт морза *(куанып).* Ах, минем кардәшем ничек мине обрадовать итте.

Ханым. Һай, ана-а-а-м! Энҗе бөртеге кебек бердәнбер туганы бар, аны да сөйми. Машаллаһ, балам, акылыңа кил!

Мөхәммәт морза. Что такое? Әнием, белеп тор, мин Айшәне сездән, әтиемнән артык яратамын. Айшәне дөньядан артык, хәтта, үземнән артык сөямен...

Ханым. Менә сиңа арату! Алтынның кыйммәтен белгән чүплеккә атармы?

Али морза. Син алтын йөзегеңне тиреслеккә аткан идең бер. Нәрсә, алтынның кыйммәтен белмисеңмени?

Мөхәммәт морза *(кардәшенә).* Мин ул вакытта бик тә кечкенә идем. *(Анасына.)* Ни өчен алай дип думать итәсез, анам? Мин Айшә кебек беркемне дә сөймим. Айшәне җанымнан да артык яратам.

Ханым. Беләм, беләм. Аңлашылды. Димәк, Айшә, морзага чыкмыйча, акылсыз татарга чыкса, куаначаксың, ә? Афәрин, балам, акылыңа!

Мөхәммәт морза. Конечно, куанырмын. Ашыров кебек укымышлы, итагатьле, деликатный морзаларыгыз арабызда бармы?

Ханым. Юк, кирәк түгел мондый деликатный-меликатныйлык. Татарга кызымны биреп хурлатмам!

Мөхәммәт морза. Вот ещё! Татарлар хатыннарын хурлыйлармы? Кто бы не был, сөйгәнен, яратканын хурламас.

Ханым. Кирәк түгел! Хурласын-хурламасын, кызымны татарга биреп иза чиктермәм. Әгәр Айшәнең әҗәле шуннан булса, барсын, язмышын күз күрер.

Мөхәммәт морза. Айшә сөя түгелме соң Ашыровны? Шулай булгач? Как-будто сез яшәячәксез аның белән?

Ханым. Димәк, иртәгә Айшә килеп: «Мин казакка гашыйк булдым», — дисә, бирергәме? Ахмак яһүдкә дә бирергәме?

Мөхәммәт морза. Менә, интересно! Беләсем килә, син ни өчен шулай татарларны яратмыйсың, ә?

Ханым. Юк! Бу булачак эш түгел, кызымны татарга бирмәячәкмен!

Мөхәммәт морза. Удивительно! Морзалар арасында да төрлесе бар. Син ошибаться итәсең, анам, ей-богу, ошибаться итәсең.

Ханым. Һич булачак эш түгел бу! *(Али морзага.)* Әйдә, улым, киттек йокларга. Агаңа күз тидергәннәр. *(Али морзаның кулыннан тотып китә.)*

Мөхәммәт морза *(башын иеп уйга кала, бераздан, башын күтәреп).* Ул ни әйтергә теләде икән? Мин ни күрәм, әниемнән ни ишетәм?

Ишетәм, күрәм, не могу понять!
Тәрбия бирә — что за мать?
Татар, морза — какая же разница?
Болар икесе дә бер милләт,
кажется.
Йә, ни өчен, ни өчен
мондый взгляд?
Ни өчен бер-берсен
презирать итәләр?
Юк! Довольно!
Вакыт инде уяныргa!
Татар белән морзаны кирәк
безгә кушарга.

Пәрдә төшә.

Дәвамы бар ■

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Шагыйрь Шәрәф Мөдәрриснең язучы Мирсәй Әмиргә фронттан язган хаты

«Мирсәй абый!

Сиңа дусларча кайнар сәлам җибәрәм. Исәнлек, саулык һәм иҗатыңда илһам телим. Безнең гаскәрләрнең уңышлы операцияләре белән котлыйм һәм якын арада син дә безнең фронттагы шатлыклы җиңүләребез белән котларсың, дип уйлыйм.

Бу хатны редакция эше белән алгы линияләрдә командировкада йөргәндә язам. Гомумән, яхшы. Газета өчен очерклар һәм хәбәрләр эшлим. Шигырь кебек әйберләр дә язам. «Александр Невский» һәм «Кызыл йолдыз» орденнары белән бүләкләнгән майор Үтәкәев турында поэма эшлим.

Минем сезгә карата бер шәхси үтенечем бар. «Хикмәтуллинның манёврда күргәннәре» дигән әсәрнең дәвамы иттереп, син «Хикмәтуллинның сугышта күргәннәре» темасына бик яхшы әйбер яза алыр идең. Ул безнең газета өчен гаять зур бер бай материал булыр иде. Хикмәтуллиннар фронтта да бар. Мылтыкка начар карау, разведкада яки оборонада үз-үзен тота алмау, противогаз һәм каскага төкереп карау (каска бик яхшы нәрсә, күп үлемнән яки ярадан коткара, кайберәүләр каска авыр һ.б., дип бәрәләр) дошманны якын ук җибәрергә кирәк булганда, үз-үзен тота алмыйча — командасыз ату һәм шуның белән эшкә кимчелек китерү, кисәкчә паникага бирелү... һ.б., һ.б. Кәлимуллин белән очраштырырга, һәм Кәлимуллинның снайпер булып, Хикмәтуллин белән ярышуын күрсәтсәгез... Гомумән, бик һәйбәт нәрсә эшләп була. Хикмәтуллин инде үзгәргән, аңардагы дошманга нәфрәт хисен дә, геройлыгын да бирергә кирәк. Стиле шул ук, күләме, әлбәттә, зур түгел. Дөресен әйткәндә, мин үзем бу әсәргә берничә мәртәбә кагылгаладым, соң язучы үзе «исән ләбаса», дидем дә хат язарга булдым.

Хатип беркөйгә яши. Менә ике атна инде, мин йөрим әле. Яңа елсыз кайтырга туры килми.

Нинди яңалыклар бар? Нәрсәләр өстендә эшлисез?

Мин синең радиокомитетта эшләвеңне белә идем, һаман да шундадырсың, дип уйлыйм. Көзен мин сезгә бер кочак шигырьләр җибәргән идем бугай.

Шунда бетерәм. Хәзергә хуш, Мирсәй абый. Хат көтәм.

Кабат сәлам белән: Шәрәф.

557 — полевая почта,
Часть 652,
Мударрисову Шарафу.
30/X 1942».

Төньяк-көнбатыш фронт. «Ватан өчен» газетасы хезмәткәрләре. Сулдан уңга: Нәфикъ Яһүдин, Габдулла Әхмәдиев, Хатип Госман, Гани Гыйльманов, Мирсәй Әмир, Шәрәф Мөдәррис. 1943 ел, апрель

Укучыбыз хаты

«Мөхтәрәм баш мөхәррир Ләбиб Лерон әфәнде!

«Безнең мирас» журналының быелгы май санындагы «Елъязма» сәхифәсендә шундый юлларга тап булдым:

«70 ел элек (1944) II Белоруссия фронтында татар телендә «Фронт хакыйкате» исемле газета чыга башлый».

Бу юлларны укыгач, тетрәнеп киттем. Чөнки әтием Нәфикъ Халик улы Яһудин ике ел бу газетада корректор булып эшләгән (очерклары, мәкаләләре дә басылып торган). Фронт газетасы татар телендә чыккан! Бу турыда исебезгә төшерүегез өчен шундый рәхмәтлемен. Ул газетаның бер нөсхәсе миндә дә саклана. Тик монда бәләкәй генә бер төгәлсезлек җибәрелгән. Бу газета 1942 елның июлендә «Ватан өчен» исеме астында Төньяк-Көнбатыш фронт газетасы буларак чыга башлый.

«Тормыш бу» исемле китабымдагы документаль повестьта әтиемнең фронт газетасында эшләгән чаклары турында да истәлекләре бар. Менә 46 нчы биттә: *«Безнең «Ватан өчен» исемле татар газетасында: редактор-майор Гани Гыйльманов, әдәби сотрудник-лейтенант Хатип Госманов, тәрҗемәче-капитан Габдулла Әхмәдиев, корректор булып мин һәм хәреф җыючы ике кыз (Федора һәм Зәкия) эшли башладык».* Соңрак редакциягә Шәрәф Мөдәррис алына һәм әти аның белән бик дуслашып китә.

1944 елда, Төньяк-Көнбатыш фронт II Белоруссия фронты итеп үзгәртелгәч һәм безнең гаскәрләр инде Ватан чиген үтеп чыгу сәбәпле, газетаның исеме дә «Фронт хакыйкате» дип үзгәртелә. Ә инде 1945 елның 9 маеннан шул ук газета «Җиңү байрагы» исеме астында чыга башлый.

Эшегездә уңышлар теләп: Марс Нәфикъ улы Яһудин,
Россия Язучылар һәм Татарстан Журналистлар
берлекләре әгъзасы.
Чаллы шәһәре. 26 май, 2014 ел.»

Редакциядән: Шәрәф Мөдәрриснең хатына өстәп, «Ватан өчен» газетасы хезмәткәрләренең фоторәсемен дә бирәчәгебезне Марс Нәфикъ улына хәбәр иттек. Ул исә, үз чиратында, кадерле ядкяр итеп саклаган фронт газеталарының фотокүчермәсен безгә юллады. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ВӘЗИРНЕҢ НИНДИ БУЛЫРГА КИРӘКЛЕГЕ ТУРЫНДА ҮГДЕЛМЕШ

Җавапта Үгделмеш әйтте: «И илбик,
Вәзир бәкләреңнән чыга, иң элек.

Вәзир шиксез кирәк була бийләргә,
Тыныч йоклый бий, ул булса әгәр дә.

Вәзир йөкләп ала бийләр бурычын,
Вәзир юлга сала алар кылмышын.

Вәзирлеккә бигрәк шәп бер ир кирәк:
Фәһемле, һиммәтле, ярсулы йөрәк.

Зиһене чишмәдәй, белеме — диңгез,
Ниләр эшләсә дә, ап-ак ачык йөз.

Уяулык, саклык хас, тугрылык аңар,
Вәзир яши алмас бер көн бихәбәр.

Бик сайларга кирәк аны — бик зур эш,
Ышанычлы кеше булырга тиеш.

Зирәк һәм белдекле булуы кирәк,
Эшлекле, булдыклы булсын ул бигрәк.

Вәзирлеккә бигрәк шәп бер ир кирәк:
Фәһемле, һиммәтле, ярсулы йөрәк.

Булдыклы уңганлык килә нәселдән,
Шулар коры калмас һичбер эшендә.

Фикерле һәм иман иясе булсын,
Аннан илгә файда тиясе булсын.

Фикерлеләр илдә сайланмыш кына,
Алардан һәр моңлы күңел хуш була.

Фикерле вәзир ул бик сак булучан,
Юньсезгә ягылмас һәм эш белүчән.

Ул илбиктән соң иң көчле хөкемче,
Эше-сүзе белән төп терәк кеше.

Ыргусыз кешеләр ардаксыз[1] булыр,
Андыйлар вәзиргә яраксыз булыр.

Ни ди, ишет, әнә инсафлы кеше
(Инсафлы кешедән чыга ил башы):

«Ару кешеләрнең холкы да затлы,
Кул бирер һәркемгә — ул халык яклы.
Арусыз кешеләр була инсафсыз,
Икмәгенә, кирәк, бал да май яксын».

Оятлы һәм күзе канәгать булсын.
Оятсыз кешедә ни мәгънә бар соң?

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санында басылып килә.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.
[1] Ардаксыз — тәртипсез, әхлаксыз.

Күзе тук булсын һәм хирысланмасын:
Күзе ач дөньяны йотып туймас ул.

Кешенең кямиле оятлы булсын,
Ояла белгәннәр ил башы булсын.

Оятлы кешеләр һәр эштә терәк,
Оятсызны кертмә — капканны терәт.

Оятсыз бәндәләр — адәм актыгы,
Оятсызның теле сөйләмәс тугры.

Ни ди, әнә, бер бик намуслы инсан
(Сине кисәтәдер мәрхәмәтле җан):

«Оятсыз кемсәдән ерак тор, ерак,
Ул бур булмаса да, күңленнән карак.

Бите күренсә дә, йөзе юк аның,
Ите күренсә дә, үзе юк аның».

Оятлы кешенең йөзе нурлыдыр,
Оятлылар үсәр — рухы зур булыр.

«Йөз күрекле булсын, тигез кырылган,
Халык үрнәк алсын кыланышыннан.

Кылмышы шәп булса һәм холкы уңай,
Шуннан файда булыр иленә тулай.

Тугры түгел икән эшләүче башчы,
Кәкре булыр төптән эше дә, бакчы.

Тугрылык — таныклык хезмәткәр өчен,
Аңар бәк ышанып тапшыра эшен.

Матур кеше эше күрекле булсын,
Матурлыгы илгә бер файда кылсын.

Йөзе, кыяфәте күрекле затның
Битенә ярашсын эчке сыйфаты.

Ни ди, ишет, кеше сынаучан кеше —
Яманны-яхшыны аерып күрүче:

«Чыраена чыга кемнең кемлеге,
Кыланышыннан ук мәгълүм күңеле.

Ыругсыз кешеләр ардаксыз булыр,
Андыйлар вәзиргә яраксыз булыр.

Эчтәлеккә китап тышлыгы таныкː
Һәр әйбәт китапка — лаеклы тышлык».

Кырынган, һәйбәтле булса вәзирләр,
Шундый вәзир эшне төгәл хәзерләр.

Хисап эшен белсен, булсын ул зирәк,
Язуның төрлесен белү дә кирәк.

Вәзир эше исәп-хисапка баглы:
Хисаплый белмәүче белән эш бармый.

Хисап илә эшнең рәте билгеле:
Анык булса елы, ае һәм көне.

Хисап белән исәп асылда бер сүз;
Исәпләп тә нишләр идең хисапсыз.

Ныклап уйламасаң, уңмассың эштә,
Эшләнә хисаплау белән һәр эш тә.

Язу илә бәндә терки белгәнен,
Язу аңар әйтә ниләр кылганын.

Язып барсаң айны, көнне-вакытны,
Эш бәхәссез була һәм хәл аныклы.

Булдыклы кешеләр була сәвәтле[2],
Сәвәтлелек юньле зат галәмәте.

Язуны белмәсә инсан угланы,
Белмәс иде, хәтта ел, ай, көн санын.

Акыл иядәре язмаса бетек,
Ничек эш итәргә дә белмәс идек.

Бу галәмне төзгән чакта Алла да
Язган ләүхел-мәхфүз дигән паллама[3].

«Бийләр сайласалар ниндирәк юллар,
Аларның эзеннән баралар коллар».

[2] Сәвәтле — укый-яза белүче, грамоталы.
[3] Ләүхел-мәхфүз — Аллаһы-тәгаләнең дөньяның киләчәген алдан билгеләп куелган китабы; паллама — проект.

**Бу галәмне төзгән чакта Алла да
Язган ләүхел-мәхфүз дигән паллама.**

Фәрештәләр язып бар кылмышыңны,
Ахирәт көнендә күрсәтер шуны.

Күңле йомшак кеше аздан шат булыр,
Шат кешеләр генә эшен булдырыр.

Ни ди берәү — ачык, алчак күңелле:
Йомшак күңеллелек — әйбәт, билгеле.

Сөекледер илгә күңел йомшаклык,
Сөексез һәркемгә катылык, ваклык.

Йомшак күңелләләр яшиләр озак,
Озак яшәмәбез без кырыс булсак.

Вәзирлеккә кирәк кямил, бөтен ир,
Укыган, акыллы булсын ул вәзир.

Теле-күңле бердәй, эшендә тугры,
Оятлы, шәфкатьле, кешенең чыны.

Ач күз түгел, эшкә ихлас бирелгән,
Кешедән кешене аера белгән.

Иманлы — гөнаһтан имәнә торган,
Хыянәт, алдаудан җирәнә торган.

Шушы фазыйләтләр булса кешедә,
Аны илбик куяр вәзир эшенә.

Әгәр шундый кеше булса бер вәзир,
Бийе дә, халкы да малга тиенер.

Теләгенчә барыр бийнең эшләре:
Халыкның баюы, илнең яшьнәве.

Тап булса ил юньсез явыз вәзиргә,
Бозылыр ил — бае, ярлысы бергә.

Вәзир әйбәт булу — халыкка шатлык,
Һәм илбикнең ашар ашы да татлы.

Ни ди берәү (дәрья чаклы белеме,
Гыйлем нуры белән тулган күңеле):

«Бийнең күңле-теле саф булса әгәр,
Һичкайчан хыянәт итмәс хезмәткәр;

Әгәр бийл булса бер холыксыз ахмак,
Аның ялчысы да тәртип бозачак».

Хуҗа яхшы булса, аның ялчысы
Холыклы, файдалы хәтта ки дусты.

Яхшы бине күрсәң, шуңарга бак син:
Яманнарны бер дә юлайтмас якын.

Яман әшнәләшә яманнар белән,
Иге зат, үзеңә иге дус телә!

Истә тот — гомуми бер канун-заң бар:
Начарга катылмас яхшырак затлар.

Кара төнгә ошап китмәс яктырту,
Кызу утка кунак булмас салкын су.

Белим, дисәң күңлен таныш түгелнең,
Таныш-белешеннән сора да белгел.

Һәрнәрсә тартыла үзе ишенә:
Төз булсаң, катылма кәкре кешегә.

Бу сүзнең исбаты — ошбу шигырьдә
(Аны ятла — киңәш булыр гомергә):

«Кара, күзәт барча җан ияләрен:
Очып, йөреп, йөзеп таба тиңнәрен.

Яхшы белән яман кушылмый, кача,
Бу гомуми канун, мәгълүм булганча.

Вәзир ил бийенә киңәшче була,
Бу ике киңәштәш тиң эшче була.

Катылма затсызга: кара халыкның
Яхшысы да бозгын, авыр холыклы.

Бийләр якын тотса яман кешене,
Яманатка калыр үзе, ил-көне.

**Тап булса ил юньсез явыз вәзиргә,
Бозылыр ил – бае, ярлысы бергә.**

[4] Көчлекче — көчләп эшләтүче.

Югарыда мәзкүр сыйфатлы вәзир
Бийен, илен рәхәт көнгә җиткезер.

Бий үз теләгенә тәмам ирешер:
Башкарылып килер бар булган эше.

Баер, ягъни, халкы, җан керер илгә,
Ишәер хәзинә, мал елдан-елга.

Калыр илбик мәңге ил хәтерендә,
Дан-абруе булыр олгайган көндә.

Шушы дөньяда вә теге дөньяда
Бәхетле булыр ул һәрчак кайда да.

ИЛБИКНЕҢ ТАГЫН БЕР СОРАВЫ

Илбик әйтте: – Оттым сүзең җелеген,
Бик акыллы сүзләр әйтелде бүген.

Хәзер әйт – ниндирәк булсын сәргаскәр,
Илбик хезмәтенә керсә ул әгәр.

Гаскәрне башкара – эшен эшләсә,
Һәм эшенә кара таплар төшмәсә.

Аңлат – моңа нинди кешеләр ярар;
Гаскәрне таркатса, булыр ич начар.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ГАСКӘР БАШЫ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘГӘНЕ

Һәм Үгделмеш әйтте: – Ил хөкемдары
Гаскәр туын[4] тотсын нык һәм югары.

Шундый булсын аның гаскәр башчысы –
Ярсыган дошманның дәртен бастырсын.

Бу эшкә бер корыч куллы ир кирәк:
Күпне күргән, мотлак сугышчан йөрәк.

Хәрби башлык үзе җаваплы бигрәк.
Максат — гаскәр төзеп дошманны җиңмәк.

Бийләр якын тотса яман кешене,
Яманатка калыр үзе, ил-көне.

Җиңел эш түгел җән, ил зур булса да,
Батырларың күптән ярсып тора да.

Сайланмыш ир кирәк монда – уяу, сак,
Гафиллек дигәннән торсын ул ерак.

Тәгин[5] алчак алпар булсын, юмарт кул,
Тоз-икмәге алда, холкы кунакчыл.

Юмарт булсын бик тә су[6] башлар кеше,
Җыелсын янына батыр-үз ише.

Ир-атка бар булган малын өләшсен –
Ишле булсын яудаш, кулдаш илдәше.

Үзенә тик бер пар ат-тун[7] калдырсын,
Кирәкми артыгы, бары дан булсын.

Угыл-кыз, хатынга мөлкәт җыймасын,
Йорт-җирем, багым дип, мал дип йөрмәсен.

Бар теләге булсын хәрби эшендә,
Дан өчен өләшсен ул үлҗәсен дә[8]

Сүвгә аш-су, кием табып, мул бирсен,
Яхшы ат-тун, үлҗә, чүре[9], кол бирсен.

Каһарманнар аңар җыелыр шулчак,
Җан кызганмый, яуда таулар ашачак.

Йөрәк булсын анда һәм зирәк булсын,
Киң күңел өстенә зур гайрәт булсын.

Сугышта кирәксез йөрәксез кеше,
Йөрәксез кеше ул хатыннар ише.

Йөрәксез солдатлар чирүне боза,
Бозылгачтын сафлар, бар гаскәр туза.

Ләкин батырлар да сабыр булсыннар,
Атлы һөҗүм килсә, нык-шып булсыннар.

[4] Ту, туг – гаскәрнең иң зур байрагы.
[5] Тәгин – хан нәселеннән билгеләнгән хәрби башлык.
[6] Сү-гаскәр, сү башлау, гаскәргә җитәкчелек итү.
[7] Ат-тун – «хәрби ат һәм корал-чорак, амуниция комплекты» (чаг., Ш.Маннурда атлы-тунлы кеше «тулы хокуклы, җитешле кеше»)
[8] Үлҗә – «трофей».
[9] Чүре – «әсир хатын-кыз». «Кудатгу билик»тә заманынча талау сәфәрләре идеологиясе чагыла. Бу деструктив идеология борыңгы төрки дәүләтләрнең зәгыйфьлеген билгеләгән.

Изгеләрне халык бик хөрмәт итә,
Ирекле кол булып та хезмәт итә.

Үлемнән калу юк – анык билгеле;
Тик вакытсыз килмәс батыр үлеме.

Ни ди күпне күргән йөрәкле яугир:
«Үлемен оныта, ир яуны җиңер.
Барыбер үлмәссең әҗәл килмичә,
Дошманны давыл һәм ут булып җимер».

Вакытлы тумыш зат вакытсыз үлмәс,
Нигә куркырга соң дошманны күргәч.

Оят-намус кирәк, гарь-намус өчен
Дошман белән көрәш, калмасын үчең.

Намуслы ир дошман сафын тарката,
Җәңдә[10] тәүләп гарьсез, намуссыз кача.

Намусланып гайрәт ала куркак та,
Үзенә кул сала батыр кайчакта.

Йөрәкле дигән ир намуслы булыр,
Гарьле кеше үлсә, сугышып үлер.

Кыланышы уңай, күңеле ачык,
Халыкка сөйкемле — менә бу холык.

Күңелне җылыта илгәзәк кеше,
Үзеннән биздерә яман теллесе.

Үзен бик тәкәббер тотса сүбаш ир,
Үз гаскәре, шиксез, җәзасын бирер.

Гафил ул асылда шундый «әре» ир.
Йә бозылачак ул, йә тиздән үлер.

«Алпар сылу, ирдәм, кырынган булсын,
Аның даны илгә ерак җәелсен.

Явыз дошманга ул дәһшәт салсын да,
Оялсын өлкәннәр, картлар алдында.

Сәясәткә оста булсын сүв башы,
Сәясәт ич аның ипие-ашы.

Сәясәт йөретсә, гаскәр низамлы,
Чирү күндәм булса, бар да тәгамьле.

Каю сүв низам һәм тәртип белмәсә,
Бозыла ич гаскәр, илбик, мең яшә.

Яманга карата сәясәт кирәк,
Яхшыга игътибар һәм хөрмәт кирәк.

Изгеләргә тиеш төгәл изгелек,
Аларны сөендер, йөкләмә күп йөк.

Изгеләрне халык бик хөрмәт итә,
Ирекле кол булып та хезмәт итә,

Ни ди, ишет, әнә берәү – холкы хуш
(Бу бәетне аңлап укырга тырыш):

«Бул азат кешеләр, изгеләр колы,
Изгелек кылып, ач тугрылык юлын.

Кешелек кыл, һәрчак кеше бул үзең,
Шулай инсанлыкның төзе нигезен».

Сүв башына кирәк берничә алым,
Белсә, сүвне бик тиз тәртипкә салыр.

Сугышта арыслан йөрәкле булсын,
Орышта юлбарыс беләкле булсын.

Дуңгыз кебек ертлач, бүредәй көчле,
Аюдай хәйләкәр, кутаздай[11] үчле.

Кызыл төлке кебек хәйлә белсен ул,
Дөя иркәгедәй үҗәт булсын ул.

Саесканнан саграк тотсын ул үзен,
Карчыгадай ерак күрәлсен күзе.

Көр арыслан кебек һәйбәтле йөрсен,
Сакта, өке кебек, төнлә дә күрсен.

Шулай булса егет гаскәри була,
Яубашы, гаскәрнең алпары була.

Сугышта арыслан йөрәкле булсын,
Орышта юлбарыс беләкле булсын.

[10] Җән – «бер сугышу эпизоды».
[11] Кутаз – кыргый як (Үзәк Азия таулыкларында яши торган куәтле мөгезле хайван) – борынгы төрки телдә, төрки фольклорда җиңелмәс көч символы.

Кораллы сугышчы кеше шундыйдыр:
Дошманны җиңәр һәм үчен кандырыр.

Тозы — икмәге[12] һәм ашы киң кирәк,
Аты, тун-тулымы аңа тиң кирәк.

Ашау-эчү, сые җәер ир данын,
Ашау ич яшәүнең дару-дәрманы.

Ни ди Илинең бер атаклы бие[13]:
«Тоз-икмәк муллыгы — кеше абруе;

Ат-шөһрәт теләсәң, ашат тоз-икмәк,
Яшәргә теләсәң, ашат син күбрәк».

Кешелек кылучан намуслы затлар
Тоз-икмәк хакы дип, ир хакын хаклар.

Олылык теләсәң, аш-суың өләш,
Озын кул[14] теләсәң, булыр аш белән.

Хыйл[15] башына кирәк берничә сыйфат,
Шулар булса эше барыр бик ансат.

Беренчедән, сүзе дөрес, чын булсын:
Алдаса, ышанмас беркем соңынтын.

Икенчедән, юмарт булу бик кирәк,
Саранны сөймиләр – шуннан ал гыйбрәт.

Өченчедән, яуда тау булсын күкрәк.
Чирлегә сабышыр, яу күрсә, куркак.

Дүртенчедән, дошман мәкерен таны:
Бер мәкер җиңәр, ди, мең арысланны.

Фәһем кирәк сүвне тибендерергә[16]
Вә дәрт – яугирләргә илһам бирергә.

Шул ирдәмгә ия булса сүв башы,
Югалтыр гайрәтен һәр каршыдашы.

Фәһем кирәк сүвне тибендерергә
Вә дәрт—яугирләргә илһам бирергә.

Сүв башы шул рәвеш хәрәкәт кылса,
Аның кулы уйнар сугыш кырында.

Һөҗүм чорларында чын сүв башчысы
Уяу торыр көн-төн, хәтта йокысыз.

Чирү күп кирәкми, сыйфатлы булсын,
Ул әйбәт кораллы, шәп атлы булсын.

Кыен зур чиругә башчылык итү;
Башлыксыз калган сув – куркак бер көтү.

Сыналган сәргаскәр генә сер бирмәс,
«Унике меңлек сүв миңа күп», димәс.

Җиңеп кайткан бик шәп бер алпар әйткән:
«Миңа дүрт меңлек бер гаскәр дә җиткән».

Сүв артык җыелса, эчтән таркала,
Идарә итәргә яраксыз кала.

Данлыклы бер алпар, ишет, ни диер:
«Яугирне сайлап ал, сүвгә тулым[17] бир».

Ни ди атаклы бер яугир дә, ишет
(Бу сүзне ишеткәч, үзеңә иш ит):

Ишле яу теләмә, шәп яугир телә,
Шуңа шәп тулым-тун һәм ат әзерлә.

Әйбәт аз яхшырак начар күптән, күр,
Кыенлык ишәя, гаскәр булса күп.

Һөҗүмгә атланып киткән чагында
Сүбаш башлыкларын тотсын янында,

Сайлап билгеләргә йәзәк[18], тоткакны[19],
Еракка юнәлтеп күз һәм колакны.

Дәвамы киләсе санда

[12] Йосыф Баласагуни һәрдаим тоз-икмәк дип яза, икмәк-тоз түгел.
[13] Или бие — Или [Кыргызстан һәм Көньяк Казахстандагы бер елга], Или — бик абруйлы бер хөкемдәр. Аның турында КБ-тә (*«Кутадгу билик»тә)* күп тапкыр әйтелә.
[14] Озын кул – КБ телендә «абруй, хакимлек».
[15] Хыйл – «отряд, рота». Хыйл башы — «старшина, гаскәрдә көндәлек эшләрдә җитәкче».
[16] Казан татар сөйләшләрендә дә тибенү — «тырышу, омтылу, ыргылу».
[17] Тулым – обмундирование, корал һ.б. (тулым төп мәгънәсендә — «юл капчыгы»)
[18] Йәзәк – «дозор», шулай ук «сакчы гвардия» (йәзмәк «карап йөремәк).
[19] Тоткак – «тел тотып алучы, разведчик».

АСЫЛ ШИГЫРЬ ЮГАЛМАС!

(Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты турында яңа материаллар)

Әнвәр Шәрипов

Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834) – әдәбиятыбыз һәм иҗтимагый фикер тарихында тирән эз калдырган шәхес, энциклопедик белемле галим. Аның күпкырлы иҗади мирасын өйрәнү XIX гасырның II яртысыннан башланып, бүгенге көнгә кадәр дәвам итә.

Сәмәрканд шәһәренең Регистан мәйданында. Гәбдерәхим Утыз Имәнинең дүртенче буын оныклары белән.
Сулдан уңга: Халит Әхмәтҗанов, Әнвәр Шәрипов, Мигъдәт Әхмәтҗанов. 1988 ел, сентябрь

Урта гасырларда яшәп иҗат иткән шагыйрь һәм әдипләрнең әсәрләре, билгеле булганча, кулъязма рәвешендә барлыкка килгәннәр. Ул кулъязмалар әлеге шәхеснең яки үзендә сакланган яки, башка кешеләргә таралып, шул кешеләр кулында калган. Әлеге шагыйрь яки әдипнең иҗат мирасын ачыклау өчен, әлбәттә, ул кулъязмаларны эзләргә, табарга һәм фәнни әйләнешкә кертергә кирәк. Г.Утыз Имәни әсәрләренең кулъязмаларын барлау, аларны өйрәнү, халкыбызга кире кайтару өлкәсендә дә моңа кадәр шактый гына эшләр эшләнде. Утыз Имәнинең Казан университетының фәнни китапханәсендә саклана торган кулъязмаларының тасвирламасын 1968 елда Альберт Фәтхи, ә Санкт-Петербургның Көнчыгышны өйрәнү институтындагы кулъязмаларының тасвирламасын 1980 елда Л.В.Дмитриева бастырып чыгарды. Ә 2005 елда Марсель Әхмәтҗанов Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Мирасханә»сендә саклана торган кулъязмалар тасвирламасын бастырды; анда Г.Утыз Имәни фондындагы кулъязмалар да тасвирлана.

XX гасыр дәвамында галимнәр Г.Утыз Имәнинең иҗат мирасыннан нигездә аның шигъриятен аерып алып өйрәнделәр, аның татар поэзиясенә керткән өлешен, татар әдәбияты тарихындагы урынын ачыкларга омтылдылар. Бу өлкәдә XX гасыр дәвамында ике кандидатлык диссертациясе — Үлмәс Беляеваның «Утыз Имәни поэзиясе» (1948) һәм Әнвәр Шәриповның «Габдерәхим Утыз Имәнинең иҗат мирасы һәм аның поэзиясендә дөньяви мотивлар» (1973) дигән хезмәтләре якланды. 2005 елда Мәсгуд Гайнетдин үзенең «Габдерәхим Утыз Имәни» дигән фәнни хезмәтен бастырып чыгарды.

Соңгы елларда Утыз Имәнинең дини-фәлсәфи мәсьәләләргә багышланган, саф гарәп телендә язылган трактатларын өйрәнү, аларны анализлау һәм халыкка яңадан кайтару өлкәсендә дә

бик әһәмиятле эшләр эшләнде. Фәлсәфә фәннәре докторы Айдар Юзиев 1998 елда үзенең ике кисәктән торган «XVIII гасыр ахыры — XIX гасыр татар фәлсәфи фикере (эволюциясе, төп юнәлешләре, вәкилләре)» дигән монографиясен бастырды; анда Утыз Имәнинең дә динифәлсәфи фикерләре анализланды, кайбер дини трактатларыннан өзекләр рус теленә тәрҗемә итеп бирелде. 2005 елда Рамил Әдһәмов Утыз Имәнинең динифәлсәфи трактатларын анализлаган «Габдрахим Утыз-Имяни» дигән монографиясен рус телендә бастырып чыгарды һәм 2006 елда, шул хезмәт нигезендә, «Роль Габдрахима Утыз-Имяни в изучении социокультурных и религиозных традиций татарского общества конца XVIII — первой трети XIX вв.» дигән темага диссертация яклады. Ә 2007 елда ул «Антология татарской богословской мысли» сериясендә Г.Утыз Имәнинең дини эчтәлектәге тугыз трактатын рус теленә тәрҗемәләп, бер том итеп бастырып чыгарды. Бу хезмәтнең кыйммәтен һәм әһәмиятен, безнеңчә, бәяләп бетергесез. Рамил Әдһәмов монда күп галимнәрнең «теше үтә алмаган» эшне башкарган: Утыз Имәнинең дин, шәригать, фикъһе, суфичылык турындагы саф гарәп телендә язылган зур күләмдәге кулъязма һәм басма трактатларын рус теленә җентекләп тәрҗемә

итеп кенә калмаган, ә аларга аңлатмалар да биргән. Моның өчен, әлбәттә, урта гасырлардагы дин галимнәре күтәргән мәсьәләләрне тирәнтен белергә, шул чорның атмосферасына керергә, аны тоярга-сиземләргә кирәк. Шунысы шиксез, бу хезмәте белән Рамил Әдһәмов урта гасырларны өйрәнү өлкәсенә үзеннән гаять зур өлеш кертте.

Г.Утыз Имәнинең шигърият өлкәсендәге иҗади мирасы, фәнни өйрәнелеп, билгеле булганча, 1986 елда «Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар» дигән бер томлыкта басылып чыкты. Анда шагыйрьнең 1980 елларда билгеле булган әсәрләре тупланган иде. Әмма бу китапта Утыз Имәнинең бөтен шигъри әсәрләре дә дөнья күрде, дип әйтеп булмый. Төрле сәбәпләр (атрибуциясе ачыкланып җитмәү, фарсы теленнән тәрҗемә ителмәү яки әле билгеле булмау) аркасында, бу җыентыкка әлеге авторның кайбер әсәрләре керми калды. Бу мәкаләдә сүз әнә шулар, Утыз Имәни иҗатына кагылышлы яңа мәгълүматлар турында барачак.

Утыз Имәни шигъри әсәрләренең бер томлыгына керми калган әсәрләр арасында, безнеңчә, аеруча ике поэма әһәмиятле һәм кыйммәтле: берсе — «Җенахел-фәлях фи зәмми мөбах» («Мөбахны шелтәләү — котылу юлы»), икенчесе — «Дөррәтел-фахирә яки ахирәтнамә» («Мактаулы энҗе яки ахирәт турында») поэмасы.

Иң элек **«Җенахел-фәлях фи зәмми мөбах»** поэмасына тукталыйк. Бу — дини-фәлсәфи эчтәлектәге әсәр, шагыйрьнең дини-әхлакый, фәлсәфи карашларын чагылдыра.

Мөбах ул — шәригать тарафыннан тыелмаган да, кушылмаган да эш-гамәлләр, ягъни эшләсәң савап та, гөнаһ та булмый торган гамәлләр. Аларны эшләү — кешенең үз ихтыярында. Утыз Имәни бу әсәрдә кешеләрнең шул мөбах эш-гамәлләр белән артык мавыгып китүләрен, шул мавыгулары аркасында үзләрендә хайвани сыйфатлар булдыруларын, комсызлыкка бирелүләрен тәнкыйтьли.

Дүрт сыйфатлә тәркиб улмышсән,
әй йар,
Һәрберендин чук сыйфат
сәндин тугар.
Бонлари белсәң, белүрсән халеңи,
Аңлайурсән никү-бәд әхвалеңи, — ди шагыйрь поэманың баш өлешендә.

Юлга-юл тәрҗемәсе:
Дүрт сыйфат белән барлыкка
килгәнсең син, и дус,
Аларның һәрберсеннән синдә күп
сыйфатлар туар...
Боларны белсәң,
белерсең үз хәлеңне,
Аңларсың яхшы-яман әхвалеңне.

Тумыштан ук һәр кешедә була торган шул дүрт сыйфатны болай аңлата:
Бәс, ишет ул дүрт сыйфатлар
нә имеш,
Берсе сәбгый, берсе шәйтани имеш.
Берсе бәһими, берсе раббани ирүр,
Бу сыйфатлар даимән сәндә йүрүр.
Һәрберинең тәэсире булмыш сәңа,
Кайсы йулга өндәйүр, кайсы йаңа.
Һәрберине әйтәен, дыңлар исәң,
Дыңлайуб, сүз мәгънәсен
аңлар исәң, — ди.

Юлга-юл тәрҗемәсе:
Инде ишет, ул дүрт сыйфат
нәрсә икәнен,
Берсе ерткычлык,
берсе шәйтани икән.
Берсе хайванлык,
берсе илаһи (раббани) булыр.
Бу сыйфатлар һәрвакыт
синдә йөрер.
Һәрберсенең тәэсире булыр сиңа,
Кайсы юлга өндәр сине,
кайсы — читкә.
Һәрберсен әйтәм сиңа, тыңласаң,
Тыңлап, сүз мәгънәсен аңласаң.

Шуннан шагыйрь дәвам итә:
Ул газыб кем,
сәбгый васфың сәндә вар:

Зарб-у-шәтем,
богъз-у-кин андин дугар.
Баз, икенче васфың ул шәйтанидур,
— Мәкр-ү-хәйлә вә хидагъ
андин улур.
Өчүләнчи, ул бәһаим васфидур, —
Йимәк-әчмәк,
шәбгъ-у-хирс андин улур.
Дүртүләнчи васфың ул рәббанидур
Гыйльм-у-хикмәт,
гакл-у-һуш андин кәлүр,
Адың инсан улдисә, и болфозул,
Улды мәүҗүд сәндә
ошбу дүрт осул.

Тәрҗемәсе:
Ул ачулану-ерткычлык
сыйфаты синдә булса,
Сугу һәм сүгү, дошманлык
һәм үч саклау аңардан
туар.
Күр инде, икенче сыйфатың
ул шәйтанидыр,
Мәкер белән хәйлә һәм
алдау аңардан килә.
Өченче сыйфат —
ул хайванлыктыр,
Ашау-эчү, тыгыну һәм
комсызлык аңардан булыр.
Дүртенче сыйфат —
ул илаһилыктыр,
Гыйлем һәм хикмәт,
акыл һәм аң аңардан килер.
Исемең кеше булса синең,
и фәһемсез,
Синдә шушы дүрт башлангыч
бар булыр.

Шагыйрь кешеләрне беренче өч сыйфатка — ерткычлык, шайтанлык һәм хайванлыкка бирелмәскә, ә дүртенче сыйфатка — илаһилыкка бирелергә чакыра:
Гаклә вирүлде —
тәмиз хакимдур ул,
Хаккы-батыйль белмәгә
камилдур ул.
Акылга бирелгән кеше —
саф хаким ул,
Хаклыкны-ялганны
белүдә камил ул.

«Акылга бирелгәндә, — ди Утыз Имәни, — кешедәге беренче өч сыйфат эндәшми, тын гына торалар». Ә илаһилык сыйфатын ул кешедәге барлык яхшы сыйфатларның нигезе дип атый:
Васфы раббани ки сәндә вар иде, —
Җөмлә бу әүсафларың аслы иде.
Җәннәтнең йулы сәңа ачык иде,
Нәфс-ү-шәйтанның йулы
качак иде.

Тәрҗемәсе:
Әгәр синдә илаһи сыйфаты
булса, —
Ул — бу сыйфатларның
нигезе торыр.
Җәннәтнең юлы сиңа ачык иде,
Нәфес һәм шәйтанның
юлы ябык иде.

Автор кешеләрдәге начар сыйфатларның акылны җиңәргә мөмкин икәнлеген искәртә, акылны начар сыйфатлардан җиңдерүне теләми, аңардан сакланырга өнди:
Гаклы мәгълүб әйләдеңсә нәгяһан,
Кишвәрәтеңдә качан калур әман?
Золм-у-хаинлык белән пор
улды тән,
Җөмлә әгъзаларыңа йитде михән.

Тәрҗемәсе:
Әгәр көтмәгәндә акылың
җиңелеп калса,
Бөтен тәнеңдә нинди иминлек
калыр?
Тәнең җәбер һәм хыянәтлек
белән тулыр,
Барлык әгъзаларыңа михнәт килер.

Шуннан соң поэмада, алда әйтелгән һәр өч начар сыйфатның чыганагы ул — мөбахка бирелү, диелә. Мөбахка бирелүнең нинди начарлыкларга китерүе сурәтләнелә:
Бел, мөбахдүр ул
хәрамның рәһбәре,
Качды андин җөмлә
гакыйль дин ари.
Бу мөбахдүр күпләри идән һәлак,

Мәгърур итди та
керәнчә зире хакъ.

Тәрҗемәсе:
Бел, мөбах ул —
хәрам эшләр җитәкчесе,
Бөтен акыллы кешеләр
аңардан качты, дин эзләп.
Бу мөбах күпләрне
һәлак иткән нәрсә,
Кабергә кергәнче аларны
горур итеп тотты ул.

Әсәрнең калган өлешен шагыйрь мөбахка бирелүнең кешене нинди хурлыкларга төшерүен сурәтләүгә багышлый. Бу поэманың барлыгы өч кулъязмасы билгеле. Аларны без үзара чагыштырып чыктык, чагыштырма-тәнкыйди текстын төзедек, хәзерге әдәби телгә юлын-юлга тәрҗемә итеп чыктык.

Икенче поэма «Дөррәтел-фахирә яки ахирәтнамә» — зур күләмле әсәр, 1456 юлдан тора. Анда кеше үлгәч булачак вакыйгалар, теге дөньядагы хәлләр, кыямәт көне һ.б.лар турында сөйләнә. Альберт Фәтхи күрсәтүенчә, Утыз Имәни аны Мөхәммәт әл-Газзалиның «Дөррәтел-фахирә фи кәшфе гомумелахирә» («Ахирәт хәлләрен ачу юлында хөрмәтле энҗе») исемле әсәреннән файдаланып язган.

Әсәрнең эчтәлеген аның нинди бүлекләрдән торуыннан чыгып та күз алдына китерергә мөмкин. Әсәрдә түбәндәге бүлекләр бар:

1) Кереш өлеше. Анда һәр кешегә үлем киләчәге, һәркемнең кабергә керәчәге турында сөйләнелә. Үлем килүен шагыйрь болай сурәтли:
Тотар аны йакадин нәгаһани,
Йыкар йиргә идеп
мәкъһүр вафани...
Түшәкендә йатан ул һәм фирашың
Калыр тәнһа ки
гүргә керсә башың...
Мосаффа ул көмешдик ак бәдәнләр,
Төшәр тупрак эчигә сим тәнләр.
Мөҗәүһәр зөлефле пакъ-ак йөзләр,
Шәкәрдин һәм зиядә
татлы сүзләр —
Улыр гүрдә мөләүвәс хакъ-у-хашак,
Череп китсә,
улыр мисле сийаһе хакъ.

Юлга-юл тәрҗемәсе:
Тотар аны якадан көтмәгәндә,
Җиргә егар аны һәлак итеп,
ныклык белән...
Түшәгеңдә яткан улың
һәм хатының
Ялгыз калырлар,
әгәр гүргә керсә башың...
Көмеш кебек саф, ак гәүдәләр,
Туфрак эченә төшәр көмеш тәннәр.
Җәүһәрдәй чәчле пак-ак йөзләр,
Шикәрдән дә татлырак
матур сүзләр, —
Кабердә барысы пычраныр
туфрак һәм шакшылык белән,
Череп китсә, кара туфрак
төсле булыр...

Автор бу үлемнән һичничек тә котылып булмавын искәртә:
Бере кыйлмаз вафаны, килсә үлем,
Ушандакдыр бу галәм хале мәгълүм.

Тәрҗемәсе:
Беркем ярдәм итә алмас,
үлем килсә,
Бөтен галәм халкының
хәле шулай булыр.

2) Беренче баб. Үлгән кешегә зикер әйтүнең файдасы турында.

3) Икенче баб. Һичкайчан үлмәм, дип дөнья куып йөрү һәм аның зарарлы булуы турында. Бу бүлек үзе ике бүлекчәгә бүленә: а) дөнья куып йөрүнең сәбәпләре турында. Монда шагыйрь кешеләрнең дөнья куып йөрүләрен тискәре күренеш итеп тасвирлый һәм аңа бирелүнең ике сәбәбен күрсәтә:
Әмәлнең тоулегә ике сәбәп вар:
Берeдер — хөббе дөнья, әй борадәр.
Дәхи берсе җәһелдер, улгыл агяһ,
Гыйлаҗен эстәгел шам-у-сәхәргяһ.

Тәрҗемәсе:
Дөнья куының ике сәбәбе бар:
Берсе — дөньяны сөюдер,
и туганкай.

Тагын берсе — наданлыктыр,
сак бул син,
Аның даруын эзлә
кичтән алып таңга кадәр.

б) икенче бабның икенче бүлеге дөнья куучыларның нинди эш-гамәлләр белән мәшгуль булулары турында.

4) Өченче бабта үлем ачысы сурәтләнә. Шагыйрь аны болай тасвирлый:

Үлемнең шиддәтен
тел әйтә белмәс,
Юлыкган адәмиләр телгә килмәс…
Кылыч зарбы ки
өч йөз төшсә башә,
Үлемнең шиддәтен бел андин аша.

Ягъни, үлемнең катылыгын шуннан бел, әгәр башыңа бер үк вакытта өч йөз кылыч килеп төшсә, үлем ачысы аңардан да катырак булыр, ди шагыйрь.

Өченче баб — поэманың иң зур бүлекләренең берсе. Аның эчендә кешеләрнең ничек, ни рәвешле үлүләре турында дүрт хикәят китерелә.

5) Поэманың иң зур бүлеге — дүртенче баб. Ул үзе аерым мөстәкыйль поэма булып каралырга мөмкин. Аның эчендә 5 бүлекчә, 13 бәян бар. Баштагы бүлекчәләрдә Мөхәммәт пәйгамбәрнең, аннан соң Әбүбәкер, Гомәр, Госман һәм Галинең үлемнәре сурәтләнә. Шуннан соң түбәндәге бәяннар китерелә: 1) кабергә күммәк бәяны; 2)Мөнкир һәм Нәнкирнең сорау алулары; 3)кыямәт көнендә Исрафил фәрештәнең сур (быргы) өрүе; 4) кыямәт көнендәге башка вакыйгалар турында; 5) кыямәт көнендә соралачак сораулар турында; 6) гөнаһларны һәм савапларны үлчәү; 7) сират күпере турында; 8) Алланың шәфкате турында; 9) җәннәт чишмәләре турында; 10) җәһәннәмне тасвирлау; 11) җәннәтне тасвирлау; 12) җәннәттәге ашамлыклар турында; 13) хур кызлары һәм җәннәт хезмәтчеләре турында. Шуннан соң хатимә, ягъни бетем өлеше килә.

Шулай итеп, «Ахирәтнамә» поэмасы



Лениногорск районы Тимәш авылындагы Габдерәхим Утыз Имәни кабере өстенә 1994 елда, шагыйрьнең тууына 240 ел уңае белән Татарстан нефтьчеләре төзегән мавзолей

шагыйрьнең дини-фәлсәфи карашларын ачыклау җәһәтеннән зур әһәмияткә ия.

Утыз Имәни шигъри әсәрләренең бер томлыгына керми калган әсәрләр арасында шагыйрьнең тагын «Ишаннар һәм суфилар» исемле шигыре дә бар. 42 юллы бу шигырьне тел һәм әдәбият галиме Латыйф Җәләй 1938 елда урта мәктәпләрнең 8 класс укучылары өчен чыгарылган «Әдәбияттан хрестоматия» дигән китапта Утыз Имәни әсәре дип бастырган (39-40 бб.). Бу шигырьнең кулъязма варианты әлегә очрамады. Л.Җәләй, бу шигырьне безгә билгеле булмаган кулъязмага нигезләнеп, Утыз Имәни әсәре дип тәкъдим иткән булса кирәк. Язылу стиле һәм әсәрдә кулланылган гарәп-фарсы алынмаларының уртаклыгы һәм охшашлыгы безгә бу шигырьне чыннан да Утыз Имәни әсәре дип карарга нигез бирә. Түбәндә шул шигырьнең тексты китерелә.

Ишаннар һәм суфилар
Ялган ишан үзен-үзе вәли саныр,
Шөһрәтләнеп,
надан ишан мөрид алыр.
Рәхәт ятып горбәт тапкан
каян чыккан,

Бу ниндәен мут, наян,
шаян чыккан.
Нәфсен тыймас бәдбәхет,
надан чыккан,
Җәмгы мал өчен зур хәйлә
тапкан имди.
Өмәраларга, түрәләргә
юлдаш булып,
Һәм алар мәҗлесендә
сохбәт булып,
Гыйззәт-горбәт иясе
түрдәш булып,
Ничек корбәт тормага лаек имди.
Нәфсесенең морадынча
булган белән,
Суфилар дик башны
түбән куйган белән,
Сырхауларга дару кыйлып
торган белән
Ничек корбәт тормага кәрәк имди.
Шәһавәттә тукларны җыйган
берлән,
Байлар килсә, самоварын куйган
берлән,
Нигъмәтени туклар йиеп туйган
берлән,
Җәмгы малга бу шәбәкә
белең имди.
Кил газизем, тәүфыйклы ике
күзем,
Кальбеңә салыр булсаң
бәнем сүзем,
Гасыйлардан булсам да гәрчә үзем,
Китапларда күренсә кәрәк имди.
Мөрид булып кул бирерсән
батыйль пиргә,
Үз-үзеңне белә алмазсән нә дияргә,
Хак белерсән, китә алмазсән
бүтән йиргә,
Батыйльлектә гомрең
заигъ үтәр имди.
Һәрбер хальдә
бер-берене мәдехләрләр,
«Әҗнәби» дип
гайреләрне кабихләрләр,
Кадер-гыйззәт
кыйлмаганны кабихләрләр,
Хосусән бирмәгәнне
сәүмәзләр имди.
Йөргән йирдә байларны күзәтерләр,
Пәрһизләр дик кара төшен
төзәтерләр,
Баеракларны тәмгы берлә
йөдәтерләр,
Пәрһизлекне мал өчен
кыйлырлар имди.
Йөргән йирдә керерлек
җайлар булса,
Күмәч илә ашарга майлар булса,
Һич таһәрәт күрмәгән
байлар булса,
Мәҗлесләрдә аны мәдех
идәрләр имди.
Бу нөсхәне юлыкып укырсаңыз,
Гаҗәбрәк сүзләреми ялкырсаңыз,
Гаепләре качан чыкмаз,
чыкарсаңыз,
Гаеп итмәгән гыйбрәтләнсә
кәрәк имди.

Утыз Иманинең 1986 елгы шигырьләр җыентыгына кермәгән тагын берничә әсәрне күрсәтеп үтик.

1. «Ки дәрйалар мидад улса…» шигыре. Бу әсәрнең тексты 1973 елгы археографик экспедиция вакытында шагыйрьнең туган авылы Яңа Кадидә яшәүче 90 яшьлек Суфиян бабай Исхаков сөйләвеннән шушы юлларның авторы тарафыннан язып алынды. Суфиян бабай аны «Габдерәхим хәзрәт шигыре» дип тәкъдим итте. Шушы ук шигырьне 1976 елның җәендә археография экспедициясе вакытында Габдерәхим хәзрәт бер ел мәдрәсәдә укытып киткән икенче бер авылда — Чистай районының Исләй авылында яшәүче 94 яшьлек Нурулла бабай Хәлилов та «Габдерәхим хәзрәт шигыре» дип, күңелдән әйтеп бирде. Кульъязма күчермәләре очрамый.

Ки дәрйалар мидад улса,
Каләм андин йазар улса, —
Бәхер мохитъ ула тәмам,
Илһам әрхам тәгълим вирсә.

Тәрҗемәсе:
Гәр елгалар чыганак булса,
Каләм аннан язар булса, —
Хәтта океан кибеп бетәр,
Илһам чишмәсе агып торса.

2. «Мәкямлылар миһманлашыр тиңле-тиңгә» исемле ике юллык шигырь.

Бу шигырь текстын исә 1970 елгы археографик экспедиция вакытында Башкортстанның Дәүләкән районы Мерәс авылында яшәүче аксакаллар авызыннан язып алган идем. Авыл картлары аны «Габдерәхим хәзрәт шигыре» дип сөйләделәр.

Мәкямлылар миһманлашыр
тиңле-тиңгә,
Ә фәкыйрьләр карап торыр
моң-зар булып.

Тәрҗемәсе:

Бай кешеләр кунакка
йөрешер тиңле-тиңгә,
Ә фәкыйрьләр карап торыр
моң-зар булып.

3. «Дийаре горбәтә дөшеп...» шигыре.

Бу шигырь Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Хорасанинының «Җәмигъ әр-ромуз» әсәренә Утыз Имәни төзегән гарәпчә-фарсыча сүзлекнең ахырына язып куелган. Бер кулъязмасы билгеле — ул «Мирасханә»дә саклана: колл. 39, тасв.1, с.б. 133, 31 б биттә. Күчерүчесе — Утыз Имәнинең кияве Әхмәтҗан бине Шәмсетдин. Шигырьнең эчтәлеге һәм гомуми рухы аны Утыз Имәни каләменә нисбәт итәргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, *«Кеше хөсне ризасилә чыкыб тәрке дийар итмәз»* һәм бигрәк тә *«Кеше кем кабил улурмы җөда улмага йарындан»* кебек гыйбарәләр шагыйрьнең биографиясендәге вакыйгаларга бик тәңгәл килеп торалар.

Дийаре горбәтә дөшеп,
кеше шаһ улмады даим,
Кинә кәнд дийарендә
гәр улмасы әфзалдур.
Кеше хөсне ризасилә
чыкыб тәрке дийар итмәз,
Сәбәпсез горбәтүн-каһрун
үзигә ихтыйар итмәз.
Кеше кем кабил улурмы
җөда улмага йарындан,
Кидәрме ихтыйар илә кеше
кәнде дийарендән?

Тәрҗемәсе:

Иленнән аерылып кеше беркайчан
шаһ була алмады,
Чөнки һәркемгә үз илендә булу
кадерлерәк.
Бер кеше дә үз теләге белән илен
ташлап китмәс,
Сәбәпсез читкә китү авырлыгын
үз-үзенә теләмәс.
Кем, кайсы кеше риза булыр иде
аерылырга үз йарыннан?
Китәрме үз ихтыяры белән кеше
үз туган иленнән?

Шагыйрьнең бер томлыгына кермәгән тагын ике әсәре бар: аларның икесе дә рифмалы проза (сәҗегъ) белән язылганнар. Аның берсе — **«Нәшер эт-тәкъриб»** («Аллага якынаюны тарату») дип атала. Барлыгы 287 юл. Әсәрдә беркадәр автобиографик моментлар да чагылып ала. Мәсәлән, әсәрнең ахыргы өлешендә автор болай ди:

Әгәрчә «Сәеф сарим» бителде[1]
Лик лөгате фарсы улды.
Тел белмәз төркиләр мәхрүм калды.
Анлар өчүн «Гавариф эз-заман»
мәнзум улды[2]
Соңра бу «Нәшер эт-тәкъриб»
аңа шәрех кеби улды.

Икенчесе — «Бу бер нөсхә ләтыйфдур...» дигән әсәр. Бер кулъязмасы билгеле — «Мирасханә»дә саклана: колл. 39, тасв. 1, с.б. 45, 1а-3б битләр. Текстның баштагы һәм ахыргы өлеше югалган. Сакланган кадәресе — 156 юл. Әсәрдә үз заманындагы яман гадәтләр — наданлык, алдакчылык, икейөзлелек һ.б. сыйфатлар тәнкыйтьләнә.

Зур күләмле булулары аркасында, бу әсәрләрне әлеге мәкалә эчендә анализлау мөмкинлеге юк. Аларның әдәби кыйммәтен һәм сәнгатьчә эшләнешен анализлау — аерым мәкалә темасы. ■

1 Бителде — язылды.
2 Мәнзум улды — тезмә белән язылды.

«АНА КҮҢЕЛЕ ДӘ ИРЕШМӘСЛЕК ЕРАКЛАРГА КИТЕП БАРЫШЫМ...»

Рөстәм Акъегет

Бу юллар безнең белән бик иртә хушлашкан шагыйрь Зиннур Насыйбуллинның иң соңгы шигыреннән. «Ана күңеле дә ирешмәслек еракларга» – ул, җиргә әкрен генә сыенган көзге яфрак кебек, тын гына, тып-тын гына китеп барды.



Минем Зиннур белән беренче очрашуым 1974 елның июнь ахырында булды. Әле университет белән бөтенләй үк араны өзеп бетермәгән килеш Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә урнашып йөргән көннәрем. Редакциянең өлкән мөхәррире Рим Шириязданов дәрәҗәлерәк җиргә күчеп, аның урыны бушап калган икән. Җәйнең ямьле чаклары. Редакциянең икенче хезмәткәре әле яңа гына нәүбәттәге ялына киткән. Әдәбият, музыкаль, яшьләр, балалар бүлекләрен үз эченә алган нәфис тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире Рим Кәримовның да шулай ук ялга, үзенең туган җире — Оренбург якларына җыенган чагы. Ул июль аенда барачак тапшыруларның планын кулыма тоттырды да: «Кайбер тапшыруларны Рим Шириязданов килеп эшләр, калганнарын үзең оештырырсың, кайткач карарбыз», — дип, китеп тә барды. Шулай итеп, кулыма айлык план тотып, «кайткач карарбыз»ы нәрсә була икән моның, дигән уй белән, эшкә дә урнашып өлгермәгән килеш редакциядә берүзем калдым. Хәер, редакция бүлмәсендә тагын бер кеше бар, аның белән мине, музыкаль редакциянең әдәби мөхәррире Зиннур Насыйбуллин, дип таныштырдылар. Ишетеп белсәм дә, моңарчы аны күргәнем юк иде. Туры җилкәле, төз гәүдәле, Такташныкыча озын, куе, кара чалара башлаган чәчле, акыллы сабыр караш сирпеп торган зәңгәр күзле урта яшьләрдәге бу кеше, эше белән башка редакциягә караса да, минем бүлмәдәшем булып чыкты.

Вакытлы матбугатта сирәк-мирәк шигырьләре, бер-ике язмасы басылган, ләкин әле бернинди эш күрсәтмәгән, юньләп дөнья күрмәгән, шәкертлектән айнып җитмәгән тәҗрибәсез яшь малайның нинди кыенлыклар алдында торганын ул яхшы аңлаган, әлбәттә. Ләкин колач җәеп ачык чырай күрсәтергә дә ашыкмады. Мин үзем дә беренче күргән кеше белән бик үк җиңел танышучылардан түгел. Шуңа күрә ике-өч

Сулдан уңга: Нәсимә Әхмәтҗанова, Эльза Гобәйдуллина, Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет), Рим Кәримов, Зиннур Насыйбуллин, Рәкыйп Гаффаров. 1970 еллар

көнебез урык-сурык сораулар алмашып кына үтте. Аңа дәшеп, сорау бирсәм, ул тәмәкедән саргаеп беткән музыкантларныкы кебек озын бармаклары белән сигарет көлен пөхтә генә каккалап, салмак кына җиренә җиткереп аңлата, үзе миннән берни төпченми. Башта, булса булыр икән бу дөньяда мондый битараф кеше, дип тә уйлап куйган идем. Соңыннан белдем, гомумән кешеләр белән мөнәсәбәттә ул бик сак, сөйләшүгә хирыс түгел икән. Ләкин сүзгә кесәгә кереп тормый, шаяртучыларга да тапкыр җавабы һәрвакыт әзер.

Элеккеге өлкән мөхәррир Рим Ширияздановның кендеге редакция белән чыннан да өзелеп бетмәгән икән, ул килеп бер-ике тапшыру әзерләп китте. Шул арада без аның белән танышып, хәтта дуслашып та өлгердек. Тумышы белән шулай ук Башкортстаннан булгангамы, әллә шактый еллар буе бер бүлмәдә бергә утыргангамы, Зиннур белән алар үзара ярты сүздән аңлашалар иде. Бу ике профессиональның эшләгәнен күзәтеп тору, аларның иҗат мохитында турыдан-туры кайнашу, минем кебек үрнәккә мохтаҗ яшь малай өчен үзе бер мәктәп булды. Аларга карап, мин дә мөстәкыйль эшкә тартыла башладым. Һәм, озак та үтми, мин әзерләгән тапшырулар да эфирда яңгырады. Әлеге вакыйганы, символик рәвештә генә булса да, без өчәүләп билгеләп тә үттек бугай әле. Бу Зиннур белән якыннанрак аралаша башлауның беренче адымнары иде.

Кайберәүләр белән гомер буе янәшә яшәп тә, чит-ят кеше булып каласың. Шөкер, безнең Зиннур белән алай булмады, без, ничектер, дәшмичә дә уртак сүз таба алдык һәм бер ай дигәндә безнең мөнәсәбәтләр шактый дустанә иде инде. Шулай булмаса, әлеге үзсүзле, үз-үзенә бикләнгәнрәк кеше: «Син Ширияздан урынына килгәнсең, дип ишеттем, ялдагылар чыкканчы таныклыгыңны алып куйсаң, хәерлерәк булыр», — дияр идемени?! Ул аны болай гына, сүз ияреп сүз чыгып кына әйткән сымак булды. Ләкин мин аңладым: Рим Шириязданов урынында аның мине күрәсе килгән. Дөресен әйтергә кирәк, ул чакта мине хезмәт вазифасыннан бигрәк, шул таныклык кызыктыра иде. Таныклыкның чын күннән эшләнгән затлы тышлыгы бер хәл, ул вакытларда радионың абруе нинди дә, аның хезмәткәренең дәрәҗәсе нинди! Радиога гап-гади мөхәррир булып раслану өчен генә дә Өлкә комитетында (бу сиңа Обком дигән сүз!) әңгәмә үтү кирәк иде бит! Зиннурның сүзләреннән кабынып киттем, ул

Музыка белгече Клара Таҗиева белән. 1970 еллар

мәсьәләнең җиңел хәл ителә торган юлын өйрәтте. Озак уйлап тормастан, кадрлар бүлеге мөдире — беркадәр ваемсыз, таркаурак, ләкин күндәм һәм киң күңелле марҗа түтәй янына кердем, тиешле кәгазьләр тутырттым. Һәм күп тә үтмәде, марҗа түтәебез җитәкчелек утырган икенче катка йөгерде. Шул ук көнне мине чын радио кешесе итеп таныткан мөһерле рәсми документ куен кесәмдә күкрәгемне җылыта иде. Аңлашыладыр ки, таныклыкны теләсә кемгә тоттырмыйлар. Димәк, хезмәт вазифам турында җитәкчелек күптән инде үзара килешкән. Мин, Зиннурның кайгыртучанлыгы белән, сынау срогын да узмыйча, бүлек мөдире вазифаларын башкарырга керештем.

Зиннур белән безнең араны тагын бер вакыйга аеруча якынайтты. Бу болай булды. Атна ахыры, яна торган көндәлек эшләр беткән. Гамьсез генә утырам шулай иякка таянып. Өстәл буш. Алдымда бары тик чип-чиста кәгазь бите һәм каләм. Кул, нигәдер, ирексездән каләмгә үрелә һәм кәгазь битендә үзеннән үзе зур хәрефләр белән «Бүген — җомга» дигән язу пәйда була. Шушы «ачыш»тан соң, тыныч күңел белән коридорга тәмәке тартырга чыгып китәм. Ул арада безнең яраткан режиссёрыбыз, уен-көлке яратучы, һич тиктормас Госман абый Әхмәтҗан, минем кәеф дулкынына бирелепме, «Бүген — җомга» дигәннең астына калын хәрефләр белән «местком» дигән имза сырлый. Битарафлык дәрәҗәсендә бакый сабыр, гамьсезлек дәрәҗәсендә бакый тыныч Зиннурыбызга ул көнне нәрсә булгандыр, Ходай үзе генә белә, ул тота да шул язуны кеше күрмәгән арада боерыклар тактасына элеп куя. Күп тә үтми, кинәт бүлмә ишеге каерылып ачыла һәм теге кәгазьне селки-селки местком активисты — күрше бүлмәдәге өлкән яшьтәге апа атылып керә. Мине күрү аңа тагын да дәрт-дәрман өстәде булса кирәк, бөтен бүлмәне ярып, аның тантаналы зәһәр тавышы яңгырады: «Бу Сезнең генә эш, башка беркемнеке түгел, кара син аларны, кара син аларны совет месткомыннан ничек көләләр, күрсәтермен мин сезгә ничек көлергә! Фәтхи Фазылҗаныч* үзендә микән?.. Хәзер... Хәзер күрсәтәм мин сезгә...». Апабыз минем борын төбендә кәгазьне хәтәр җилфердәтеп, үз сүзләренә буыла-буыла чыгып та китте. Артыннан һава гына суырылып, соңгы сүзләре ишеккә кысылып калды. Җомга көннең икенче яртысы тыныч үтте. Бу начар иде. Димәк, мәсьәләне зурга җибәреп, дүшәмбе көн булачак иртәнге җыелышка калдырганнар...

Дүшәмбе көн «летучка» гадәттәгечә башланды: Фәтхи абый тыныч кына атналык эшкә йомгак ясады. Инде җыелыш бетте ахрысы, дип, җиңел генә сулап куярга әзерләнгәндә, җитәкчебез дәһшәтле җитди төс чыгарып, ачулы карашын миңа төбәде: «Менә яшь специалистка карагыз әле, эшли башлаганына күпме һәм нәрсә белән шөгыльләнә ул, понимашь», — дип каяндыр теге кәгазьне тартып чыгарды. Аның тавышы көчәйгәннән-көчәя барды: «Ул нәрсә, кайда, нинди оешмада эшләгәнен

*Фазылҗанов Фәтхи Фазылҗан улы — ул елларда Татарстан радиосының башлыгы.

аңламый мәллә? Баш мөхәррир нәрсә карый, комсомол секретаре?!» Мин башны аяк арасына тыгардай булып аска караган килеш, Ходайга тапшырган инде, нәрсә булса шул булыр дип, тын да алмыйча да утыра бирәм. Зал да тып-тын. Теге апаның: «Менә җавап бирсен хәзер», — дип ысылдаганы гына ишетелә. Әнә шундый гасаби бер мизгелдә, аермачык булып, Зиннур тавышы яңгырый: «Ул кәгазьне тактага мин элдем». Башымны калкытам. Чалара башлаган чәчләрен сыйпаштырып Зиннур басып тора. Зал өнсез. Фәтхи абзый да өнсез. Мондый хәлне күргәне булмаган, ахрысы. Зиннурга аптырап карап-карап торды да: «Летучка бетте, таралыгыз», — дип кырт кисте.

Шушы хәлдән соң әле бик озак вакыт мин аның алдында үземне ничектер гаепле итеп сизеп йөрдем.

Зиннурны музыкаль редакциянең әдәби хезмәткәре, дигән идем. Әдәби мөхәррирнең эше беренче карашка әллә ни катлаулы булып тоелмаса да, ул — зур әдәби сәләт һәм профессиональ осталык таләп итә торган шактый авыр хезмәт. Гадәти музыкаль программалар, сораулар буенча концертлар, төрле бәйрәмнәргә һәм юбилейларга багышланган тапшырулардан тыш, әле бит аерым язучыларның, композиторларның, һәвәскәр башкаручыларның иҗат эшчәнлеген яктырткан концерт-очерклар, тыңлаучыларның музыкаль белемен күтәрүгә юнәлдерелгән махсус концерт-әңгәмәләр оештырыла иде. Шуның өстенә, музыкаль редакциягә штаттан тыш авторлар да тупланган. Аларның күбесе йә «култык астына скрипка кыстырып туган» халык вәкилләре, йә үзебезнең урыслашкан татар булганга, Зиннурга бик күп кара эш — тәрҗемә белән шөгыльләнергә туры килә иде. Коры академик тел белән язылган, гади кеше аңламаслык үзенчәлекле терминнар белән шыплап тулган никадәр язма узгандыр аның кулыннан. Чиләнсә-чиләнде, ләкин һәрберсенә җан кертте, күңел сулышын өрде һәм аларны саф татарча яңгыратты.

Инде яңа җыр текстларына килсәк, монысы — үзе бер тема. Ул заманнарда җыр яздыру студиясенең гөрләп эшләгән чаклары әле. Көне-төне редакция бүлмәсендә, студиядә җырчылар, композиторлар, музыкантлар, шагыйрьләр кайнаша, өзлексез эш бара, иҗат хөкем сөрә. Җыр текстларын карап чыгу, тиешле шигъри камилгә китерү Зиннурга йөкләнгән. Моның өчен ул җаваплы. Монда Зиннур тагын алмаштыргысыз кеше. Эшләсә, ул эшне җиренә җиктереп эшли, текстларына Зиннур кул тидергән авторларның рәхмәт әйтмичә киткәне юк. Җене килсә, беркая ярамаган җыр текстын да өр-яңадан язып бирә. Аның бу йомшак ягыннан оста файдалану-

Сулдан уңга: Фәтхи Фазылҗанов, Рим Кәримов, Зиннур Насыйбуллин, Мәхмүт Нигъмәтҗанов – Татарстан радиосының сәнгать советы утырышында. 1970 еллар

чылар да табыла, әлбәттә. «Нигә болай әллә кемнәр өчен күпме көчеңне һәм вакытыңны әрәм итәсең?», — диючеләргә ул: «Көе әйбәт бит, әйдә, тусын яңа бер җүнле җыр, миннән булсын яхшылык», — дия торган иде. Ә белгән кеше белә: әзер көйгә җыр тексты язу — бер дә җиңел эш түгел. Аның үз кагыйдәләре бар. Темасы бер мәсьәлә, текстны музыкага яткыру, үлчәмнәрне туры китерү, сүзләрнең мантыйкый басымын музыкаль басымга тәңгәлләштерү — болар барысы да текст язучыдан зур сәләт тә, тәҗрибә дә сорый.

Ә Зиннурда сәләт тә, тәҗрибә дә хәттин ашкан иде. Шуңадыр, аның каләменә ышанып, Казан белән Уфа арасында оештырыла торган алмаш концертларны да, аеруча җаваплы программаларны да гел Зиннурга тапшыра килделәр. Бүтәннәр әзерләгән шундыйрак тапшырулар булса, алар да аның күз уңыннан үтмичә калмый. Ул, оста рәссам кебек, бәләкәй генә төзәтмә-үзгәрешләр кертеп җөмләнең аһәңен, әйтәсе фикерне тагы да ачыклап, фәлсәфи төсмерләр, мәгънәви бизәкләр белән баета белә иде.

Зиннурның зур әдәби сәләткә ия кеше булуына еллар үтеп, ул безнең әдәби редакциядә эшли башлагач, тагын бер кат инандым. Нәрсә генә язмасын, коеп кына куя иде. Башка сүз юк, иң оста каләм иясе дә тел-теш тидерерлек түгел аңа. Әдәби редакциядә эшләгәндә сирәк-мирәк булса да шигырьләр язды, ара-тирә радио өчен әдәби тәрҗемәләр ясады. Ул ара-тирә эшләнгән тәрҗемәләр дә, әгәр бергә тупласаң, күләме белән уртача бер җыентыктан һич ким булмас иде. Әллә тәрҗемәне җитди эшкә санамагангамы, әллә һәрчак өелергә торган кәгазь тауларыннан туйгангамы, ул аларны саклауны да, матбугатта да бастыруны кирәк тапмады. Ә алар арасында шактый кызыклылары да бар иде. Мәсәлән, Рәсүл Гамзатның «Минем Дагыстаным» китабыннан кайбер бүлекләр, төрле халык вәкилләренең үз туган телләре хакындагы шигырьләре... Дөрес, аның кайбер тәрҗемәләре радио фондында әле дә саклана. Алар күп түгел. Киләчәктә бәлки кемгәдер кирәк булыр дип, хәтердә калганнарын искәртеп үтәм. Чыңгыз Айтматовның «Гасырга сузылган көн» әсәреннән өзек, Рөстәм Кутуй хикәяләре һәм шигырьләре, Чиләбедә яшәп иҗат итүче язучы Рөстәм Вәлиевнең «Хәмәт һәм Коромцев» повестеннан өзек, казах язучысы Аман Соспаевның «Сары эт» хикәясе, Дмитрий Фурмановның «Шәкүр» дигән парчасы... ныклап карасаң, тагын берничә әсәр табылуы мөмкин.

...Зиннурның 1987 елны, моннан 20 ел элек басылган «Гамьнәр илендә» дигән китабын өр-яңадан укып чыктым. Һәм өр-яңа китап укыган кебек булдым. Алдагы битләрдә урнашкан берничә шигырен санамаганда, андагы шигырьләр бүген дә заманча яңгырый, бүген дә үзләренең эстетик кыйммәтен югалтмаган. Хәзер инде ышанып әйтергә буладыр — Зиннур Насыйбуллин вакыт сынавын узган шагыйрьләрдән!

Бу китапны, шагыйрьнең юбилее уңае белән, аны тагын бер кат бүгенге күзлектән карап чыгып, Зиннурның иҗаты турында каләмдәш дусларының язмаларын өстәп, яңа бизәлештә, яңа форматта бастырып чыгарасы иде дә бит. Анысы да булмады! Кем әйтмешли, юк шул бездә талантка кадер, «үлеп аңлатсаң» да юк. Туксан тугыз тапкыр әйтелгән фикер, йөз булсын дип, мин тагын кабатлыйм: күренекле шәхесләребезне, аларның иҗатын без юбилейдан-юбилейга, 10 елдан 10 елга гына искә алабыз. Шуның аркасында кыйбласын саташтырып торган бу заманда җан азыгы булырдай нихәтле әдәбият-сәнгать әсәрләребез файдасыз һәм хәрәкәтсез хәлдә, әрәм булып ята. Рухи мирасны дөньяга чыгару өчен рәсми дата мәҗбүрилеген кагыйдәгә әверелдердек шул без. Кызганыч.

Шунысын да әйтергә кирәк, Зиннурның әсәрләре вакытында дөнья күрә алмады һәм, шул сәбәпле, вакытында тиешле дәрәҗәдә бәяләнмәде дә. Бу мәсьәләдә ул ялгыз түгел. Андыйлар

элек тә бар иде, хәзер дә күп. Мәсәлән, Башкортстанда торып иҗат итүче ни талантлы шагыйрә Халисә Мөдәррисова үз туган телендә беренче шигырьләр җыентыгын Казанда нибары 2005 елда, инде шигырьдән прозага күчә торган яшенә җиткәч кенә чыгара алды. Шул ук Башкортстанның бер районында шактый гомер сөргән, хәзер исә Чаллыда яшәүче татар рәссамы һәм шагыйре Хәмит Латыйфны алыйк. Рәсемнәре, агачтан һәм башка материалдан иҗат ителгән хезмәтләре дөньяның төрле почмакларында үткәрелгән күргәзмәләрнең түрендә урын ала, призлы урыннар яулый. Шушы алтын куллы оста бездә танылу тапмый. Казанга күчеп килеп үзен күрсәтергә ни үҗәтлеге, ни әрсезлеге, ни матди мөмкинлеге юк...

Зиннурның иҗатына килгәндә, аның төп өлеше 1973 елда дөнья күргән «Тәлгәш» җыентыгына сыеп беткән дисәк, хата булмас. Ул китап Зиннурга бик соңарып, үз сүзләре белән әйтсәк, «шатлыкларга инде күнегеп, иңләшеп беткәч», 36 яшендә килеп керде һәм шагыйрьне «илһам өстәп яңа иҗат үрләрен яуларга рухландыра» алмады. Мин аның белән эшли башлаганда ул инде актив иҗаттан читләшә башлаган иде. Аннары, шигырь уты сүнеп бетмәсә дә, язу-сызу эше белән шөгыльләнергә аның артык мөмкинлеге дә юк иде. Кичен — эшчеләр тулай торагындагы дүрт кешелек шау-шулы кысан бүлмә. Ә түземсезлек белән көтеп алынган ял көннәрендә ул Дөбъяз районында укытучылык иткән хатыны һәм сабый кызы янына ашыга. Кызын бик ярата иде Зиннур. Кызы дигәндә, аның йөзе җанланып китә, күзләре нурлана, хәрәкәтләренә дәрт керә. Фатир да аңа шулай ук бик соңлап, кырыкның үрге ягына чыккач, дөнья гаме инде битарафлана, шигырьгә күңел сүрелә башлагач бирелде. Ә инде шигырь язу ул — яшьлек эше, шигърият — яшьлек юлдашы, диләр.

***

Зиннур традицион калыпта һәм шушы калыпның чиксез мөмкинлекләре барлыгына инанып иҗат итте. Үзенең табынган шагыйре Хәсән Туфан кебек, формага караганда, ул күбрәк шигырьнең эчтәлегенә, мәгънәви яңгырашына, аһәңлелегенә игътибар бирде. Туган телнең бөтен нечкәлекләрен яхшы тойган кеше буларак, ул аның чиксез хәзинәсеннән мөмкин кадәр киңрәк файдаланырга тырышты, нәтиҗәдә, үзе дә ана телен баетырлык канатлы сүзләр дәрәҗәсендәге шигъри юллар тудырды:

...Тик яшәми канатлылар
Канатсыз тормыш белән.
(«Канаган канатны җилкетеп...»)

...Юксынуы җиңел түгел икән
Үз янында булган кешене.
(«Үзгәрдең син»)

Аз язса да, бер уйлаганда, Зиннур бәхетле шагыйрь иде. Ул халык әле шигъри сүзнең бәясен белгән чорда яшәде. Шагыйрьнең «Гамьнәр илендә» дигән икенче җыентыгы да, беренчесе кебек, чыгуга ук таралып бетте, көтеп алган укучыларын тапты. Һәм, алда әйтеп үтелгәнчә, әгәр дә аның әдәби мирасы янә бер барланып, әлеге җыентык нигезендә яңа китап басылып чыкса, мин ышанам, бүген нинди заман булуына карамастан, ул кибет киштәләрендә тузан җыеп ятмаячак.

Хәзер уйлап утырам, Зиннур белән мин 12 ел чамасы бергә эшләгәнмен. Шул елларда иң аралашкан кешесе дә мин булганмын. Безнең эш урыны гына түгел, торган җирләребез дә тора-бара бер тирәдәрәк булып чыкты. Барыбер мин Зиннурның эчке һәм тышкы дөньясын яхшы белә идем, дип әйтә алмыйм.

Авылда туып үскән, шунда тәрбия алган табигать баласының күңеле зур шәһәрнең шартлы тормышына, бигрәк тә кешеләрнең ясалма мөнәсәбәтенә күнегеп тә, иңләшеп тә бетмәгән, күрәсең. Ул күбрәк үз эченә бикләнебрәк яшәде, аның нинди дер кешеләргә сиздерергә теләмәгән «күзгә арты дөньясы» бар иде. Ул дөньяга беркемне дә, хәтта иң якын кешеләрен дә кертергә теләмәде. Бу аның холкы белән бәйле булганмы,

башка төрле сәбәп беләнме, әйтү кыен. Миңа калса, Зиннурда аның күңелен ирексезләп, бимазалап торган бер борчу бар иде. Ул аны даими сызландырып торды кебек. Нинди борчу булды ул, сер булып калды. Ни генә булмасын, Зиннур беркайчан да вакланмады, чәбәләнмәде, үз дәрәҗәсен белеп яшәде. Анда тышка бәреп, ташып тормаган эчке бер горурлык бар иде.

Зиннурга кайвакыт: «Синдәге сәләт башкаларга бирелсә, алар нәрсә генә эшләмәс иде», — диючеләр дә булды. Җавап урынына ул, иңнәрен җыерып, көлемсерәп кенә куяр иде.

Зиннур белән без бергә эшләгән, бергә аралашкан еллар, хәзергечә әйтсәк, торгынлык вакытына, тормыш ашыкмыйча гына үз җаена ага биргән чорга туры килде. Кешеләр дә ул вакытта Ходай биргән юклы-барлы кыска гомерен бүгенгедәй ут капкандай чабып-йөгереп үтми иде. Җәй айларында, кичкырын без Зиннур белән Казан елгасы буенда йөзьяшәр тирәкләрнең дулкын юып шомарткан карт тамырларында утыргалыйбыз. Подлужный урамы әле элеккечә, шул килеш, вакыт гүяки монда туктап тора — җыйнак йортлар агачлар күләгәсенә ышыкланган, хәрәкәт юк, шәһәр шау-шуы килеп җитми. Өстә, зәңгәр күктә каядыр еракта калган балачак иленнән йөзеп килгән ак болыт кисәкләре тирбәлә. Кичке эңгердә, ярлары белән хушлашып, тын гына Казансу ага. Кичке шәфәкъ хозурында ашыкмыйча гына суга коелган аксыл-саргылт яфракларның әйләнбәйлән уйнавын күзәтәбез. Шәраб ачыла, әкрен генә телләр чишелә, сүз иярә сүз чыга. Нәрсә турында гына сөйләшеп бетермәгәнбездер андый чакларда! Зиннур балачагын искә ала, Башкортстанның табигатен мактый, Сахалинда хезмәт итүләрен, Бүздәк районы газетасында эшләгәндә иптәшләре белән сал ясап, Караидел буйлап сәяхәткә чыгуларын, шәхси тормышы турында сөйләнергә яратмаса да, туган ягында беренче хатыны янында калган малайларын хәтерендә яңарта.

«Их, Сак-Сок темасына бер либретто язарга иде, — дип көрсенү катыш хыялланып ала. — Бер уйласаң, бу әле аерым кешеләр язмышы гына түгел, гомумән татар халкының, төрки халыкларның уртак язмышы да», — дип өстәп куя. Әлбәттә инде, агымсулар үткәннәрне дә хәтергә төшерә, узган гомерләрне дә искәртә, яшәеш, фани белән бакыйлык турында да уйландыра. Кайсыдыр бер язучыны җирләгәннән соң шул карт тирәкләр төбендә утырганда: «Ничек кенә авыр, мәшәкатьле булмасын, мин үземне туган туфракта җирләтер идем... Туган туфракта җирләнер идем», — диде. Аның бу сүзләрен мин мәңгегә күңелемдә бикләдем.

Зиннурның ял алып кайдадыр шифаханәләрдә, яисә юллама алып җылы якларга, яки иҗат йортларына баруын хәтерләмим. Һәр елны нәүбәттәге ялын алыр иде дә, шул ук көнне өлкән яшьтәге әти-әнисе янына Башкортстанга кайтып китәр иде. Печән чабып, лапаскураларны карап, капка-коймаларны сипләп, үзенчә ял итеп, җиләсләнеп, күңел күтәренкелеге белән кире Казанга килер иде. 1985 елның җәй башында шушы максат белән ул янә туган ягына юл тотты. Кире кайтуы болай хәтердә калган. Мин дүшәмбе көннәремдә була торган җыелышка соңга калмыйм, дип эш бүлмәсенә кергәндә Зиннур үз өстәле артында утыра иде инде. «Һәй, Зиннур да эшкә чыккан, яшибез икән болай булгач!» — дип, чын күңелдән сөенеп аңа кулларымны суздым.

Зиннур тыйнак кына исәнләште, аннары гаепле кеше сыман елмаеп, кәефсез генә: «Авырыйм әле мин, Рөстәм, авылда да бернәрсә кыралмадым, әти-әнигә бернинди ярдәм тимәде, гел сырхауланып ятарга туры килде», — диде. Аннары, минем: «И, андый чаклар була инде ул», дигәнрәк сүзләремә игътибар итмичә: «Сине генә көтеп утырам, мин Сәгыйтов* янында булдым,

* Сәгыйтов Тәүфик Камәретдин улы — ул елларда Татарстан радиосының яңа башлыгы.

рәхмәт аңа, нindидер таныш табибына шылтыратты, хәзер шуның янына барышым. Ярар, әлегә хуш», — диде дә, чыгып китте. Аның бу чыгып китүе, кызганыч, «әлегә» булмады, бу китүдән радиога инде ул бөтенләй кире әйләнеп кайта алмады.

Бер-ике ай 15 нче хастаханәдә ятты. Чыгардылар. Мин хәлен белгәләп йөрдем. Ничә кермә, ул аш бүлмәсенең тәрәзәсеннән урамга карап утыра. Бер кулы белән ияген учлаган, икенче кулы иң арзанлы һәм иң каты булган «Астра» сигареты кабын капшый. Ул чакта барыбыз да шул «Астра»ны көйрәтә идек. Элек кызыл шәрабтан баш тартмаган кеше, аннан тыела төште, ә менә тәмәкедән аерыла алмады, күп тартты, берөзлексез тартты.

Аның янына бер килгәндә, әбиләр чуагы башланган мәл, җылы, матур көзге көн иде. Зиннурның да кәефе күтәренке. Ул мине күрүгә үк: «Рөстәм, бер чыкканда безнең кибеттә коньяк күргән идем, үземнең хәлем юк, бетмәсә, шуны алып кер әле, бәлки, мин дә әзрәк тотып куярмын», — диде. Өстәл янында шактый сөйләшеп утырдык. Шунда ул тәмәке төтененә буылып: «Булдыра алсаң, тәмәкене ташла, мин дә елларны кире кайтарып булса, тартмаган да, тотмаган да булыр идем», — дип, көрсенеп куйды. Элек үгет-нәсыйхәт бирә торган кеше түгел иде Зиннур.

Шактый сөйләшеп утырдык. Ул вакытта Зиннурның савыгырга өмете бик зур иде әле. Сүз ахырында: «Бу табибларны да әйтер идем инде. Синең бер чирең дә юк, организмың хәлсезләнгән, күбрәк витаминлы азык ашарга, сөт эчәргә кирәк, диләр. Бөтенесен аларча эшлим, инде ничә ай үтте, яхшыга бернинди үзгәреш юк, киресенчә, хәл начарланганнан-начарлана бара, ичмасам, дарулар да бирмиләр», — дип бераз зарлангандай да итте. Шуннан соң Зиннурның хәле белән даими кызыксынып торган радиобыз җитәкчесе Тәүфик Сәгыйтов аны РКБга урнаштыру җаен тапты. Анда да ул күпмедер ятып чыкты. Ләкин РКБ да Зиннурга ярдәм итә алмады. Ул сызганнан-сыза барды. Кара көзләр җитеп, декабрь башланды, карлар яуды. Әҗәл аңа хөкем чыгарып яткан көннәр... Мин аның янына болай да еш керәм, ләкин беләм, ул минем тагын да ешрак керүемне тели. Эштән кайтышлый юлым аның тәрәзәсе каршыннан үтә. Башка юл да бар, ләкин болай турырак. Кичә генә хәлен белгән идем, бүген инде кермәсәм дә ярый, дип өен узып китәм. Белмим, бу дөньяда чыннан да нәрсәдер бар, ахры. Аның карашы аркамны тишә. Сизәм, бөтен җаным-тәнем белән тоям, Зиннур мине күргән, таныган, инде хәзер өметсез карашы белән кышкы кичнең караңгылыгында югала барган шәүләмне озата. Нindидер көч мине кире бора. Ишек төбендә сагалап торган диярсең, кыңгырау төймәсенә басу белән Зиннур күренә. Сүзсез генә бер-ике сигарет көйрәтәбез...

Хәлләре авыр булса да, Зиннурның бәләкәй генә бер юанычы бар — өстеннән бер йөк төште. Тагын ел-ел ярымнан дөнья күрәчәк «Гамьнәр илендә» китабының кульязмасы яңа баштан бер каралып, Равил Фәйзуллинның төпле кереш сүзе белән Татарстан китап нәшриятына тапшырылды. Китап чыгачагына инде хәзер борчылмаска да була.

Зиннурга чын күңелдән сәламәтлек теләп, аның хәлен белешеп торучылар байтак булды. Хәлен белешүчеләр генә түгел, хәленә керүчеләр дә юк түгел иде. Шундыйларның берсе — Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, язучы Фәрваз Миңнуллин. Белмим, үз нияте беләнме, башкаларның киңәше беләнме, беркөнне ул мине үзенә чакырды да: «Зиннурның бу китабы 1987 елда гына басылып чыгачак. Әгәр дә аңарчы аның белән берәр хәл була калса, гаиләсенә китапка тиешле гонорарның нибары 25 проценты гына эләгәчәк. Ләкин бер хут бар, әгәр дә ул үз кулы белән, «Дәвалану өчен акча кирәк булу сәбәпле, гонорарны тулысынча алдан түләвегезне үтенәм» дигән эчтәлекле гариза язса, ул чакта директор белән

сөйләшүне мин үз өстемә алам, озакка сузма», — диде. Бу сөйләшү яңа елга әзерләнгән көннәрдә, декабрьнең урталарында булды. Эшне чыннан да озакка сузарга ярамый иде. Ләкин гаризаны ничек яздырырга? Турыдан-туры гариза яз, дип әйтеп булмый, Зиннур бик сак акыллы, сизгер кеше, дөресен шунда ук аңлаячак иде. Ләкин мин озак уйлап тормадым, озак уйларга вакыты да юк, бәлки кирәге чыгар дип, бер яхшырак шәраб алдым да, Зиннур янына киттем. Ишектән керү белән: «Зиннур, сөенечле хәбәр бар. Әле яңа гына Фәрваз абыйны күрдем. Нәшриятның быелга бирелгән бераз акчасы файдаланмыйча калган, аны яңа елга хәтле сарыф итеп бетерергә кирәк икән. Зиннур кебек җүнле кешеләрнең хәленә кереп, китапка тиешле гонорарны алдан ук тулысынча түләп кую мөмкинлеге бар ди, тиз генә гариза язарга кушты, шуңа ашыгыч килүем», — дидем. Зиннур уйга калды, бүген каләм тотарлык хәлем юк, дип карады. Мин чынчынлап ачуланып киттем. Миңа инде уйныйсы юк иде, чөнки, гариза язылмаган хәлдә, безнең ул чактагы хезмәт хакы белән исәпләгәндә, ике ел казна эшендә эшләмичә яшәрлек акча юкка чыга. Зиннур ул чакта нәрсә уйлагандыр, әйтүе кыен, ләкин гариза язылды.

Ә күп тә үтми, яңа елга кереп, ябалак-ябалак карлар ява башлаганда без Зиннурны соңгы юлга — «Ана күңеле дә ирешмәслек еракларга» — озаттык. Тәкъдир шулай булгандыр, ул Самосырово зиратында җирләнде. Җәсәден җир куенына тапшырганда, аның Казансу буенда агымсуларга карап пышылдаган сүзләрен ишеткәндәй булдым: «Юк, мин туган туфракта җирләнер идем!» Җил исеп куйды.

Ярлары белән хушлашып, Казансу сулары ага да ага. Алар ярлары белән генә хушлашмый, безнең белән дә хушлаша икән...

КАРА ШӘЛЕ КИЛӘ СӨЙРӘЛЕП

Шомлы еллар иде.
Январь җиле
Өйне-тышны йөри бер итеп.
Сыңар күзем белән тышка карыйм,
Тәрәз бозын өреп эретеп.

Ыңгырашкан кебек шыгырдатып,
Хат ташучы ачты капканы,
Шомландырып, керәр-кермәс торды
Һәм борылып кире атлады.

Нигә китте?
Нигә хат-хәбәрдән
Мәхрүм калды безнең өй генә?
Анам күңеле нидер сизде бугай,
Кара шәлен ябып иңенә,
Ул урамга чыкты.
Өерелеп
Кышкы салкын керде ишектән.
(Салкын гынамыни ул елларда
Кешеләрнең җанын өшеткән.)
Тиз урады әнкәй, ләкин өйне
Узып китте. Никтер кермәде.
Яланаяк каршы чыкканымны
Әллә күрде, әллә күрмәде.

Каерылган кош канаты кебек,
Кара шәле кардан сөйрәлә.

— Әни, әни!
Нәрсә булды, әни?
Сөйлә, әни.
Хәер... сөйләмә.

...Шатлыкларга күнегелә бугай,
Тик кайгыга булмый өйрәнеп.
Ничәмә ел...
Ничәмә ел инде әниемнең
Кара шәле килә сөйрәлеп.

ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИН

(1937-1986)

СКРИПКА МОҢЫ

Җиргә ай нурлары буйлап
Агыла сыман бу моң.
Яп-ялангач йөрәгеңә
Кагыла сыман бу моң,
Күңелеңә сагыш булып
Ягыла сыман бу моң.

Мең күңелнең кичерешен,
Зарларын, борчуларын
Нечкә генә җансыз кыллар
Ничек сыйдырган барын?

Уйный кыллар, сөйли кыллар, —
Көй түгел бу — хикәят.
Ярсый кыллар, өзгәләнә,
Даулый кыллар, ниһаять.
Кыллар аша үз-үзенә
Сорау бирә бу хәят,
Җавап эзли бу хәят.

***

Җиде диңгез кичкән чая ирләр,
Кайтмас юлга китәр алдыннан,
Бу дөньяның бөтен мәшәкатен
Мирас итеп безгә калдырган.

Хәзер шушы авыр йөкне төяп,
Безгә чират диңгез кичәргә,
Тормыш инде чиләндереп беткән
Төеннәрне безгә чишәргә.

Тик курыкмый йөкнең зурлыгыннан
Ата улы булган беркем дә —
Йөк төялгән көймә тотрыклы,
Ә буш көймә — дулкын иркендә.

ПӘРӘВЕЗ

Табигать сөйми бушлыкны,
Сөйгәне ешлык икән.
Ләкин үрмәкүчләр өчен
Һава да бушлык икән.

Тормыштагы бушлыкларга
Корыла пәрәвезләр.
(Яктылык ничек төшә бит —
Шәйләми кайчак күзләр.)

Үрмәкүч холыклы җанның
Акылыннан, булмышыннан
Хәтәр җепләр сузылалар,
Янап бар тормышыңа.

Үрмәкүч җанлы кешеләр
Пәрәвез корган итә.
Пәрәвез корганнарны да
Пәрәвез корбан итә.

АККОШ КҮЛЕ АНЫ САГЫНА

«Туфан килми», — диеп,
Аккош күле
Дулкынлана һаман, борчыла,
Һәм наратлар: «Күренмиме?» —
диеп,
Басып карый аяк очына.

Ул килер дип, ак каеннар монда,
Чыкка манып, чәчен тараган;
Чыкка манып, чәчен тараган да,
Көзге итеп, күлгә караган.

Дога итеп пышылдыйлар алар:
«Язмыш, безне аннан аерма,
Рухы белән ул да имән ләса,
Җаны белән охшаш каенга».

Гөлләр сөйгән җанны гөлләр
сагына,
Сагыналар, аңлыйм телләрен.
Яшел белән язган шигырьләрен
Актарасы килә җилләрнең.

Ник көтмәсен аны Аккош күле? —
Кәккүкләр бит язгы таңнарда
Һәр ел саен җырлы гомер юрый,
Озын гомер юрый аңарга. ■

ТАШКЫННАРДАЙ ТАШКАН ЕЛЛАР...

Әхтәм Зарипов

1976 елның ахыргы айларында, Октябрь бәйрәмнәре узгач, киләсе 60 еллык бәйрәм көннәренә Таҗи Гыйззәтнең трилогиясе буенча фильм-спектакль әзерләргә иде, дигән сүз йөри башлады. Моны Академия театры артистлары да, телестудия хезмәткәрләре дә әйтә.

Шулар белән рухланып, мин телевидение җитәкчеләренә тәкъдим белән кердем. Җитәкчеләр бу тәкъдимне янә үз җитәкчеләренә җиткезеп, рөхсәт алырга вәгъдә иттеләр. Рөхсәт бюджетка кагыла. Бюджет исә акчага барып тоташа.

Бу хәбәр трилогия авторының улына ишетелеп, озак та көттерми, ул: «Сценарием үзем язачакмын, шулай булганда гына ризалык бирәчәкмен», — дигән шарт-ультиматум куя.

Ул әтисе язган трилогияне бүлгәләп, 12 серияле тамашалык «сценарий» бастырып китерә. Үзеннән өстәгәннәре — ул чордагы «политэкономия» буенча лекцияләр тексты. Алар, серияләр алдыннан, сценарий авторы тарафыннан укылырга тиеш икән. Студия җитәкчелеге риза. Ә менә режиссер риза түгел. Ул спектакльне үзенчә күрә һәм үзенчә куя: 12 серияне — 8 сериягә сыйдыра, «политэкономия»дәресләре — серия алларында түгел, премьера алдыннан 3 кенә минут булырга тиеш, ди.

Ләкин сценарий «авторы» барыбер үз дигәненә ирешә: һәр серия алдыннан унар минутлык лекция укыла.

Бу рәсемне (режиссерга сиздермичә генә) фильм-спектакльне тасмага яздыру алдыннан Рөстәм Нәбиуллин төшереп алган. Утырып торганы — ул вакыттагы баш режиссер Клара Газизова, аннары — режиссёр, ягъни мин фәкыйрегез басып тора, ялгышуларны язып баручы режиссёр ассистенты исә — Равил Гайнетдинов, бүгенге көндә — шәех, Россия мөфтиләр шурасының вә Россия Үзәк Европа төбәге мөселманнары Диния нәзаратының рәисе Равил Гайнетдин!

«Ташкыннар» дип аталучы бу фильм-спектакль хәзер студиядә саклана, 8 сериядә, «политэкономия» дәресләресез генә, әлбәттә.

Чөнки әсәр — үзе шул чор «политэкономиясен» чагылдыручы трилогия. ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

АИТОВ ИСМӘГЫЙЛЬ СӨЛӘЙМАН УЛЫ (1888-1930) — зыялы, эшмәкәр. Россиянең төрле шәһәрләрендә коммерция эшләре белән йөргән И.Аитов, Казанда булганда, якын дусты, сабакташы Ф.Әмирхан белән дә очрашып, вакытларын бергә үткәрергә тырышкан һәм шундый кичәләрдә ул Г.Тукай белән танышкан, аралашкан. Ф.Әмирханның И.Аитовка язган хатларында Г.Тукай турында да хәбәрләр бар. 1908 елның 8 март даталы бер хатында ул: «Тукаев Габдулла... яңа костюмлык алып тегәргә бирде...» — дип, шагыйрьнең көнкүрешенә караган бер детальне искә алып китсә, шул ук елның 26 октябрендә язган хатында: «Безнең «Әдәбият кичәсе»ндә Тукаевның «Кисекбаш»ы укылды (үзе укыды), халыкның көлә-көлә эчләре катты һәм Тукаевны бүлә-бүлә кул чабу белән сыйладылар», — дигән сүзләрдән Тукайның, бу чорда бик актив рәвештә әдәби кичәләрдә катнашып, әдәби-мәдәни мохит үзәгендә кайнаганы аңлашыла. 1908 елларда Исмәгыйль Аитов, аның энесе Ибраһим, абыйлыэнеле Фатыйх белән Ибраһим Әмирханнар һ.б. И.Аитовларның дача бакчаларында (Ботанический сад каршында) еш кына очраша торган булганнар. Кайчакта аларга Г.Тукай, Х.Ямашев та кушылган. Бу күңел ачу кичәләрендә Солтан Габәши рояльдә уйнарга тотына, Исмәгыйльнең энесе Ибраһим җырлый торган була. Шул рәвешле И.Аитов белән Г.Тукай арасында якыннан танышлык, дустанә мөнәсәбәтләр урнаша. Прогрессив карашлы И.Аитов шагыйрьнең әдәбият-сәнгать әһелләренең эшләре, газета-журналлар эшчәнлеге белән даими рәвештә танышып бара. И.Аитов үзе дә хатларында Тукайны искә алып, сорашып язган булуы ихтимал. 1909 ел 27 апрель даталы хатта: «...Тукаев та минем өстәл буенда яңагына таянып утыра. Сиңа сәлам әйтми», — дип язган шаян юллары шуңа ишарәли... Алдынгы карашлы, милләтпәрвәр гаиләдә тәрбияләнеп үскән И.Аитов, Тукайны үз итеп, аның иҗатына хөрмәт белән караган.

Әнисә Алиева,
филология фәннәре кандидаты ■

Әдәбият

Рәсүлева З. Тукай эзләреннән. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1985. Б.46-49; Әмирхан Ф. Әсәрләр. — 4 томда: Т.IV. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1986. — Б.244, 259, 269.

ЗАМАН УТЛАРЫ

17 октябрь, 1972 ел. Язучылар Союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышы

Катнашалар: Гази Кашшаф, Ренат Харисов, Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Рафаэль Мостафин, Ләбибә Ихсанова, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Мирсәй Әмир, Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм башка язучылар, редакция хезмәткәрләре, әдәбият сөючеләр (барлыгы 102 кеше).

Көн тәртибендә: «Казан утлары» журналының 1-8 саннары турында фикер алышу.

Тыңланды: Гази Кашшафның кереш сүзеннән соң, Мәдинә Маликова — проза, Шамил Бикчурин — очерклар, Роберт Әхмәтҗанов — шигърият, Ф.Урманчеев тәнкыйть турында докладлар белән чыкты *(биредә «докладлар беркетмәгә теркәлә» дип язылган, вәләкин бер генә беркетмә — Роберт Әхмәтҗановныкы гына теркәлгән. — Л.Л.).*

Фикер алышулар башлануга, сүзне **Барлас Камалов** ала:

— Иң әйбәт доклад — Роберт Әхмәтҗановныкы. Проза доклады да уйланып эшләнелгән. Нигездә килешәм. Ләкин ул үзенең алтын тәңкәләрен «Фронтовиклар»га сибеп бетерде. «Урталыкта» повестена — көмеш, «Каты токым»га бакыр гына калды. Калган әсәрләрнең исеме генә саналып чыкты. Бу дөрес түгел. «Фронтовиклар»ның кимчелеге бар, китап итеп чыгарганда М.Мәһдиев искә алыр. Аяз Гыйләҗевне дә пьедесталга бастырды. Иртә. Игътибарга лаек әсәр. Җыйнак. Сәнгатьчә эшләнгән 3-4 характеры бар. Динамика җитми, хәрәкәт аз.

А. Ганиевнең «Сүзсез җыр» повестена карата бәя белән килешәсем килми. М.Маликова докладындагы фикергә: Гаптелхак белән Хәятнең мәхәббәтенә тел-теш тидерүгә каршы мин. Алар — чын, ихлас мәхәббәт.

Мөнбәргә **Газиз Иделле** күтәрелә:

— Шамил Бикчуринның «Каты токым»ы миндә әйбәт тойгы калдырды. Мәдинә Маликова, образларны бер-берсеннән аерып булмый, ди. Киресенчә, алар бик нык аерыла. Кадермәт, Мотгәрәй, Фәрхетдин, Сапарбай, Гомәр бай. Алымы әйбәт. Күченеп китәләр — башы, күченеп китәләр — ахыры. Тин-Тинычта морякка хас булмаган сыйфатлар бар. Аның Валентина тирәсендә мавыгулары артык. Гомумән, әсәр — авторның

Барлас Камалов

Фатих Хөсни

уңышы. «Фронтовиклар» — нигездә әйбәт роман. Тик укытучылар коллективына түбәнсетеп карау дигән, уй кала күңелдә (кайбер репликаларда).

Госман Бакиров сүз ала:

— Журнал елдан-ел байый бара. Журналда басылган һәрбер әсәр мине канәгатьләндерә. «Фронтовиклар» — әйбәт роман. Гата университетта гармун уйнап бара — мин бу эпизод белән килешмим. «Сүзсез җыр» — художник егет комбайннан картон алып, малайның чәчен кисеп, рәсем ясый. Бу эпизод белән дә килешмим. «Җилкәнне җилләр еккач»та Фәнияргә — гарип кешегә кызның кияүгә чыгуы белән килешмим. Фәнис Яруллин повестенда тел кимчелекләре редакцияләнмәгән.

Рафаэль Мостафин нотык тота:

— Күпчелек фикер белән килешәм. Килешмәгәнем — «Сүзсез җыр». Мәдинә Маликова төп геройны яратмаган, шуны повестька күчерә. Гаптелхак — матур табылган образ. Авылдагы авыру, шуны бирәү дә яратмый. Гаптелхак аның матур якларын күреп ярата. «Фронтовиклар» турындагы бәхәсләр хаклы. Әйбәт әсәр, кимчелеге бар. Роберт Әхмәтҗановның докладо әйбәт. Бигрәк тә башы, ахыры абстрактрак. Журналга мәкалә итеп эшләгәндә конкретлаштырыр дип ышанам.

Сүз **Хәсән Туфанг**а бирелә:

— Роберт Әхмәтҗанов сары чәчле кыз образын күз итеп алуда Мөдәррис Әгъләмовны гаепләде. Зөлфәттә бар, ди. Мин килешмим. Андый образ шигырьнең эчке рухыннан чыга. (Мисал китерә.)

Туган җирнең үсүе, үзгәрүе, халыкның үз йөзен саклавы Ренат Харисов шигырендә бик әйбәт бирелә. Халкыбызның үткәнен һәм үсү юлын әйбәт сиземли. Рәшит Гәрәй дә акка-карага битараф булмауны күтәрә. Мөдәррис Әгъләмов шигырьләренә тукталды Роберт, ләкин ул аның шигырьләрен шактый турады, үзенең эрудит икәнен күрсәтү өчен докладын терминнарга төрде.

Безнең поэзиябез, бәхәскә-нигә карамый, олы юлда баруын дәвам итә.

Хәсән Хәйри сөйли:

— Докладлар ошады. Яшьләр чыкты, җаваплы зур докладлар белән. Үз фикерләре бар. Докладларны киләчәктә дә курыкмыйча яшьләргә бирергә кирәк. Бигрәк тә ошаганы — поэзия турында. Очерк турындагы доклад — төпле эшләнгән, җыйнак.

Гази Кашшаф чыгыш ясый. Арткы планда – Хәсән Туфан, Нәкый Исәнбәт һ.б. 1966 ел

Гариф Ахунов, Гөлшәһидә ханым һәм Рафаэль Мостафин Ш.Камал музеенда

Журналны тикшерү идарә утырышында бара, димәк, редколлегиянең 8 айлык эшен тикшерәбез. Редколлегиядән чыгучы-сөйләүче булмады. Кирәк иде.

Журнал дөрес юлдан бара. Көннәнкөн яхшыра. Якын арада аның 100 меңгә җитәргә мөмкинлеге бар. Тәнкыйть мәкаләләрендә тәнкыйть проблемаларын күтәреп, бурычларын куеп язасы мәкаләләр бар әле.

Әдәбиятның үсү юлына, традицияләргә дөрес бәя бирү булырга тиеш. Юкса матбугатта нигилистик фразалар да очрап тора (татар әдәбиятының төрле этапларын инкяр итү).

Дөнья күләмендә барган әдәби көрәш журналда яктыртылмый. Тәрҗемә итеп булса да аны бирергә кирәк. Әдәби багланышларны да бирә барырга кирәктер.

Ниһаять, тел остасы Фатих Хөснигә дә сүз чираты җитә:

— Журналның 9 нчы санында татар прозасының бүгенге хәле турында бәхәс ачылды. Мин хәзер гел шуны уйлап яшим.

Бүгенге бәхәсләргә карата. Аяз шәхес мәсьәләсен кискен итеп куя. Бик төпченә. Кайвакыт ул хәл артыкка китә. «Урталыкта» повестенда Сәгыйть образында да бик казына. Сәгыйть авыру Баязит янына бару-бармауда тик икеләнә. «Сүзсез җыр» (А.Ганиев) миңа ошады. Гаптелхак шәхес буларак үзен расларга омтыла. Коллективта шәхеснең үз дәрәҗәсен тота белүе — бик әйбәт. Фәнил Мансуров повестена «Тургай картаймый» — дип Ибраһим Газидан алып куйган эпиграф дөрес түгел. Ибраһим Гази «Тургай да картаямы икән?» — дип куя мәсьәләне.

Гариф Ахунов, «Казан утлары»ның баш редакторы буларак, докладларның төпле, нык уйланылган булуын әйтте, тик Мәдинә Маликованың проза буенча ясаган докладында яшьлеккә хас категоричность булуын, вакыт-вакыт примитив фикер йөртелүен, докладчының эстетик кыйммәтләрне берьяклы аңлавын күрсәтеп үтте.

Баш редактор бүлек мөдирләре Яхъя

Сулдан уңга: Ренат Харис, Мәгъсум Гәрәев, Минтаһир Минһаҗев, Ринат Мөхәммәдиев һәм Гомәр Бәширов

Халитов (проза), Фәрваз Миңнуллин (әдәби тәнкыйть), Нури Арсланов (поэзия) иптәшләрнең журналны яхшы итеп чыгаруда күп көч куюларын билгеләде һәм шул нисбәттән «Очерк һәм публицистика» бүлегенең бер еллык эш тәҗрибәсе (мөдире — М.Хәмитов) бу бүлекнең гаять дәрәҗәдә сүлпән кыймылдавын, эшкә җавапсыз каравын әйтеп, әгәр алга таба да шулай барса, республикабыз һәм илебез күләмендә эшләнгән гаять зур эшләрнең журналдан читтә калачагын күрсәтте. Шуңа күрә Язучылар Союзының идарә утырышында якын арада М.Хәмитов иптәшнең отчётын тыңлауны утырышка куюларын үтенде.

Соңыннан 1973 елда журналда басылырга тиешле яңа әсәрләр, редакциянең планнары белән таныштырды.

Татарстан Язучылар идарәсе председателе урынбасары Гази Кашшаф, йомгак ясап, җыелышның файдалы һәм җитди булуын, җанлы узуын әйтте.

Татарстан Язучылар Союзы идарәсенең Председатель урынбасары
Гази Кашшаф

Җаваплы секретарь
Ренат Харисов

ӘДӘБИ МИРАС *

Роберт Әхмәтҗанов

(«Казан утлары»ның 1972 елгы 1-8 саннарында чыккан шигъри әсәрләребез турында)

Сүземне әдәби мирас мәсьәләсеннән башлап китәргә телим. Бездә әдәби мирасны барлау, аны, вакыт тузаныннан аралап, бүгенге укучыга тәкъдим итү эше, ничектер, үз агымына куелган. Әле бүген дә бу изге эш без көткән югарылыкта тора, дип әйтеп булмый. Мәрхүм әдипләрнең төрле сәбәпләр аркасында үз вакытында дөньяга чыга алмаган әсәрләрен, алар хакындагы истәлекләрне, хат һәм документларны матбугатта күрсәтү шул язучылар иҗат иткән чорның атмосферасын, вакытын кабат яңарта. Нәтиҗәдә, аларның иҗаты яңа гомер белән яшәп китә шикелле.

Журнал, бу әһәмиятле миссияне башлап җибәреп, бик әйбәт эшләде. Без аның узган саннарында Зыя Мансур, Шәрәф Мөдәррис һәм Гали Хуҗи иҗатлары белән кабат очраштык.

Кайбер иптәшләр сугыш һәм сугыштан соңгы еллар поэзиясен «өйрәнү

*Чыгыш-язма кыскартып бирелде.

Роберт Әхмәтҗанов

чоры» гына дип бәяләп китмәкче була. Янәсе, бүгенге көннәр таләбеннән чыгып караганда, 50 нче еллар шигърияте укучыларны тирән мәгънәле әсәрләр белән куандыра алмаган. Мондый фикер белән килешеп булмый. Андый бәячеләргә болай диясе килә: иптәшләр, аермыйк әле елларны еллардан, алар арасында киртә дә, чик тә юк ич! Алар — тоташ. Еллар, чорлар бер-беренә күпер булып сузыла. Бүгенге кайбер казанышларыбыз да шул еллар җирлегеннән килмимени?!.

Ул елларны һәм ул елларда иҗат иткән шагыйрьләрне миңа аз булса да күрергә туры килде. Ул еллар иҗат ялкыны белән кайнап, дәртләнеп яшәгән еллар иде. Бүгенге көннәрнең шигъри запасы әле дә булса шул окопды кырлардан, яңа гына блиндажлар тузанын кагып, автоматын тыныч көннәр каләменә алыштырган, түшләрен орден һәм медальләр бизәгән фронтовик рухыннан килә кебек, әдәби-эстетик кыйммәтләре ягыннан да бер дә түбән түгел иде ул еллар иҗаты! Дөресен әйткәндә, инде без ул елларда язылган әсәрләрне кулыбызга бик сирәк алабыз, яисә бөтенләй алмыйбыз...

Сугышның соңгы елында һәм җиңү салютыннан соң туган яшь буын аларның күбесен бөтенләй белми дә. Ә менә әдәби мирасны өйрәнү, вакыт-вакыт үткәннәргә дә борылып карау һич зарар итмәс иде безгә!

Менә мин журнал битләрендә Шәрәф Мөдәрриснең сигезьюллык шигырьләре белән яңадан очрашам. Шундый тыгыз хисле, ялкынлы, ашкынулы шигырьләр! Алар әдәби осталыклары, камиллекләре ягыннан да бүгенге шигърияттә үрнәк булырлык әсәрләр. Бу шагыйрьләрнең шәхси якларында да соклангыч сыйфатлар күп иде. Алар әдәбиятыбызга яшь алмаш тәрбияләүгә күп көч куйган иптәшләр. Алар бу юнәлештә чын күңелдән бирелеп, үз-үзләрен онытып эшләде.

Шәрәф Мөдәрриснең тәмамланмый калган җыры — «Полк намусы»исемле трагедиясе — гражданлык накалының югарылыгы, иҗат палитрасының байлыгы, окоп һәм блиндаж шартларында, ил азатлыгы өчен барган бөек көрәш фонында коммунистның тулы канлы образын тудыру һәм аның җитәкчелек көчен күрсәтү юнәлешендәге уңышлары белән үзенә бер героик сәхифә ул. Шигъри трагедия иҗат итү, күп планлы, полифоник сугыш симфониясе тудыру шагыйрьдән күп көч таләп иткәндер.

Бүгенге көннәрдә, яшь поэзиянең тыныч офыкларында безнең лирик шигырьләр, тыныч көйләр, иделлиягә якын парчалар калгып утырганда, шундый ялкынлы, киң сулышлы, эпик колачлы әсәрләргә күз төшерү, аларны киң масштаблы булулары ягыннан үрнәк итү зарар итмәс иде безгә.

Гомумән, бу әдипләрнең гаять бай шәхси-иҗтимагый гомер сәхифәләре безне, яшь әдипләрне, иҗатта һәм тормышта шактый күркәм сыйфатларга өйрәтер иде...

«Казан утлары»ның киләчәктә дә шундый әдәби мирас сәхифәләрен киңрәк, тулырак, эзлеклерәк яктыртуын телик. Алда әле безне төрле иҗади шәхесләр, мирасыбызның яңа үрнәкләре белән очрашулар көтә, дип ышаныйк.

1972.

*Язмаларны **Л.Лерон** әзерләде.* ■

«Минем шәҗәрәдә – Бөек Ватан сугышы еллары»
конкурсы нигезнамәсе

I. Гомуми нигез

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев инициативасы белән «Безнең мирас» журналы һәм «ТАТМЕДИА» ААҖе белән берлектә үткәрелә.

II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

Максат:

1. Шәҗәрәләр аша Бөек Ватан сугышы тарихында татар милләтенең урынын билгеләү, тарихи үзаңын формалаштыруга өлеш кертү.

Бурычлар:

1. Нәсел тарихы нигезендә Бөек Ватан сугышында һәм тылда катнашучыларны барлау.

2. Нәсел шәҗәрәсен төрле форматта, зәвыклы, башкаларга үрнәк булырлык итеп башкару күнекмәсен формалаштыру.

3. Гаилә тарихында гына сакланган шәхесләрне татар дөньясына чыгару.

4. Туган як тарихын өйрәнүгә кызыксындыру уяту һәм татар теленә мәхәббәт тәрбияләү.

5. Укучыларда ватанпәрвәрлек һәм әхлакый идеаллар тәрбияләү.

III. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

1 этап — 2014 елның июленнән — 2015 елның май аена кадәр.

Катнашучыларның яше чикләнми.

Йомгак 2015 елның 22 июнендә, Бөек Ватан сугышы башланган көнне ясала (яисә 2015 елның май аенда).

IV. Материалларны кабул итү тәртибе

Тапшырылырга тиешле материаллар:

— Төрле ысулда эшләнгән гаилә шәҗәрәсе, А4 форматында, 1 бит.

— Сугышта яисә тылда катнашучы турында бер битлек инша (14 нче шрифт, интервал — 1, формат А4). Өстәмә материал — шәхеснең фотосурәте.

— Материалларны әзерләүче турында белешмә: исем, фамилия, әтисе исеме тулысынча; туган елы, эшләгән яисә укыган урыны; элемтәгә керү өчен телефон, яисә электрон почта адресы булу зарур.

— Материаллар кәгазьдә басылган һәм электрон вариантта тапшырыла.

— Һәр конкурсант 2015 елның беренче ярты еллыгына «Безнең мирас» журналына язылган квитанциянең күчермәсен тәкъдим итә.

V. Бәя бирү шартлары

1. Шәҗәрәнең башкарылу үзенчәлеге (иҗади якын килү).

2. Башкарылу зәвыклылыгы, затлылыгы.

3. Шәҗәрәдә урнаштырылган буыннар саны.

4. Инша эчтәлегенең Бөек Ватан сугышы елларында булган гыйбрәтле вакыйганы чагылдыруы.

5. Иншаның язма сөйләм таләпләренә туры килүе.

VI. Йомгаклау һәм бәяләү

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» бәйгесенә нәтиҗә жюриенең йомгаклау утырышы карары беркетмәсе нигезендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире боерыгы белән рәсмиләштерелә. Җиңү яулаган авторларга редакциянең дипломнары, сертификатлары һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла. Яхшы дип табылган эшләргә журнал битләрендә басылу хокукы бирелә.

Шәҗәрәләрне аерым китапка туплап чыгару ихтималы да бар.

СӨЙКЕМЛЕ СӨЯКЛЕ ФИРДӘВЕС

Әзһәр Шакиров

Утырдым ла көймәнең, әй, читенә,
Карадым ла суның төбенә,
Су төпләрендә һич кара юк,
Күрәчәкне күрми чара юк.

«Гомеремнең узганын аккан су, искән җил кебек сизми дә калдым. Артка борылып карасам, үзәкләр өзелә», — дип язды Фирдәвес Әхтәмова. Без бит, артистка дигәч, гел чибәр, үзенә каратып торган, зифа буйлы, бик серле кыз баланы күз алдына китерәбез. Хәзер менә Фирдәвесне күз алдына китерегез: уртача буйлы, почык борынлы, шул кадәр гади, тыйнак, чын авыл кызы, ләкин бездә әйтәләр бит, бу кешенең сөйкемле сөяге бар, дип. Бу Фирдәвескә бик тә туры килә.

Фирдәвес урта мәктәпне Казанда тәмамлаган. Аның театр сәнгатенә кереп китүендә иң мөһим рольне Рәшидә апа Җиһаншина уйнаган.

«Мәктәпне тәмамлар алдыннан классыбызга зәңгәр костюм кигән, зәп-зәңгәр күзле бер апа килеп керде. Мәскәүдә Малый театр каршындагы училищеда татар студиясе ачылачагын, шуңа укучылар кабул ителәчәген сөйләде. Имтиханнар Галиәсгар Камал театрында узачак икән. Шул көннән башлап, минем өчен тынычлык бетте. Дистәгә якын укучы Рәшидә апага җырлап, биеп, шигырьләр укып күрсәттек. Шулар арасыннан бер малайга, ике кызга Рәшидә апа Җиһаншина гариза бирергә киңәш итте. Кызларның берсе — мин идем. Театрга имтихан бирергә барганда, кемнән күлмәк, кемнән туфли сорап тордым. Рәшидә апа: «Үкчәле туфли кисәң, әйбәтрәк булыр, буйлырак күренерсең,»— дигән иде. Сорап алган туфлиемне кулыма тотып барып, имтихан биргәндә генә кидем. Экзаменда үземне ошаттылар, кабул иттеләр. Бертуган апам Мәрьям, сөлге-эскәтерләрен сатып, зур гына фанер чемодан алып бирде. Шул чемоданны тотып, Мәскәү каласына китеп бардым», — дип яза Фирдәвес үзе. Менә шушы юлларны укыгач, башыма бер фикер килде. Нишләп әле безнең заманда инженер, врач баласы сәнгать, театр юлыннан китми? Бәлки бәхетсез, ятим, авыр тормышта яшәгән балалар гына чын сәнгатькә, әдәбиятка тартыладыр? Мин мәктәп директоры яисә колхоз председателе баласының театрда эшләп йөргәнен күрмәдем. Чөнки безнең заманда укымышлы татар гаиләсенең үз баласын андый катлаулы язмышка дучар итәсе килмәгән. Күрәсең, алар артист хезмәтен «үзләренчә» бик тирән аңлаганнардыр. Әлбәттә, театрда эшләр өчен туарга кирәк.



«Соңгы хат» (Х.Вахит) Розалия – Ф.Әхтәмова, Нияз – Н.Дунаев. 1966 ел

Фирдәвеснең дә бит әтисе сугышта һәлак була, әнисе дә аңа җиде яшь тулганда бу дөньядан китеп бара. Менә күз алдына китерегез шул ятим кыз баланы, тормыш аның аркасыннан сыйпап тормагандыр. Ә бит Фирдәвес шулкадәр шаян, шук, җитмәсә, үткен телле, һәрнәрсә аңа кызык, бер спектакльне калдырмый, кино турында әйтеп тә тормыйм. Сәнгать дөньясы белән кызыксынуы шулкадәр көчле иде ки — ул һәрвакыт безнең егетләр белән бергә булды. Гомумән, ул иптәш кызларына караганда, безнең белән күбрәк уртак тел таба белә иде. Равил Шәрәфи белән ничек итеп «Балет» биеп йөрүләре, Туфан Миңнуллинның беренче язмаларын кич буе тыңлап утырулары әле дә хәтеремдә, саный китсәң, алар шактый. Хәзер инде мин аның диплом спектакльләрендә нинди рольләр уйнаганын да хәтерләмим, ләкин сәхнәдә аңа игътибар итмичә калу мөмкин түгел иде. Театрга кайтып эшли башлаган елларында да аңа үзен күрсәтерлек рольләр булмады. Гөлсем Исәнгулова белән Нәҗибә Ихсановага бер-бер артлы зур-зур рольләр бирделәр. 1962 елның язында Празат абый Исәнбәт Мостай Кәримнең «Җырланмаган җыр» әсәрен сәхнәгә куйды. Аңа Рәхимә ролен бирде. Мостай Кәрим спектакльне карагач, Фирдәвескә үзенең китабын бүләк иткәндә беренче битенә: *«Фирдәвес сеңлем, Рәхимәне соклангыч итеп уйнавыгыз өчен рәхмәт»*, — дип

«Беренче театр» (Г.Камал) Биби – Ф.Әхтәмова, Хәмзә бай – Х.Уразиков

яза. Әлбәттә, Мостай ага Кәримнең бу сүзләре Фирдәвес өчен иң зур бүләк була. Аның күңелендә театрда эшләргә дә эшләргә, дигән теләк туа. Ләкин бәхет дигән әйбер бар бит ул: Фирдәвесне, артистка буларак, бөтенләй көтмәгәндә, икенче яктан ачып җибәрә. Ул Галиәсгар Камалның «Беренче театр» әсәре буенча куелган телефильмдагы Биби роле булды. Камалның бу әсәрен белмәгән кеше сирәктер, чөнки аны укытучылар да, балалар да укыйлар иде. Кызык бит, 50 елга якын гомер узган, әмма бүген дә шул фильмны карагач, Фирдәвеснең уенына ничек сокланмыйсың?! Ул фильмда Биби ролен ялкау, аңгыра, булдыксыз итеп уйнарга да мөмкин булыр иде, ләкин Фирдәвес уенында без бөтенләй икенче мәгънәне күрәбез. Аның күзләре шундый хәйләкәр: ул хуҗаларның нәрсә эшләгәннәрен, нинди кешеләр икәнен шулкадәр ачык итеп күрә ки, юк, бу ялкау, аңгыра кыз бала гына түгел, бер җае чыккач, ул алардан үзенең үчен ала, шуннан рәхәт, ләззәт таба. Гомумән, бу фильмны куйган режиссёр Ринат Сакаевка бик зур рәхмәт әйтәсе килә. Шушы фильмнан соң Фирдәвескә: «Кара әле, бу безнең Биби түгелме соң?» — дип эндәшәләр иде. Чөнки ул вакытта телевидениене меңләгән татар карый иде. Шулай итеп, Фирдәвес халкыбызның яраткан артисткасына әверелде.

Академия театрына Марсель Сәлимҗанов баш режиссёр булып килгәч, үзенең беренче эше итеп Хәй Вахитның «Соңгы хат» әсәрен сәхнәгә куйды. Бу спектакльдә Фирдәвес шәфкать туташы Розалия ролендә уйнады. Монда ул үзенең героинясын шундый шәфкатьле, керсез, кешелекле итеп күрсәтте ки, тамашачы күңеленә онытылмаслык булып кереп калды. Фирдәвескә бер-бер артлы зур рольләр бирә башладылар. Минем исемдә калганнары: А.Островскийның «Агай-эне ак мыек» әсәрендә — Липочка, Б.Горбатовның «Бер төн»ендә — Софья, К.Тинчуринның «Американ» әсәрендә — Мәйсәрә, Т.Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» әсәрендә — Алтынчәч, М.Гыйләҗевның «Бичура» әсәрендә — Хатын. Әлбәттә, 50 елдан артык театрда эшләгәндә уйнаган рольләре 100дән дә ашкандыр. Мин аларның һәрберсе турында язып тормыйм, чөнки дә тирәнтен өйрәнүне таләп итәләр.

Әйе, Фирдәвес сәхнәгә юкка гына чыкмый, бит аның тамашачыга әйтәсе фикере-сүзе бар! Ул һәрвакыт әйтә

иде: *«Тормышымның иң гүзәл чагы — театрдагы беренче унъеллык чоры булды. Ул елларда мин фәкать театр, әдәбият, шигърият белән яшәдем. Ир юк, гаилә, бала юк — иҗат кына бар».*

Фирдәвес рольләрне калын буяу белән түгел, ә бәлки акварель белән ясый, ягъни нечкә тойгылар белән образны тудырырга тырыша иде. Менә шул ягы белән ул безнең артисткалардан аерылып торды. Безнең тамашачы театрда ярылып яткан характерларны күрергә күнеккән. Хәер, мин инде язган идем, роль өстендә эшләгәндә һәр артистның үз алымы була, дип. Театрда артистка булып эшләү — тормыш өчен бик җайсыз хезмәт ул, чөнки синең эшеңне ирең аңламаса, хатынкызны бәхетсезлек көтә. Гомумән, театр дигән әйбер синең бөтен күңелеңне, җаныңны суырып ала. Әле ярый безнең театрда бәхетсезлекләр күп булмады. Фирдәвес бу яктан бәхетле, ире Марат Саматович аның театрдагы хезмәтен чын күңелдән аңлап, хөрмәт итеп кабул итә иде. Фирдәвес тә, Марат та 30 яшьләре узгач кына кавыштылар, шуңа күрә бер-берсен яхшы аңлыйлар иде. Мин ни өчен моны болай дип язам, чөнки аларга «төрле вакытта» — бакчада-дачада чакта кергәли торган идем. Бик кызганыч, Марат иртә вафат булды. Бик күп еллар Фирдәвеснең үзенә генә авыр тормыш алып барырга туры килде. Кызы Айгөл университетны уңышлы тәмамлап, монда үзенә кирәкле эш тапмагач, чит илдә яши башлагач, Фирдәвес бик нык үзгәрде. Болай да аның нәселендә бәхетсезлекләр берсе артыннан берсе килеп кенә торды. Иренең, абыйсының, апасының үлеме аңа искиткеч зур тәэсир ясады. Ул әйтә торган иде: «Нишләп безнең нәсел гомерле түгел микән?» — дип. Менә шушы фикерләр, үзенең ялгыз калуы аны ислам диненә китермәде микән, дип уйлыйм. Хәер, ул яшь чактан ук Аллаһы Тәгаләгә ышанган кеше. Безнең арадан, иң беренче булып, 60 яше тулгач, ул: «Мин театрдан китәм. Бу минем Сезнең белән соңгы очрашуым дип белегез. Мин Сезне яратам, хөрмәт итәм, барысы өчен дә Сезгә рәхмәт», — дип, тамашачы белән хушлашты. Шулвакытта миңа Фирдәвес нәрсә беләндер риза түгел, күңелендә нindидер үпкәсе бар сыман тоелды. Мин әйтәм: «Нигә инде тамашачыга чыгып, 60 яшеңдә шундый сүзләр әйтәсең, әле бит гомерең бар, театрда рольләр бирәләр», — дип, сүз күтәргән идем. «Мин үзем беләм», — диде. Аңа 60 яшьтән соң сәхнәдә тагын ун ел гомер уйнарга туры килде. Фәрит Бикчәнтәев аңа зур, мәгънәле рольләр биреп торды. Соңгы эшләренең берсе — Илгиз Зәйниевнең «Мәхәббәт турында сөйләшик» әсәрендә Абруй роле. Бу спектакльдә Фирдәвес укытучы ролен шундый югарылыкта, чын талантлы артистка буларак бөтен күңелен, җанын биреп уйнады. Инде 70 яше тулгач, ул бөтенләйгә сәхнә белән хушлашты. Әлбәттә, кайбер артистлар 60 яшь тулгач китәм, 70 яшем генә тулсын, хәзер театрдан китәм, дип сөйлиләр, ләкин сүзләрендә торучылар бик сирәк була. Мин инде язган идем, театрдан китү — гаиләдән китү белән бер, дип. Фирдәвес исә болай дип язды: *«Мин бәхетле, үзем теләгән, яраткан, язмышым итеп сайлаган театр дөньясында яшәдем. Ә хәзер бу театр дөньясыннан китүем белән бәхетле. Күз яшьләрем дә, бернинди үкенечләрем дә юк. Ахыры хәерле булсын!»* Фирдәвеснең театрдан китүенең сәбәпләренең берсе, күрәсең, ул — спектакль уйнаудан тәм тапмый башлау, икенчесе — ислам динен чын күңелдән кабул итү булгандыр. Шундый кешеләр бар, алар Ислам динен кабул иткәч, яшәү рәвешен үзгәртәләр. Мин ул кешеләргә сокланам, горурланам, шулвакытта гаҗәпләнәм дә. Фирдәвеснең үз-үзенә ышануы, рухи көче, бернигә карамастан, үз фикерендә калуы, ислам диненә китерүче сәбәпләрнең берседер. Шулай да ул театр сәнгатеннән берничек тә аерыла алмый. Менә ул ничек яза: *«Һич көтмәгәндә могҗиза булды. Мин аны Аллаһының олуг бүләге дип кабул иттем. «Бибинур» исемле тулы метражлы нәфис фильмда баш рольдә*

төшәргә мине чакырдылар. Шунда эшләп алган акчама 2008 елда Хаҗ кылдым. Аллаһ кабул итсен. Хыяллыга да курыккан теләгем тормышка ашты». Фильм 2010 елда Казандагы Халыкара мөселман кинофестивалендә Гран-При, ә Фирдәвес, хатын-кыз ролен иң яхшы башкаручы буларак, җиңү яулады. Бу роль Фирдәвеснең гомерен озайтты. Аны бөтенләй икенче яктан күрделәр, ягъни ул катлаулы, фаҗигале язмышларны да кинода уйный ала торган сәләтле артистка икәнен исбатлады. Картайган көнендә артистка өчен нинди зур бәхет!

Туфан Миңнуллин безнең театр училищесын тәмамлауга 50 ел тулуга багышланган фильм эшләргә теләде, сценарие дә язган иде. Хәтта фильмны үзенең фатирында төшерергә дә риза булды. Шуннан соң мин Фирдәвескә: «Әйдә, бергә төшик, аннан соң Нәҗибә белән төшәрбез», — дим. Шулвакыт Фирдәвес: «Миндә әле аның кайгысы юк, хәлем әйбәт түгел», — диде. Ә менә безнең училище бетереп кайтканга 50еллык бәйрәмне уздырганда, халык алдында ул үзен искиткеч матур тотты, шундый итеп сөйләде, күземә яшьләр килде. Шуннан соң мин аның белән очрашмадым. Бик нык авырый, дигәч, түзмәдем, шылтыраттым, югыйсә, әйтәләр иде: «Шылтыратып маташмагыз, телефонга килми, кеше килгәнне яратмый», — дип. Шылтыратуым булды, телефонны алды. Мин: «Хәлең ничек, бераз рәтләнәсең, дип ишеткән идем. Бер Ходайдан синең терелүеңне ялварып сорыйм», — дидем. Ул: «Алдагысын кем белгән», — дип, рәхмәт әйтеп, трубкасын куйды. Әле алай телефоннан сөйләшә алгач, терелеп тә китәр, дип уйладым. Минем белән сөйләшкәннән соң, биш көн узгач, ул вафат булды. Директорыбыз Шамил Закиров янына кергәч: «Без аны театрга куймыйбыз, аның васыяте шулай, ул үзен ире янына авылга күмәргә кушкан», — диде. Мин ни әйтергә дә белмәдем. Иртән ул яшәгән йорт янына барсак, урам тулы кеше, хушлашырга килгән. Тышта бик

«Бибинур» бүләк ала

салкын иде, шуңа карамастан, җыелып, саубуллаштык. Миңа бер-ике сүз әйтергә дә туры килде. Әлбәттә, бераз күңел китек булды. Артистканы Академия театрына куеп, тамашачы, дуслары белән бергә зурлап озатырга кирәк булган, барыбер бит урам тулы халык иде. Үзенең васыяте шундый дип, авызымны тиз яптылар. Нишләп үзен театрдан озаттырмагандыр, белмим, әллә озатырга кеше булмас, дип уйлаган, әллә инде дини йоланы бозарга теләмәде микән, һәрхәлдә, күңелемдә авыр тойгы калды. Авыл халкына, имамнарга, аны зурлап соңгы юлга озатканнары өчен, рәхмәтем чиксез. Әлбәттә, гел уйнап тормаса, татар халкы артистларны тиз оныта, чөнки рустагы кебек, гомерлеккә кала торган фильмнарыбыз юк шул. Әле ярый Фирдәвескә андый бәхет эләкте. Язмамны аның яраткан шигыре (Шәмсетдин кызы Рәшидә язган) белән тәмамлыйм:

Аллага шөкер кылам
сабырлык биргәненә,
Сабырлыкның савапларын
бирермен, дигәненә,
Аллага шөкер кылам
иманга кайтканыма,
Намаз укып, Коръән укып,
тынычлык тапканыма. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЛКА *г.* — Гарәпчә «халка» (сырга; бөҗра, түгәрәк, әйләнә) сүзеннән алынган. Риваятьләрдә Аллаһы Тәгалә әмере белән Җәбраил галәйһиссәлам оҗмахтан алка китереп, Һаҗәр ананың колагына кидергән, дип сөйләнә. Шуңа күрә алка тагу Исламда сөннәт гамәл булып исәпләнә.

Тарихта славян кенәзе Святославның бер колагына ике энҗе һәм кызыл якут кашлы алтын алка тагып йөрүе билгеле.

//Калач алка — зур алка («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән).

Татар телендә хоккей термины буларак «алка» (шайба) сүзе этимологиядән бихәбәр спорт комментаторлары тарафыннан көчләп тагылды, дияргә була.

//Бик зур һәм авыр алкалар асып колакларыгызны бозмагыз яки бөтенләй кимәгез. («Колак әдәпләре»ннән.)

АЛКОГОЛЬ *р.* – Гарәп алхимиклары кулланган *әл-куһел* (үтә вак порошок, онта) сүзеннән. Хәзерге мәгънәсе — исерткеч; спирт.

Коръәндәге 67 нче һәм 219 нчы сүрәләр пальма һәм йөзем җимешләреннән ясалган эчемлекне мактасалар да, соңрак иңгән сүрәләрдә эчкечелек шайтан фигыле дип бәяләнә. Мөселманнарда исерткеч эчемлек сату һәм куллану катгый тыелган. Бу кагыйдәне бозучылар өчен башта 40 тапкыр, аннары 80 тапкыр камчы белән суктыру карала (гаепләү өчен дүрт шаһит булуы шарт). Шул ук вакытта бихисап шагыйрьләр һәм суфилар шәрабны данлыклап язуларын һәм сөйләүләрен дәвам итәләр. Дөрес, бу мәдхияләр (мәс., Гомәр Хәйямдә) мистик эчтәлекле. Ә мөселманнарга җәннәттә вәгъдә кылынган шәраб күбрәк суга яки сөткә охшаган һәм эчкән кешене ул һич тә исертми. Бүген Согуд Гарәбстаны, Иран, Судан, Пакистан кебек мөселман илләрендә спиртлы эчемлек эчү тыелган, замани яшәү рәвеше кабул ителгән илләрдә дә аракы һәм шәраб куллануга карата күп санлы чикләүләр кертелде.

Алкогольле эчемлекләр төркиләргә бик күптәннән мәгълүм булган. Әйтик, брага, буза кебек атамалар рус теленә төрки телләрдән кергән дип исәпләнелә.

Тагын кара: әл-куһел. Сыра.

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынан басылып килә.

АЛЛИЛУЙЯ — Борынгы гыйбрани телдә «Алланы мактагыз» мәгънәсендә. Христианнарда чиркәү җырларында кушымта. Православиедә 3 тапкыр әйтелеп, аңа «Дан (Шөкер) сиңа, алла» («Слава тебе, господи») сүзләре өстәлә. Иудаизмда «аллилуйя» – Алланы данлыклаучы аваз. «Инҗил»нең татарчага яңа тәрҗемәсендә (2001) бу сүз *«Һалелуя»* язылышында бирелгән.

Татарча «алкыш» сүзенә дә туры килә кебек.

АЛМА — Татлы җимеш бирә торган агач. Гомумтөрки сүз. Мәхмүд Кашгари сүзлегендә (XI гасыр) — *алымла.* Монгол телендә охшаш сүз — *альмын.* Глазов яклары сөйләшендә кыргый алма агачын *сагалма* диләр. «Ихтимал, алма агачы Европадан таралгандыр», — дип яза д-р Р.Әхмәтьянов.

//*Алымла ярымы* — ярты алма. *Җир алмасы* — бәрәңге. *Кытай алмасы* — әфлисун. *Фарсы алмасы* — шәфталу, персик. *Алма коймак* — чокырлы-чокырлы итеп эшләнгән табада пешкән белен. *Күз алмасы. Бит алмасы.*

Ызгыш (җәнҗал) алмасы — яблоко раздора (русча). Борынгы грек мифында аллалар Фетиданы кияүгә биргәндә туйга Эрида дигән җәнҗал алиһәсен чакырмаганнар, дип сөйләнелә. Моңа ачуы чыккан Эрида туй мәҗлесендә утыручы алла һәм алиһәләр янына бер алма тәгәрәтеп кертеп җибәргән, имеш. Алмага: «иң-иң чибәргә» дип, язу язылган була. Шуннан соң мәҗлестә утыручы алиһәләрдән Гера, Афина һәм Афродита арасында алманың кемгә тиешлеге турында бәхәс купкан. Ахыр чиктә бу бәхәс канкоюлы Троя сугышына сәбәп булган имеш.

Шигърияттә «алма» — хатын-кыз күкрәге. *Алмалы алъяпкыч* дигәндә, ихтимал, хатын-кыз күкрәге күздә тотылган булыр. Андый алъяпкычның тирәкле алъяпкыч дигән атамасы да билгеле. //*Алмалы алъяпкычым әл дә бар сандык төбендә.* (Сөйләм теленнән.)

Гарәпчә алма — *төффах.*

АЛМАЗ — Безгә мәгълүм булган минералларның иң катысы. Химик яктан саф углеродтан (карбоннан) гыйбарәт. Бу сүзнең шәҗәрәсе гарәпчә *ал-мас* (иң каты) һәм грекча *адамас/адамантус* (җиңелмәс) сүзләренә барып тоташа. Алмаз сүзе татар һәм рус телләренә ныклап кереп урнашкан һәм сүзлекләрдә еш кына чит тел алынмасы буларак теркәлми дә. Татарда ир-ат исеме буларак еш очрый. Хатын-кыз исеме – *Алмазия.*

Шулай да татарча беренчел язылышы һәм әйтелеше алмас булган.

Башкача — *диамант* (нимесчәдән).

Махсус шомартылган үтә күренмәле алмаз *бриллиант* дип йөртелә (французча «бриллиант» — ялтыравыклы сүзеннән).

Борынгы кытайлар, алмазны асылташ буларак артык бәяләмәгәннәр, аны байлык символы итеп санамаганнар, ләкин аны башка асылташларны кырлау өчен, энҗеләрне тишү өчен кулланганнар. Алмазны «алтын катылыгы» дип атаганнар, чөнки ул алтын эчендә хасил була дип ышанганнар.

1955 елдан *ясалма алмазлар* җитештерелә башлады.

//*Куштымы ят токымны аз-маз,*
Шул мизгел үк катылыгын җуя алмаз.
Р.Шәфи. *Кара алмаз.*

АЛМАНИЯ — Германия. Гомумән алганда, тарихта *алманнар* герман кавеменнән бер халык булган. Бүгенге татарча басмаларда, төрекләргә ияреп, *нимес* яки *германлы* сүзен *алман* сүзе белән алмаштыру «процессы китте». Бер караганда, дөрес тә шикелле, чөнки моннан берничә йөз еллар элек руслар *нимес* (ягъни телсез, тел белми) дип инглизләргә дә әйткәннәр. Ләкин тарихилыкны җуймау өчен, әлбәттә, нимес (татарда гади сөйләмдә – *нимес, нимсә, нимеч/мимеч*) һәм алман сүзләрен бөтенләйгә сызып ташлауның кирәге юк. Әлбәттә, рус теле йогынтысыннан ерак торган элеккерәк чыганакларда алман сүзе актив, әйтик, 1953 елда Мюнхенда яшәгән татар-башкорт

интеллигентларының Гаяз Исхакый килү уңаеннан үткәрелгән мәҗлес беркетмәсендә фәкать «алман» атамасы гына кулланылган. Шулай да «герман» сүзе төгәлрәк, шуңа күрә аның потенциалы зуррак шикелле. Шуны да әйтеп китик, 1943 елның апреленнән 1944 елның июленә кадәр Германиядә татар әсирләре тарафыннан Гариф Солтан мөхәррирлегендә нәшер ителгән ике телле журнал «Германча-татарча белешмә» дип атала.

Бүген интернетта мәшһүр «Википедия»нең, *дейч* (нимес) версиясе белән беррәттән, *алман* версиясе дә барлыгын әйтеп китү урынлы булыр. Кыскасы, «алман» сүзе «герман» сүзенә тәңгәл мәгънәле түгел.

«Алман» атамасын төрки «алма» сүзенә бәйләргә тырышу да нигезсез.

Борынгы чыганакларда *Алемания/Алмания* Көнбатыш Европаны да белдергән.

Алмания атамасы сирәк кенә бүгенге фәнни әдәбиятта да очраштыра. *//Татарстан Фәннәр академиясе төзелгәнгә кадәр ТӘһТИ гуманитар һәм иҗтимагый гыйлемнәр буенча республика координация советын җитәкләде, якын һәм ерак чит илләрнең (шул җөмләдән, Төркия, Финляндия, Венгрия, Алмания, Англия , АКШ һ.б.) академик оешмалары һәм тюркология үзәкләре белән тыгыз иҗади элемтәләр урнаштырды.* Ким Миңнуллин.

АЛМАТЫ — 1997 елның 10 декабренә кадәр Казахстанның башкаласы (хәзер башкала *Астана*га күчерелде). *Олы* һәм *Кече Алмалы* (Алматы) елгалары буенда урнашкан. Алматы шәһәре XIX гасыр урталарында барлыкка килеп, соңыннан *Верный* дип исемләнгән.

Дөрес мәгънәсе *«Алма атасы»* түгел, бәлки *Алмалы* дигән сүз. Ә Алма-Ата сүзе 1921 елда Верный шәһәренең исемен үзгәрткәндә рәсми кәгазьләрдә киткән хәреф хатасы аркасында гына туган атама. Шуңа күрә СССР таркалганнан соң, казахларның шәһәрне

Алма-Ата шәһәре

кабат Алматы дип атый башлаулары дөреслекне кайтару гына булып тора. Шунысы кызык, Мәскәү матбугаты беркадәр вакыт Алматы дип язса да, бик тиз Алма-Ата вариантына кире кайтты һәм моңа, рус галимнәреннән бигрәк, «гади» милләтчеләре сәбәп булды шикелле (руслар шуңа ияләнгән, янәсе). Шул ук вакытта бик күптәннән күнегелгән Таллин шәһәренең исемен рус матбугатында хәзер, эстоннар үзләре язганча, ахырында ике «н» белән — Таллинн дип язалар һәм мондый куш тартыкны җырчы-шагыйрь Владимир Высоцкийның гына сузынкы аваз кебек итеп әйтә алуы берәүне дә уйландырмый.

//...соңрак СССРга кайтып, Алматыда торып калган Әнвәр Локман 1994 елда чыга башлаган татарча «Өмет» гәзитенең беренче мөхәррире булган иде. М.Госманов.

Шунысы игътибарны җәлеп итә, Татарстанда Балык Бистәсе районында урнашкан Югары Тегермәнлек авылы янындагы бер чишмә *Алматый чишмәсе* дип атала. Ул гына да түгел, Татарстан Репубикасының Ютазы районында *Алма-Ата* һәм Зәй районында *Алмалы* дигән торак пунктлар бар.

XIX гасырның урталарында Верный кальгасы янында *Татар бистәсе* (башта *Ташкент бистәсе* дип атала) барлыкка килгән. Бирегә Казан, Вятка, Тубыл якларыннан һәм Рәсәйнең башка төбәкләреннән татар сәүдәгәрләре һәм һөнәрчеләре күчеп килә. Алар бистәдә сабын кайнату, шәм кою, тире эшкәртү,

тун тегү, йон юу остаханәләренә нигез салалар. Бистәдә мәчет, мәдрәсә эшләп килә. 1879 елда анда 600ләп кеше яшәгән. Хәзерге вакытта ул Алматы шәһәре эчендә калган (Казан, Татар, Оренбург, Кырым, Уфа урамнары булуы билгеле).

Азәрбайҗан телендә — *Алмута.*

АЛМЫШ БИНЕ ШИЛКИ, АЛМЫШ ХАН — IX гасыр ахыры — X гасыр башында яшәгән. 895 елдан Идел буе Болгар дәүләтенең ханы. Чыганакларда *Алмас* варианты да очрый (Ак. Мирфатыйх Зәкиев *Алмуш* дип әйтүнең дөрес түгеллеген кисәтә). Габдулла Җилкиның (Шилкиның) улы. Мөселманча исеме — *Җәгъфәр бине Габдуллаһ.* Чыганакларда *илтибәр* титулы белән дә телгә алына. Алмыш хан соравы буенча, Багдад хәлифәсе Мөкътәдир Биллаһ Болгар иленә зур илчелек җибәргән. Илчелекнең сәркатибе һәм фактта җитәкчесе Әхмәд ибне Фазланның Идел буена бу сәфәре турында сәяхәтнамәсе бар. Шушы илчелек килгән вакытны (миляди белән 922 ел) Болгар илендә Исламның рәсми кабул ителү вакыты дип саныйлар, ләкин чынлыкта болгарлар моңа кадәр күптән мөселман булганнар инде.

Алмышның *Газан, Мал, Арбат, Ялкау* һәм *Микаиль, Арслан* исемле уллары булган. Өлкән улы Арбат Хорысланда Лачынга (Олег) хезмәт иткән («Җәгъфәр тарихы» буенча, агъни мәгълүмат ышанычлы түгел). Алмыш һәм аның улы Арбат рус тарихында венгрлар буларак (*Альмуш* һәм *Арпад*), ә болгар тарихында болгарлар буларак сурәтләнә. Алмышның Мал исемле улы рус тарихында *Добрыня* дип исемләнә (И.Р.Мусина).

Ш.Мәрҗани үзенең Фәннәр академиясенә язган хатында Алмыш хан турында түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Чөнки аларның *(Болгар мәликләренең — А.Т.)* иң элек мөселман булганнары, Алмасхан Сәлки хан углы, Габбасилардан Мөкътәдир Биллаһка буйсынуны бурыч итеп алып, Габбасиларны баш белеп, акчаларны алар исеменә, хотбәләрне аларга кылалар иде. Һәм бар эштә дә аларга охшауны үзләренә һөнәр итеп алганнар иде. Хәтта электәге гади «хан» титулын «әмир»гә, ә үзенең исемен Алмастан Җәгъфәргә алыштырып, «әл-Әмир Җәгъфәр» дип исемләнде, ә углына «әмир Әхмәт» дип куйды... Минем фикеремчә, аның нәселе Тимур һөҗүменә кадәр исән иде. Ләкин Чыңгыз нәселләренә буйсынуда иделәр. Болгар әмирләреннән Тимур тарафыннан үтерелгән әмир Габдулла шуларның соңгысы, дип уйлыйм». Мәрҗани, гарәп галиме Мәсгудигә таянып, Болгар патшасы Җәгъфәр бине Габдуллаһның 943 елда илле меңле атлы гаскәр белән Константинопольгә каршы сугышып баруы турында яза.

Алмыш хан Багдад хәлифәсе илчелеген кабул итә. В.Лаптев рәсеме. 1945-1949 еллар

АЛТЫН БӨРТЕК *тар.* — Борынгы Казан территориясендә, Архиерей дачасында табылган кабер ташындагы язмага караганда, миляди белән 1297 елның 27 сентябрендә (һиҗри 696 елда) вафат булган болгар бикәсе.

«АЛТЫН ТОБЧИ» — Галим лама Лубсан Данзан язган тарихи хезмәт (XVII гасыр). Бу елъязма Кытай иероглифлары транскрипциясендә генә билгеле булган «Монголларның яшерен тарихы»ның (1240 елда язылган) эчтәлеген сөйләп чыга. ■

Риф Якупов фотосы

ЮЛЛАРЫБЫЗГА ИЗГЕ КАПКАЛАР АЧЫЛСЫН!

Фирдәвес Гарипова

Татар географик атамалары җыелмасында терминнар бик күп. Аларның күп булуы – халкыбызның югары дәрәҗәдәге мәдәни үсешкә ирешүенең бер чагылышы. Мәгълүм ки, Урта Идел буйларында һәм башка төбәкләрдә дә географик берәмлекләр һәм аларның атамалары алыштыргысыз кыйммәткә ия булып тора. Чөнки алар чал борынгылыктан киләләр.

Капка. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә капка лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм аның мәгънәсе болай аңлатылган: Корылма, стена, койма һ.б.ш. урыннарда кереп-чыгып йөрү өчен махсус эшләнгән ачыклык һәм шул кереп-чыгып йөрү урынын ябу өчен тупсалы җайланма. *Шулвакыт завод капкасыннан бик күп кешеләр күренде. А.Алиш. Бер көтү малай, тупырдашып, басу капкасына таба йөгерә иде. И.Гази.* // Күчерелмә мәгънәдә, сөйләмдә. Хуҗалык. *Капка рәтеннән көтүгә бер сыер яки алты баш сарык яки ике кәҗә җибәргән кешедә иртә, кич берәр тапкыр ашыйбыз. М.Гали.* (1, II т.: 45)

Биектау районы, Урта Алат авылы. XIX гасыр азагы капкасы

Соңгы очрактагы капканың мәгънәсе географик атама белән дә бәйләнешле булырга мөмкин. Капка — хуҗалыкка мөнәсәбәтле лексик берәмлек.

Филология фәннәре кандидаты, татар теленең диалектларын тәфсилләп өйрәнгән диалектолог-галимә Нәҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, «капка» лексик берәмлеге җыен атамалары составында да кулланыла. Кушкапка җыенын Сулы һәм Сая (Казансуның уң кушылдыклары) ярына утырган Зур Битаман, Кече Битаман, Йуас, Әсән, Бикнарат, Кодаш, Зур Көек, Олы Рәс, Кече Рәс авыллары халкы, июнь ахырында бергә җыелып, Зур Битаман һәм Кече Рәс авыллары арасындагы түгәрәк аланда үткәргән. Җыелып күңел ачу җыенының атамасы Кушкапка Зур Битаман авылы янындагы Кушкапка исемен йөрткән тауга нисбәтән барлыкка килгән. Халык телендә сакланган риваятьләргә караганда, бу урында ныгытылган җирле үзидарә булган.

Кушкапка җыенының икенче исеме — Кушнарат — шулай ук географик атама исеменнән алынган. (2; 27)



Арча районы, Утар-Аты авылы. XX йөз башы капкасы







а) иннек капка;
б) җил капка;
в) тәбәнәк «татар капкасы»;

Ризаэддин Фәхретдинов мәгълүматларына таянып, галимә җыен үткәрелә торган урында монгол чорларына кадәрге вакытларга нисбәтле шактый гына археологик истәлекләр урнашканлыгын күрсәтә. Боларга Бигеш, Чирмешән, Иске Көлкәш, Кызыл Тау авыллыклары керә.

«Җыен» атамасы — Кушкапка-«пар капка» мәгънәсен аңлата һәм ул ниндидер ныгытылган пункт яисә ныгытылган шәһәрлек булып, күрсәтелгән авылларның үзәге булгандыр». (2: 60)

«Капка» лексик берәмлеге Адлер Тимергалин төзегән «Миллият сүзлеге»ндә болай дип бирелгән: «Капка — искечә — «капу, капугъ» (күк капусы ачылу сүзендә саклан-

Кушкапка исемендәге җыен Тау ягы төбәгендә дә үткәрелгән. Тау ягы белән Казан арты нык бәйләнгән. Казан арты белән тау ягы төбәгендә бер төрле әйтелешле һәм язылышлы атамалар шактый очрый. Димәк, халык күченеп яшәгән.

Нажия Борһанова Тау ягындагы Кушкапка җыенының кайчан үткәрелүен һәм аны бәйрәм итүдә нинди авыллар катнашуын ачыклый.

«Кушкапка» — зур җыен исәпләнгән һәм аны арыш чәчәк аткан вакытта, июнь урталарында, Зөя елгасының сул кушылдыклары Бола һәм Чирмешән елгалары бассейнына урнашкан Югары Балтай, Түбән Балтай, Зур Бакырчы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чиргү, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Коллар, Шәмәк, Күшем, Тутай, Аксу, Дәүләки, Багыш авыллары халкы үткәргән», — дип яза ул.

ган). Чыгышы — каплау сүзеннән. Кап, капкач сүзләре дә шул тамырдан килә. Сөйләшләрдә — кабак (күк кабагы ачылу сүзе шуңардан).

Тагын кара: Җилкапка; Иннек капка; Урыс капка (Кала капка); Орчык; Тимер капка; Казан капкалары» (2: 227).

Җилкапка — такта җитмәү сәбәпле, киртәләрдән оештырып ясалган ачылмалы капка. Капка баганалары өстә киң такта белән тоташтырылган, ләкин капка орчыгы озын булмаган, баганага ике җирдән бәйләп яки коршаулап куелган. Янәшәдәге кече капканың төзелеше дә охшаш булган (диагональ тоташтырмасыз) *// Җилкапкалар бетте инде бездә, Урыс капка кордык, өстен ябып. (Чыңгыз Мусин дүртьюллыгыннан.)*

Чаг.: Иннек капка.

Иннек капка — «Иннек» дип ке-

г) баганалы, биек «татар капкасы»; д) «урыс капка» (баганалы, биек, ике яктан түбәле капка);





нә дә йөртелә, арата капка. Берсе өстенә берсе куелган аркылы киртә-торыклардан торган капка. Башкача — киртә капка. Аннан кергәндә торыкларны оештырып ясалган булса да, орчыклы, ягъни ачылышлы булган.

Кала капка — Зур такта капка, Урыс капкасы.

Орчык — «Авыл капкаларының вертикаль күчәрен дә «орчык» диләр. Капка орчыгының башы (тубыгы яки үкчәсе) кереп утыра торган таш яки агачны «орчык төбәге» яки «орчык тупсасы» дип атаганнар (2: 18, 169, 198, 221).

«Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә (2009) Кабак: 1. Мишәр диалектында, аерым алганда сергач, ләмбрә, хвалын сөйләшләрендә капка (ворота). Ләмбрә һәм хвалын сөйләшләрендә кабак тагын йорт, өй, хуҗалык (дом) мәгънәсендә дә әйләнештә йөри.

Ач кабак кычкыру — кузнецки сөйләшендә килен төшкәндә егет йортының капкасын ачтыру. Кабак эс(те) — мишәр диалектының ләмбрә, хвалын сөйләшләрендә — капка төбе. Кабаг эстенә чыгу — мишәр диалектының карсун, кузнецки сөйләшләрендә капка төбенә чыгып утыру. Кабак-кура — чистай сөйләшендә капкалар, каралтылар. Кабак — стәрлетамак сөйләшендә — үр (возвышенность).

Кабак эс(те) — мишәр диалектында, аерым алганда хвалын, ләмбрә, темников сөйләшләрендә — капка төбе (место у ворот).

Кабаг эстенә чыгу — Карсун, кузнецки сөйләшләрендә — капка төбенә чыгып утыру (выходить вечером на посиделки у ворот).

Кабак-кура — чистай сөйләшендә — капкалар, каралтылар (ворота и надворные постройки). (4: 265)

«Капка» лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла: Такталачык капкасы — Актаныш районы Чалманарат авылы янындагы урын атамасы. Зират басу капкасы — Актаныш районы Семистрау (Өшәр) авылының басу ягындагы капкасы. Биш мунча ягы капкасы —Азнакай районы Әлкәй авылының капка атамасы. Танай капкасы — Азнакай районы Әлкәй авылы янындагы урын атамасы. Бикбау капкасы — Балтач районы Арбаш авылы янындагы урын атамасы. Информант — Гыйбадулла абзый. Ялгалы капкасы — Актаныш районы Чалманарат авылы

янындагы элекке атамасы. Йугары оч басу капкасы — Семистрау (Өшәр) авылы (Актаныш районы). Зират капкасы — Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы капка атамасы. Мрәз капкасы — Саба районы Олы Шыңар авылы янындагы урын атамасы. Информант — С.Якупов. Му капкасы — Арча районы иске Му авылы. Бу капка Казанбаш авылыннан югарырак булган. Басу капкасы — Апас районы Иске Йомралы авылы янындагы капка атамасы. Басу капкасы — Апас районы Иске Әнәле авылы янында. Юнәлеш күрсәтә торган атама. Капка имән күле — Майна елгасы бассейны, Спас районы Иске Рәҗәп авылы янындагы күл. Капкалы куак — Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы. Капкалы тау — Кама Тамагы районы Балчыклы авылы янындагы тау атамасы. Информант — Р.Төхфәтуллина. Капка чокыр тавы — Баулы районы Татар Кандызы авылы янындагы тау атамасы. Информант — Фәрдия апа. Капкалы куак — Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы.

Кала капкасы — Яшел Үзән районы Мулла Иле авылы янындагы капка атамасы. Югары оч басу капкасы — Актаныш районы Семистрау (Өшәр) авылы янындагы басу капкасы. Камы капкасы — Азнакай районы Әлкәй авылы капкасы.

«Капка» лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында да шактый очрый. Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романында җил капка лексик берәмлеге бик матур һәм урынлы файдаланыла: *«Гайнан зиратның оч кенә араталы җил капкасын сак кына ачып эчкә керде».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестенда капка лексик берәмлеге еш кабатлана: *«Капка төбенә ни арада өч-дүрт хатын-кыз җыелып өлгергән, барысы да, яшь катыш елмаю белән, тыкрыктан чыгып килгән Асафны карап торалар иде».* Шул ук автор «Ут чәчәге» исеме алган повестенда җилкапка лексик берәмлегеннән дә файдаланган: *«Ат кузгалагын ерып, карт җилкапкага кадәр озата килде».*

Фатих Хөснинең «Бер ана балалары» хикәясендә капка лексик берәмлеге болай кулланыла: *«Иртән көтү куган чакларда ничек тә булса кеше күзенә чалынмаска тырыша, капкасын ача да чыгарып җибәрә иде теге өч баш вак терлекне».*

Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» дип дөнья күргән повестенда мондый юллар очратабыз: *«Бар өмете, бөтен хыяллары һәм ниятләре күз ачып йомганчы чәлпәрәмә килгән капка төбеннән Хәбир көчкә кузгалып китте. Елыйсы килде.»*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» романында басу капкасы гыйбарәсе оста сурәтләнгән: *«Ирек белән Рәйсә җәяүләп басу капкасына якынлаштылар... Күңеленнән егет малайларның капка ачуларын тели, шуңа өметләнеп, кесәсенә вак акчалар да салган иде. Капка ябык, малайлар юк. «Аларның кайтасыларын ишетмәгәннәр шул ... Ирек, чемоданын җиргә куйды да, капканы киереп — атлы арба үтәрлек итеп ачты. — Әйдә, «килен», төкле аягың белән рәхим ит безнең авылга! — Рәйсәне күтәреп ачык капкадан алып керде. — Бәхет капкасы бу, белеп тор! Без ачып керткән килennәр бар да безнең авылга гомерлеккә килделәр!»*

Капу, Капуг, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем, искергән», дип бирелгән һәм беренче мәгънәсе — кара: «капка» дип ныгытылган. *«Зиндан капусы янында ук бер төнге каравылчы солдат стенага сөялеп гырылдап йокламакта иде».* Ш.Мөхәммәдев.

Икенче мәгънәсе — кара: капкач дип җибәрелгән. *«Тәрәзәмнең капусына Моңлы кош килеп кунган».* Җыр. (1, 2 т: 17).

Төзүче-авторы Адлер Тимергалин булган «Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек»тә: «капу, капуг» — борынгы төрки дип бирелгән һәм беренче

Л.Гобәйдуллин фотосы

Биектау районы. XX гасыр капкасы

мәгънәсе болай аңлатылган: *«Капка. Кап/кап — а ябу, каплау фигыленнән».* (Р.Әхмәтҗанов) // Күк капусы ачылу (күк кабагы ачылу — метеор яңгыры, йолдыз яңгыры; ләкин электә төньяк балкышының гына күк капусы ачылу дип аталган булуы бик мөмкин, сүзнең бу мәгънәсе 1966 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә дә теркәлгән). Шуңа бәйле рәвештә капу сүзе «бәхет капкачы ачылу» мәгънәсен дә белдергән.

Электә ай шикелле түгәрәк итеп ясалган капканы «айкапу» дип атаганнар. *«Үзе өчен бер кемсә хәер сорашмактан бер капу ачса, Алла хәзрәтләре ачар аңа фәкыйрълектән җитмеш капу».* Муса Акъегет.

Икенче мәгънәсе. Борынгы төркичәдә идарәченең кабул итү бүлмәсе. // Капуг башчысы — борынгы чорда ханның кабул итү эшләрен оештыручы. Аны «капуг башлар» һәм «капуг ил башы» дип тә йөрткәннәр.

Тагын кара: «Кабак». (3: 227)

Капу берәмлеге белән географик атамалар аз. Шулай да берничә генә булса да очрады: Капу — Кама елгасы ярындагы кечерәк кенә калкулык. Чаллы шәһәре янындарак. Капу елгасы — Ширәмәт елгасы бассейнында. Капу күпере — Әтнә районының Ябынчы авылы янындагы элекке күпер.

Бу лексик берәмлек төрки халыкларда шактый очрый. Төрек телендә — капу; кырым татарлары телендә — капу, хапу «ишек, капка; император сарае ишеге» дигәнне аңлата. (Радлов, II: 414-415, 1693). Татар теле лексик берәмлекләргә бик бай. Бу мәкаләдән күренгәнчә, капканың да әйтелеш вариантлары, мәгънәләренең дә төрлелеге күренә.

Чыганаклар

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. — II т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1979.
2. Бурганова Н.Б. О системе народного праздника джиен у казанских татар (исследование и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. — Казань, 1982. — С.20-67.
3. Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек. Төзүчеавторы Адлер Тимергалин. — Казан: Мәгариф, 2007.
4. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. — Казан: Татар кит. нәшр., 2009.
5. Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий. Т. II. — СПб., 1899.

Фотолар «Тартарика. Этнография» атласыннан, Ф.Вәлиевнең «Татарский народный орнамент», «Народное декоративное искусство Татарстана» китапларыннан алынды. ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның июль ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде

Печән базарында

Печән базарында общественный корпус янында акчадан карта уйнап торганда Дәүләтша Җиһаншин, Сөләйман Гыймранов, Сәлахетдин Булатов дигән кешеләр тотылганнар. Карталары һәм уенга куйган акчалары мөсадәрә ителгән [конфискацияләнгән].

1914. — №450. — 1 июль

Хифзыссыйххәткә [сәламәтлекне саклауга] даир

Симферополь хифзыссыйхәт попечительство рәисе врач Кондорский Казанның хифзыссыйхәт бюросы мөдире Н.П.Даниловка түбәндәге хатны җибәргән: «Мөхтәрәм Николай Петрович! Кырымдагы мөселман халкының кырылуына (үлеп бетүенә) каршы тору максаты белән Симферополь шәһәре хифзыссыйхәткә даир әсәрләр (рисалә вә аерым кагыйдәләр) бастырып, мөмкин кадәр бушлай мөселман халкы арасына таратырга карар бирде. Кырымдагы мөселманнарның кырылуына каршы тору секциясе татар телендә нәшер ителгән хифзыссыйхәткә даир язылган вә тәрҗемә ителгән әсәрләрне җыядыр. Җәнапларыгыз да шуңа даир әсәрләрне табып җибәрүдән баш тартмассыз, диеп өмид итәбез».

Мөселман халкына вә мөселман китапчыларына, шәһәр управасына тыйббия вә сыйххия (медико-санитарный) бюросына, Н.П.Даниловка халык телендә хифзыссыйхәткә даир язылган әсәрләр бирүне үтенәбез.

1914. — №451. — 2 июль

Театрны сакларга

Шәһәр театрын караучы, шәһәр театрына ут төртүләр[1] ешая башлаганлык сәбәпле, шәһәр идарәсеннән театр янына күбрәк каравылчылар куелуын сораган.

1914. — №452. — 3 июль

Мәкәрҗәдә газета

Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында Ибраһим Кулиев[2] вә Мөхәммәд Идрисовлар[3] тарафыннан чыгарылырга уйланган «Мәкәрҗә хәбәрләре» газетасының чыгарылуы үзләреннән булмаган сәбәп илә киләсе елга калдырылган.

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Театрда 1860, 1874 елларда зур янгын була. 1919 елда булган янгында хәрабәләр генә кала.

[2] Кулиев Ибраһим Габделвахит улы (1885-1936) — тәрҗемәче, журналист, татар теле белгече, сүзлекләр авторы.

[3] Идрисов Мөхәммәд (1882-1948) — китап басу остасы, рәссам.

Тынычландырган

Шәһәр көтүенең көтүчесен Карякина сыеры көтүдән качып, Казанка аркылы йөзеп чыгып, өенә кайтуы белән йөдәтә икән. Көтүче моңа «гакыл» тапкан — тоткан да сыерны тышаулаган. Сыер да «әмәлен» белгән — тышаулы көе качып, Казанкага кереп, батып үлгән. Сыер 200 сум тора икән. Моның заманы[4] табигый: көтүче белән шәһәр арасында мөштәрәк [уртак] булырга тугры киләчәк[5].

1914. — №453. — 4 июль

Страхование җәмгыятенә әгъза сайлау

Бу көн, җиденче июльдә, взаимное страхование җыелышы булачак. Мәҗлестә мәрхүм Мөхәммәдҗан Сәйдәшев урынына[6] идарә әгъзалыгына яңа кеше сайланачактыр. Җәмгыятьнең иске мәрасиме (традициясе) буенча бу әгъза мөселманнардан сайланырга тиешле. Мәҗлескә мөселманнар күбрәк килсәләр, әлбәттә, бу мөмкин булыр. Әгәр дә аз килсәләр, теләмәгән бер кеше сайланыр. Без, үз тарафыбыздан, мелла Габдулла хәзрәтне[7] мәгъкуль [лаек] күрәбез. Моннан мөкаддәмге [элекке] мәҗлестә хәзрәткә фәкать бер шар җитмәгән иде. Димәк, фәкать бер мөселманнан эш калган иде. Хәзерге мәҗлестә моның тутырылуын өмид итәбез[8].

Татарча театр

Җомга көн, 4ендә, Панаев бакчасында[9] «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан куелган спектакльгә кеше күп килгән иде. Тамашага куелган өч әсәрнең беренчесе — «Мәсхәрәләнмеш ханым»[10] — төзелешендә зәгыйфьлеге белән уйнаучыларны байтак уңайсызлыкка төшерә. Сәхнә тормышын, тамашачыларның хәлен игътибарга алып төзелгән «Табылдык»[11] уйнала башлагач, рух бөтенләй үзгәрә. «Мәсхәрәләнмеш ханым»да мәсхәрә була язып калган шул ук артистлар бөтенләй башкалар. Бу әсәрнең һәр ике пәрдәсендә манзаралар кинематограф лентасын хәтерләтәләр.

Бу әсәрдәге итекче Фәтхетдин (Үзбәк[12]) белән аның хатыны Былбыл (Болгарская[13]) никадәр мәһарәт [осталык] күрсәтсәләр, өстәлче Фәсхетдин (Иманский[14]) да шулкадәр үк мәһарәт күрсәтте. Фәкать шулкадәрлесен хәтердән чыгармаска кирәк ки, иртәгә никах мәҗлесе дигәндә, үзенә казаки сатып алу өчен кәләшеннән 2 сум алуга мохтаҗ бер балта остасының

[4] Заман — бу очракта бернәрсәнең бәясен түләү мәгънәсендә.
[5] Ягъни көтүче белән шәһәр управасы бу сумманы үзара бүлешеп түләячәкләр.
[6] Күренекле эшкуар, «Бәянел-хак» газетасының нашире Сәйдәшев Мөхәммәдҗан Әхмәтҗан улы 1914 елда вафат була (1865 елда туган).
[7] Габдулла хәзрәт — сүз Печән базары мәчетенең имамы Габдулла Апанаев (1862-1919) турында бара.
[8] «Кояш» газетасының 9 июль санында (№ 457): «... мөселманнар шулкадәр күп килгән иде ки, мәҗлес мөселманнар җыелышын хәтерләтә иде. Беренче нәүбәттә үткән мәҗлеснең протоколы укылып, Габдулла мелла Апанаев тасхих [төзәтмә] кертелеп кабул ителде», — дип языла.
[9] Панаев бакчасы — хәзерге «Динамо» стадионы урынында булган бакча.
[10] «Түләшү, яхуд Мәсхәрәләнмеш ханым» — А.Н.Островскийның «Без вины виноватые» комедиясеннән В.Әхмәдуллинның үзгәртелгән тәрҗемәсе.
[11] «Табылдык» — тулы исеме «Табылдык, яхуд Итекче Фәтхетдин һәм өстәлче Фәсхетдин». Ф.А.Ярыгинның комедиясе. Әсәрне Г.Сәйфелмөлеков үзгәртеп тәрҗемә итә.
[12] Үзбәк — драматург, артист Кәрим Тинчуринның сәхнә псевдонимы.
[13] Болгарская Гөлсем Муса кызы (1891-1968) — актриса.
[14] Мортазин-Иманский Вәлиулла (1885-1938) — артист, режиссёр.

яхшы ук җиренә җиткереп, вальс көе көйләве һәм вальс танцысы биюе бик гарип тоела. Мөмкин булганда балта остасына муафикъ [туры килгән] бер биюгә алмаштыру мәслихәт булса кирәк.

Яхшы ук рухлы үткән бу комедиядән соң, тамашаның хатимәсе [йомгаклау өлеше] буларак уйналган, татар артистлары тормышын яхшы белеп төзелгән «Артист[15]» нам [исемле] көлкедә дә уйнаучылар һәммәсе иттифак белән муаффәкыятьле [уңышлы] уйнадылар. Бу уенда мактанчык бай малае Шәрәфи ролен уйнаган К.Үзбәк Тинчуринның иң соңгы аккордка хосусый бер гүзәл аһәң бирүе тамашачыларны бигрәк тә мәмнүн итте.

1914. — №455. — 7 июль

Яңа дамбаны[16] төзәтү

Элекке әгъзалардан гыйбарәт булган элекке шәһәр управасы, хөкүмәттән алынган хезмәт белән иганә сәрмаясыннан [акчасыннан] 400 мең сумга төшереп, яңа дамба салдырган иде һәм шушы «салынган» яңа дамба сәясендә шәһәр халкы өч елдан бирле Усиягә[17] тугры юлдан йөри алмыйча, Бишбалта аркылы «сәяхәт» итәргә мәҗбүр булганнар иде. Ахырында яңа әгъзалардан тәшкил ителгән хәзерге управа бу дамбаны йөрерлек хәлгә китерергә тотынды. Моның өчен ташлар алынды, Нижнийдан, Самардан, Казаннан ташчылар китертелде вә җыелды. Таш җыюлар ашыгычлык белән бара. Хәзер дамбада 200 кадәр кеше, 70 кадәр ат эшләп тора. Шулай булса да, дамба иң кирәк вакытка, Мәкәрҗәгә мал җибәрү вакыты җитүгә өлгертелеп җитмәгән. Кичегүгә сәбәп тә, дамбаның читләренә, чокырларга туфрак тутырулар булган. Болар электән эшләнгән булса, хәзерендә вакытлы өлгергән булачак иде. Туфрак тутыру эшләре шәһәргә 1500 сумнарга төшәчәк.

1914. — №456. — 8 июль

Яңа дамба. 1925 елгы карта

Хәзерге заманда

---

[15] «Артист» — бер пәрдәлек комедия. Г.Кариев әсәре.

[16] Яңа дамба — Бишбалта (Киров) һәм Кизическая (Ленин) дамбаларыннан соң төзелгән. Хәзерге Казан тимер юл вокзалы артыннан үзәнлек буенча Идел елгасының Дальнее Устье пристанена юнәлгән дамба. 1956-1958 елларда Куйбышев сусаклагычы астында кала. Хәзерге топографик картада, утрау булып, кайбер өлешләре күренә.

[17] Усия — Дальнее Устье пристане — Казансуның Иделгә койган урыны янында булган. Казан сәүдәгәрләре бу пристаньнан Мәкәрҗә ярминкәсенә һәм башка шәһәрләргә Идел аша мал алып барганнар. 1958 елдан су астында.

Тукаев конфетлары

Ибраһимовлар[18] кярханәсе «Альфа» фабрикасының эше булган Тукаев конфетлары гаять ләззәтле вә татлыдыр. Аеруча рамазанда ифтар вә тәравих чәйләре өчен иң муафикъ конфеттыр.

1914. — №459. — 11 июль

Мобилизация

Шәһәрдә төрле урыннарга бу мәзмунда [эчтәлектә] игъламнамәләр [белдерүләр] ябыштырылып чыгылды:

1) Падишаһ әгъзәм хәзрәтләренең гаскәр вә флотны хәрби халәткә китерү хакында фәрман галияләре садир булды [барлыкка килде].

Мобилизациянең беренче көне пәнҗешәмбе 17 нче июльгә тәгаен ителгән. Казан военское повинностное присутствиесе нижний чиннарны шушы көнгә Казанга дәгъвәт кыла һәм җомга көн 18 нче июльгә сборный пунктка чакыра. Нижний чиннар хезмәт итә торган мөәссәсәләргә [оешмаларга], аларның хисабын бетереп азат итәргә игълан итә.

2) 4тән 15кә кадәр яшьле, биеклеге аршин 14 вершоктан[19] ким булмаган, йөксез һәм яшь тайсыз таза атларны 17сендә иртәнге 8 сәгатькә мәйданнарга (төрле участкалар өчен махсус урыннар күрсәтеп, махсус игъламнамәләр хәзерләнгән) китерергә. Икенче көн — җомга көннең иртәсендә кабул ителгән атларны шул ук мәйданнарга китереп тапшырырга.

1914. — №465. — 18 июль

Шәһәр управасы

Шәһәр управасы язу белгән мөселман яшьләре дикъкатенә гарыз итүебезне үтенә: мобилизация сәбәпле, шәһәр управасы язучыларга мохтаҗ булып калган. Управа өчен һәр өстәлгә бер мөселман язучы булындыру матлуб [таләп ителгән]. Теләгән кешедән шәһәр управасы секретарена мөрәҗәгать итүе үтенелә.

1914. — №466. — 20 июль

Игълан

Бу көн, иртән сәгать унда, Русиягә сугыш игълан ителү сәбәпле, рус гаскәриенә галәбә [җиңү] теләп, Казан меллалары тарафыннан Юнысовлар мәйданында зур дога булачактыр.

Мосафирлар

Казан мәдрәсәи «Мөхәммәдия» таләбәләреннән [шәкертләреннән] Борһан әфәнде Хәбиб вә Семиреченская область Тукмаклы Шәриф әфәнде Рәхимов шәһәребездә мосафирлардыр.

Шәриф әфәнде Бәйрүт-Американ көллиясе [университеты] таләбәләреннәндер. Борһан әфәнде исә мәзкүр көллиянең фәнун шөгъбәсен [бүлеген] тәкмил [бетерү] илә диплом алып, тәхсилен [укуын] тәмам итеп кайтмактадыр.

1914. — №467. — 21 июль

---

[18] Ибраһимов Вәлиулла — 2 нче гильдия сәүдәгәр. Казанның «конфет патшасы».

[19] Бер аршин 14 вершок якынча 132 см.га тигез. (1 аршин = 0,7112 м; 1 вершок = 4,445 см).

r Дога нөмаишләре [тантаналары]

Якшәмбе көн чиркәүләрдә гыйбадәт тәмам булганнан соң падишаһка һәм Ватан сәламәтлегенә дога нөмаишләре ясалды. Кичке сәгать 11дә яңадан дога нөмаишләре ясалган. Бу нөмаиш падишаһ хәзрәтләренә һәм Ватан саклыгына догалар һәм «Ура!» тавышлары белән урамнарда йөрелеп, иртәнгә кадәр дәвам иткән. Дүшәмбе көн Казан имамнары тәхте риясәтендә [рәислегендә] падишаһ хәзрәтләренә, Ватан сәламәтлегенә дога нөмаишләре ясалды. Тәкбир әйтеп урамнарда йөрелде.

1914. — №468. — 22 июль

q Казан губернаторының игъланы

Ошбу июльнең 24ендә көндезге сәгать 2дән башлап, Казанның театр мәйданында[20] автомобиль һәм мотоцикллар кабул итү башланачак. Хәрби-автомобильная повинность хакындагы положение[21] нигезендә, үзе йөри торган машиналар хуҗалары, үзе йөри торган һәммә машиналарны шушы урынга гарыз итәргә тиешләрдер. Машиналарны сынап карау[22], губернатор начальнигы белән округ штабы билгеләгән комиссия тарафыннан, шушы театр мәйданында һәм Грузинская урамында[23] иҗраэ ителәчәктер [башкарылачак].

1914. — №470. — 24 июль

r Зыялылар күп

Шәһәр идарәсе мохтариятендә хезмәт итүчеләр гаскәргә алынгач, алар урынына язу хезмәтенә кешеләр дәгъвәт ителгән иде. Инде хәзер, бу урыннарга керергә теләп, бик күп гариза килгән. Араларында зур гына укымышлылар да очрыйлар. Мөселман зыялыларыннан да байтак гаризалар бар. Килгән гаризалар кирәктән бик күпкә артык. Димәк, Казанда укыганнарның микъдары кирәгеннән артык дәрәҗәгә җиткән инде.

1914. — №472. — 27 июль

q Бозлы яңгыр

Кичә, 29 нчы июльдә, көндезге 2 сәгатьтән башлап 3 тулганга кадәр каты яңгыр булды. Баштарак, күк күкрәп, яшен яшьнәп, ун дәкыйкадан [минуттан] артыграк вакыт эреле боз белән катыш явып, бөтен урамнар тулды вә суга батты. Урамнарда сатып утыручыларның алма вә кыярлары агып киткәне күренде. Җөмләдән, Чечеткин номерлары алдының шундый агызылган яшелчәләр белән тулганы күренде. Балык базарында[24] да бу хәлне күрергә мөмкин иде. Болактан яртылай су тулып акты.

1914. — №474. — 30 июль ■

---

[20] Театр мәйданы — хәзерге Ирек мәйданы.
[21] Военно-автомобильная повинность турындагы нигезләмә Николай II тарафыннан 1914 елның 17 июлендә раслана һәм шул ук көндә округларга мобилизация турында телеграмма таратыла. Бу нигезләмә чиновникларның бер өлешенә, мещаннарга, сәүдәгәрләргә һәм хәлле крестьяннарга кагылган.
[22] Комиссия тарафыннан машинаның сугыш өчен яраклылыгы тикшерелгән. Сугышка алынган очракта хуҗасына банк аша акча күчерелгән.
[23] Грузинская урамы — хәзерге Карл Маркс урамы.
[24] Балык базары — хәзерге Тукай мәйданы.

Мәзәкләр

«Шура» журналы, 1909 ел

Басмага **Рәисә Шәрәфиева** әзерләде.

] Сәяси гамәл...

Бер карт үзенең якын бер дустына: «Угылымның зиһене, фикере вә белеме тәмам җирендә, фәкать ялганчы чыкты, ялганчы адәм кулыннан һич эш килмәс!» — дидекендә, дусты да: «Ул илә исә [алайса], угылыңны сәясәт адәмнәре арасына кергез! Сәясәт галәмендә ялганчылык кадәр могтәбәр [хөрмәтле] бернәрсә юктыр!» — димештер.

[Яшь хатын хыялы

Карт хаҗилардән бере үзенең бик сөя торган яшь хатынын янына чакырып: «Бәлки бән бу хасталыгымнан шифа тапмам, әгәр дә вафат итсәм, үземезнең хезмәтемездә улган Габдуллага варырсың, бик уңган егеттер!» — дидекендә, хатыны: «Үзем дә хәтеремдә күптән шуны фикерләп йөрим!» — димештер.

] Кемгә ни шарт?

«Дини журнал чыгарыр идем, буның өчен нә кеби шәйләр белергә кирәк?» — дигәнгә, мәшвәрәт итүчеләрдән берен Мисырның олуг адәмнәреннән бере: «Бу көндә ислам диненә гаид журнал чыгарыр өчен Коръән илә хәдис гыйлемнәрен тәмам белергә кирәк вә аның өстенә дә дәрелфөнүн дәресләреннән шәһадәтнамә алырга кирәк, әмма урам уртасында анадан туган рәвештә йөрерлек дәрәҗәдә тинтәк улган адәм өчен һичнәрсә шарт түгел», — дип җавап вирмештер.

Ләтаиф // Шура. — 1909. — №24. — Б.767.

] Падишаһның зирәклеге

Французларда иске мөхәррирләрдән бере, бер хикәят язып, гомумият илә хатыннардан көлмеш иде. Шулвакыт падишаһның сарай хатыннары буңа бик ачуландылар һәм дә сарайга китертеп үз куллары илә кыйнап ачу алмакны падишаһтан үтенделәр. Падишаһ, хатыннарның морадларын [теләкләрен] җиренә китермәк өчен, мөхәррирне сарайга китерде вә тышкы киемнәрне чишендертеп, хатыннарга: «Эстәдегеңез [теләгәнегез] кадәр кыйнагыз, фәкать арада иң ямьсезеңез элек уларак кыйный башламак шарттыр, башлаңыз!» — диде. Ун дәкыйка [минут], егерме дәкыйка үтте, кулларында улган таягы илә башлап кыйнаучы улмады. Падишаһ та мөхәрриргә: «Кыйнамыйлар, инде киенеп кайтып кит!» — диде.

[Ахмакка ни кирәк?!

Тәхеткә чыктыгына 25 ел тулдыгына ядкәр улмак өчен Солтан Габделхәмит бөек бер мәдрәсә тәэсис итмәк фикеренә кереп, мәшһүр мөстәшрикъ Вамберига бу мәдрәсәдә укылачак дәресләр хакында программ төзергә боермыштыр. Вамбери тарафыннан тәртип ителмеш программда тарих, фәлсәфә, икътисади, сәяси фәннәрне керттегендә, урыныннан сикереп торып: «Рәшид әфәнде! Бу фәннәр безем мөселманнар өчен дә, хосус бәнем өчен дә файдалы улмас, бунларны төшерергә кирәк!» — димеш. Буңа җавап уларак, Вамбери: «Әфәндем, тарих, фәлсәфә, икътисад вә сәяси укымаган шәкертләр ахмак улып җитешәләр, ахмаклар җитештерер өчен сезләрдә мәдрәсәләр күп, тәрар яңа бер мәдрәсә тәэсис хаҗәт күрелми!» — димештер.

Ләтаиф // Шура. — 1909. - №22. — Б.700. ■

«ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» БИТЛӘРЕННӘН...

ТАБЫШ

(Аңлатмалы сүзлек язуга тәҗрибә)

Табыш! Яңа табылдык! Әпкәлинең гаять бай архивыннан әдәбиятыбыз өчен бик тә кыйммәтле булган кульъязма — Әпкәли үзе исән чакта тәмамлый алмый калган аңлатмалы сүзлек табылды. Сүзлекнең төзелү принцибы кызыклы. Әпкәли беренче компонент итеп әдәбият белемендә, әдәби тәнкыйтьтә һәм язучыларның рәсми чыгышларында кулланыла торган сүзләрне һәм төшенчәләрне ала. Ә карасаң, шул ук сүзләрне һәм төшенчәләрне гадиерәк, аңлаешлырак һәм кыскарак итеп тә әйтеп була икән. Әнә шундый гади һәм аңлаешлы сүзләрне Әпкәли икенче компонент итеп ала. Түбәндә без укучыларыбызга сүзлекнең Әпкәли эшләп калдырган кадәресен тәкъдим итәбез:

Пөхтә киенгән, төз гәүдәле, йөзендә һәрвакыт елмаю балкып тора торган, матур борынлы, зәңгәр күзле, кара кашлы, бөдрә чәчле кеше — ***уңай герой.***

Иләмсез зур корсак үстергән, һәрвакыт караңгы чырайлы, тукмак кадәр күксел-кызыл борынлы, карлыккан тавышлы, җимерек кашлы, акай күзле пеләш кеше — ***кире герой.***

Урта кул укучы — ***урта белемле.***

Югары зәвыклы укучы — ***югары уку йортын бетергән.***

Әдәбият һәм сәнгать кануннарына җавап бирми торган китап — ***халтура*** (чүп, пүчтәк дигән вариантлары да бар).

Ритмик закончалыклар һәм рифма системасына җавап бирми торган поэзия әсәре — ***телне сындыра торган шигырь.***

Затлы зәвык һәм әдәбият-сәнгатьнең югары таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр җыентыгы — ***шәп китап.***

Артык нык сентиментализмга бирелеп, примитив хисләрне идеаллаштырырга тырышып, трагик пессимизмга бирелеп язылган шигъри әсәр — ***елак шигырь.***

Дөреслекнең күзенә карап, сәнгатьчә дөреслек рухында тормышны купшыландырмыйча, бизәмичә язылган шигъри әсәр — ***усал шигырь.***

Сюжет линиясе, образлар эзлеклелеге, логик бәйләнеше булмаган әсәр — ***геройларны бер-берсенә төкерек белән генә ябыштырып кую.*** (Монысы Ф. Хөсни терминологиясеннән алынды.)

Әдәби әсәрдә тапталган, кулланышта йөри-йөри шомарып беткән, төссез һәм хиссез сүзләр, фразалар гына кулланып язу — ***гәҗит теле.***

Әдәби әсәрдә «ләбаса», «ләса», «ләсә»»дигән сүзләрне кулланып язу — ***Хәсән Туфанга иярү.***

Әсәрдәге җөмләләрдә бик күп тел бизәкләре куллану, җөмләне сыгылмалы итү, логик төзеклек булмаганда, хәтта грамматика, синтаксис кануннарын да исәпкә алмау, җор теллелек — ***Фатих Хөснигә иярү.***

Җөмләне шигырь юлының уртасында төгәлләп, бер үк җөмләнең дәвамын яки азагын икенче строфага ук чыгарып язу — ***Сибгат Хәкимгә ияргү.***

Ярты ел вакыт эчендә берничә роман һәм повесть язу — ***Мәхмүт Хәсәновка ияргү.***

Язучының үзе белмәгән тормыш материалын үз иҗатында иң дөрес хәл итүе — ***темага керешмәү.***

Теләсә нинди шартларда, теләсә кайсы урында шигырь язарга сәләте булган шагыйрь — ***фатирсыз шагыйрь.***

*(Сүзлекне матбугатка яшь әпкәлиивед **Г.Рәхим** әзерләде. Язучыларның «Тынгысыз каләм»дигән дивар газетасыннан. 1980.)*

Гәрәй Рәхим

....

НУРИ АРСЛАН ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН ТЕЗМӘ

Акыл белән эш ит диләр миңа,
Ә йөрәкне кая куясы?
Анда һаман әле давыл уйный,
Анда һаман «җеннәр оясы»!

***

Рус кызлары мәхәббәттә кыю,
Авызын үпсәң, бирә телләрен,
Бер кабынса мөмкин түгел тыю —
Әйләндерми башын кемнәрнең?

***

Син карыйсың һаман элеккечә, —
Тик күзләрең бераз сагышлы...
Язмыш ятлар белән табыштырды,
Җаным синең белән кавышты!

***

Лимон сары, лимон төсле
Сагыш саргайта икән,
Саргаеп сагынган саен
Мәхәббәт арта икән.

***

Ак мендәргә башын куеп яткан,
Ә гәүдәсе ярым ялангач...
Матурлыгын кая яшерсен ул
Чын алиһә булып яралгач?!

Нури Арслан

***

Нинди үкенеч!..
Үтте-китте гомерем:
Танып беләлмәдем, кичектем:
Тик сукырайгач, чын йөзеңне күрдем,
Чукраклангач өнең ишеттем...

***

Дөнья гариплеген айкап,
Ачып йөрисе килә.
Кыштай салкын күңелләрнең
Карын көрисе килә.

***

Арткан саен тәҗрибәм,
Кими яхшы тәрҗемәм.

***
Җирдә күрелмәгән һәйкәл булып
Менеп бастым ташка,
Кошлар, болытлар да миннән түбән —
Минем аяк аста.

***
Иртеш буйларыннан гына
Атлыйсым калган икән.
Шул Кәрәкәүдән Казанга
Кайтмыйсым калган икән...

***
Таулар да туза, тарала —
Дөнья ул калыр бездән дә,
Гомер бер дә узмас диеп,
Гамьсезләнмә, гамьсезләнмә.

***
Мин — Идел, син ярым булсаң,
Ташыр да тулыр идем.
Акчарлагым, янда булсаң.
Балык та булыр идем.

***
Егерменче гасыр баласы мин,
Акылым минем асыл.
Бар тылсымын беләм табигатьнең:
«Сим-сим, ачыл! Ачыл!»

***
Шагыйрь гомере кыска була, диләр,
Әйбәт кеше, диләр, гомерсез.
Әйтсәм әйтим, моны минем яшьтә
Ишетүе шактый күңелсез.

***
Туктатырга теләп бирәүләре
Таш атарлар эткә — тиярләр...
Ә мин — кеше, миңа туры карап:
«Сынаттың бит, Нури!» — диярләр.

***
Әй йөрәк, бер җилләнеп кал,
Агармагае чәчләр:
Картларга карап, гыйбрәт ал,
Яшьләргә карап, яшәр!

(«Тынгысыз каләм», 1982)

....

Камил Кәримов

Made in Schale (Камил Кәримов)

ИКЕ ШАГЫЙРЬ, БЕР ШАГЫЙРӘ...

1

Автобус эченнән чыккач, Әхмәт Гадел як-ягына карамаска тырышты — болай да танырга тиешләр... Акъелганың паром килеп төртелә торган җирендә көтеп торабыз дигәннәрие. Чемоданнар белән бәреп, көянтәләр белән төрткәләсәләр дә төшкән җиреннән кузгалалмады ул, автобус ишегенә ябышып тик басып торды: читкәрәк китсәң, гади халык арасына чумып буталуың бар, анда инде синең шагыйрь икәнлегеңә беркем дә ышанмас, җитмәсә, Мәхмүт Хөсәен эче чыккан портфелен дә тоттырып китте, ояты ни тора! Бар бит дөньяның каруннары, 60 ел буе шигырь яза, юньле сумкасы да юк. Әнә, Риф Гатауллин — Фәннур Сафин шигырьләренең музыкаль редакторы гына булып исәпләнсә дә, кулындагы дипломаты германский, бәдрәфкә кергәндә дә үзеннән калдырмый.

Бөтен нәрсәгә җен ачуы чыкты Әхмәтнең. Кәефе тәмам кырылды. Язучылар төркеме ясап чыгасы калмаган. «Социалистик Татарстан» корреспонденты булып йөрүгә ни җитә! Бервакыт шулай Биектау яшелчә базасын «өшкерергә» дип сәфәр чыгарга торганда тәрәз турысына «Көмеш кылган җыры»ның сигнал данәсе төсле өр-яңа «Волга» килеп туктамасынмы.

Шофёры гына түгел, Биектауның өч дәрәҗәле түрәсе дә килгән иде. Әхмәтнең җиленнән машиналары белән дер калтырап торалар:

— Әхмәт Гаязович, сезне каршы алырга килдек, — диләр. Каян ишетеп алганнар диген?! Биектау белән Казан арасы Туфан Миңнуллин «Волга»сы белән дә атна үтмәле юл бит әле ул. Вәт, ичмасам, биектаулылар! Норлат ит комбинатын, Актаныштагы кәнфит заводын, Питрәчнең сөт-май комбинатын тикшергәндә дә шулай булды... Мондый кунакчыл хуҗаларга ничек итеп тел-теш тидерергә кирәк!

Ә менә алексеевскийлылар Кама ярына килеп алырга да иренгәннәр.

Әхмәт Гадел

Ничава, Әхмәт Гаделнең кем икәнен соң булса да белерсез әле сез!

Алар дүрт кеше: Әхмәт Гадел, Мәхмүт Хөсәен, Риф Гатауллин һәм... (хәер, дүртенчесен танырлык түгел, ул әле яңа автор) попутный машина көтә-көтә, Алексеевск ягына җәяүләп атлый тордылар. Берәр багана арасын үткән саен Әхмәт борын яулыгы белән ботинка йөзенең тузанын сөртеп-сөртеп алгалады. Ниндидер бер миһербанлы шофёр Мәхмүт Хөсәеннең кул астына килеп туктады. Авызы-борыны җимерелсә дә, «УАЗ»игы аягында шәп басып тора. Ялындырып тормадылар, менеп тә утырдылар.

Әллә гомер буе ялгыз яшәгәнлектән, Мәхмүт Хөсәен тынлыкны бик өнәп бетерми. Ул шофёрны сөйләндерде.

— Ник буш кайтып киләсең?

Мәхмүт Хөсәен

— Ниндидер писательләрне каршы алырга җибәргәннәр иде. Тапмадым.

— Без бит инде ул писательләр! — диде Әхмәт ярсуыннан теге борын яулыгы белән күзләрен сөртә-сөртә.

2

— Нинди әдәби очрашу, нинди кичәләр ди ул тагын! — Колхоз рәисе шагыйрьләргә күтәрелеп карамаска тырышты, бары тик каурыйсыман болыт кебек озынча аксыл кашларын гына җилфердәтеп утырды. — Уттай янып торган кыр уртасына бер тамчы яңгыр төшкәне юк. Ә сез күңел ачып, кәмит оештырып йөрмәкче буласыз. Әнә, күккә карагыз — җәй башыннан бирле бер генә болыт әсәре дә күренгәне юк.

Фәннур бу рәисне ирексездән кызганып куйды, ниндидер юату сүзе әйтәсе иде моңа.

— Минем бәхет — судан, — диде Әхмәт көр тавыш белән. — Авыл җиренә аяк басуым була, артымнан яңгыр килеп җитә... теләсәм, кәнишне.

— Да-ну! Юкны сөйләп тормасана!

— Менә, ышанмасагыз, Мәхмүт Хөсәеннән сорагыз, ул белә.

Рәиснең каурыйсыман кашлары

Гөлшат Зәйнашева

йөнтәс болытка әверелде, күзләреннән яңгыр тамчысыдай күз яшьләре бәреп чыкты.

— Әгәр бүген яңгыр яудырсаң, мин сине шәраб диңгезендә йөздерәм, хәтта диңгезнең үги кызын да тотып бирәм.

— Күпме яңгыр кирәк?

— 250 миллиметр җитәргә тиеш.

— Граммга әйләндергәч, әзрәк икән шул...

Ә кичен көләч күк йөзенең кашы җыерылды, язучылар чыгыш ясыйсы клуб өстен генә түгел, хәтта бөтен авылны болыт каплап алды. Шыбыр-шыбыр, чыпыр-чыпыр яңгыр ява башлады. Сукмакларның тотанагы бетте, бөтенләй йөрерлек түгел, колхоз ашханәсенең банкет залыннан фатир хуҗасының өенә хәтле дүртаякланып кайтырга туры килде... И сөенде халык. И сөенде... Күргән бер кешенең авызы җырылып кына тора.

Яңгыр иртә белән дә туктамаган иде әле. «Алга» колхозыннан «Волга» колхозына хәбәр килеп җитте:

— Алло! Бездә яңгыр коя бит әле!

— Башка анекдотың юкмы, — диде «Волга» рәисе скептикларча гына.

— Ышанмасаң, тыңла! — Һәм «Алга» рәисе телефон трубкасын ачык тәрәзәгә якын китерде. Анда — шыбыр-шыбыр, чыпыр-чыпыр, чаптыр-чоптыр яңгыр тавышы.

«Волга»лылар тынсыз калды.

— Вообщем, — диде «Алга» ныкы, — мин сиңа яңгыр яудыручы егетне җибәрәм, шартын китереп, каршы ал. Яңгыр бушлай яумый ул...

— Аңлашылды, — диде «Волга»-ныкы. — Өемдә бер ящик алып куйганым бар.

— Егет дигәнем — шагыйрь кеше...

— Алайса, тагын бер-ике ящик әзерләп куярмын.

Һәм Фәннурларны «Алга»дан «Волга»га китереп бушаттылар. Анда да яңгыр яудыргач, «Энгельс», «Татарстан» колхозлары да коры калмады... Ә бер атнадан бөтен Тәтеш районы яңгырга кинәнде. Коепмы коя! Сукмаклар елгага әверелде, инешләр дәрья булды, карабодай басулары — майсыз боткага әйләнде.

«Алга»ныкылар Фәннурларны көчкә эзләп таптылар.

— Зинһар өчен туктат яңгырыңны. Районыбыз агып китә бит...

Алар, артык бәхәсләшеп тормыйча гына, юлга чыкты. Тәтеш районында яңгыр явып калды...

3

— Гөлшат апа, юлга чыгабызмы?

— Кайсы районга?

— Биектауга.

— Анда бөтнек үсәме соң?

— Каян килсен?!

— Бәлки мәтрүшкә бардыр, валериан үләне, үги ана яфрагы, кара әрем?

— Сукыр кычыткан да юкмы?

— Шәһәр кырыендагы районда калдырмаганнардыр шул, Гөлшат апа.

— Алайса, әйдәгез, Баулы ягына. Анда печән дә шәп үсә.

— Балакаем, шулай да райкомга шылтыратып белеш әле, үсә микән?

Районга килеп төшүгә, келәмле юл туп-туры райкомның беренче секретаре бүлмәсенә алып килә иде. Баулыда да шулай булды.

— Йә, сөйләп җибәрегез, Казанда нинди яңалыклар бар, — дип башлады секретарь, Гөлшат Зәйнашевадан

язучылар турысында бер-ике маҗара ишетергә теләп.

— Яңалык дип, быел никтер сукыр кычыткан чәчәк атып өлгермәде. Җәй үтеп бара инде, бака үләне белән әче әрем дә юньле түгел.

— Ул үләннәрнең берәр файдасы бармы соң? — диде секретарь, елмаюын яшерә алмыйча.

— Кайсы җирегез авырта? — Җавап ишетелгәнче Гөлшат Зәйнашева тәрәзә төбендә коргаксып утырган шикәрле гөлгә секретарь эчә торган кувшиннан су сибеп килде.

— Авырткан җирем юк-югын да... аяклар гына алҗый.

— И-и! Берние юк аның, зәңгәр чәчәк суына утырырга гына кирәк.

Кулдан-кулга, авырудан-авыруга, өйдән-өйгә йөрттеләр Гөлшат Зәйнашеваны...

Бер клуб мөдире Ык суында көнозын балык чирттереп утырганда кулын кармакка ерттырган. Гөлшат Зәйнашева аның кулын чистотел үләне белән ябып куйды. Бер укытучының маңгаена сөял чыгып килә иде — шикәрле гөл яптылар. Склад мөдиренең тамак төбенә каклаган каз сөяге кадалган иде — Гөлшат Зәйнашева тартып алды, алды да тамак төбен чайкарга әрем компоты әзерләп бирде.

Кыскасы, бер атна эчендә Баулы шәһәре бүльницләрендә чиратлар бермә-бер кимеде. Инде саубуллашып китеп бардым дигәндә генә Зәйнашеваны Бөгелмә аэропортында эзләп таптылар. Йокысызлык белән интегә торган бер авыл советы председателенең хатыны эзләп килгән.

— Икенче көн инде, ирем йокысыннан уяна алмый, син аңа нәрсә эчергәниең, — ди.

— Сукыр кычыткан төнәтмәсе генә ул, ашыгычлык белән күбрәк салынгандыр, беркая да китмәс, уяныр!

— Бар бит дөньяның талантлы шагыйрәләре! — дип сокланып калды теге хатын.

(«Тынгысыз каләм», 1982)

Гамил Афзал

Гамил Афзал
ЯШЬЛӘРГӘ БЕР-ИКЕ СҮЗ

— Янам, янам! — ди ул укучыга,
Имеш, аңа яну бик читен.
Авызыннан зәңгәр төтен чыга,
Дәлил булып чыга шул төтен.

***

Данлыларның данына сырыштың,
Дансызларга карамадың;
Бик күпләргә ярарга тырыштың,
Беркемгә дә ярамадың.

***

Мин берни дә белмәгәнемне беләм.
Сократ.

Белем кирәк һәр чакта, дим,
Белем кирәк, дибез.
И Ходаем, Сократ та мин —
Берни дә белмибез.

***

Бөтен шагыйрь күзе үткер күрә,
Үтерерлек күлә;
Күлә белми торган елак шагыйрь —
Ярты шагыйрь генә.

(«Тынгысыз каләм», 1973)

Зөлфәт Хәйруллин һәм
Рөстәм Нуриев шаржлары

ФЕНОМЕН

Расиха Фәизова

Владимир Александрович Попов 1924 елның 24 июнендә Мариуполь шәһәрендә хәрби гаиләсендә туа. 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша. Өч сугышчан орден һәм 15тән артык медаль белән бүләкләнә. 1951 елда Казан сәнгать училищесын «5»ле билгеләренә генә тәмамлый. 1955 елдан Бөтенроссия, ә 1963 елдан чит ил күргәзмәләрендә катнаша башлый.

Россиянең атказанган рәссамы, Татарстанның халык рәссамы, Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, ЮНЕСКО каршындагы Халыкара сынлы сәнгать ассоциациясе әгъзасы, нәкышче, акварельче, график буларак танылган рәссам соңгы 20 елда тулысынча гарәби каллиграфия (шәмаил, тугра, каллиграфик композицияләр) белән шөгыльләнә. Сәнгатьнең бу төренә килгәндә, рәссамга 70 яшь (!) була.

Рәссамның 100гә якын эше төрле музейларда, көнбатыш һәм шәрык илләрендә шәхси тупланмаларда саклана.

— Мин гомер буе дәрвиш сыман ил гиздем, аркама капчыгымны аса идем дә икешәр айга, яки яртышар елга чыгып китә торган идем, — дип әйтмәсә дә, Владимир Поповның чирәм җирләрне торгызучыларны да, БАМ төзелешендә эшләүчеләрне дә, Үзәк Азия якларындагы мәһабәт мәчетләрен, Россиянең чиркәүләрен кыл каләме белән берәмберәм «барлавын» эшләре әйтеп тора. 2000 елда Иранда узган Коръән һәм каллиграфия форумында куелган экспозициядә катнашып, дөньяның 17 мәшһүр каллиграфы арасында көмеш медальгә һәм дә алтын хәрефләр белән язылган Коръән китабына лаек булганнан бирле, шәрык дөньясына да юллары ачык аның. 2006 елда Ливан, Сүрия, Мисыр дәүләтләренең 7 шәһәрендә шәхси күргәзмәләре уза. Ә 2008 елның июлендә Мәскәүдә Россиянең Чит ил эшләре министрлыгының «Росзарубежцентр» бинасында узган шәхси күргәзмәсеннән соң, каллиграфия күргәзмәсе белән килүен сорап, дөньяның 24 иленнән чакыру ала хаттат!

Асия Садыйкова җитәкләгән «Сакура» татар-япон мәдәни-мәгълүмати үзәге тарафыннан эшләнгән «Каллиграфия



тынычлык хакына» дип аталган проект шулай ук киң яклау таба. Моңа кадәр ачылмаган ишекләрне дә ачтырырга сәләтле булуын дәлилли ул. Биредә В.Попов үз эшләрен (тугра, каллиграфик композицияләр) күрсәтеп кенә калмый, бу күчмә күргәзмә үз тирәсенә төрле илләрнең хаттатларын да туплый. 2010 елда Анкарада (Төркия) башланып киткән әлеге проект Марокко, Иордания, Иран, Сүрия, Ливан, Мисыр калаларында һәм Казанда дәвам итә. Шулай итеп, Владимир Александровичка дөньякүләм танылган каллиграфлар Джозеф Чечвурд (Яңа Зеландия), Исмет Кетен (Төркия), Мөхәммәд Кармад һәм Хәссән Мегри (Марокко) үз эшләре белән килеп кушыла. Әле — үткән көздә генә әлеге проект эшен Белоруссиянең дүрт шәһәрендә — Минск, Гомель, Ивье, Витебск шәһәрләрендә дәвам итте. Бу юлы инде аларга Владимир Александровичның шәкерте, яшь каллиграф Гөлназ Исмәгыйлева да (Татарстан-Төркия) кушылды. Миссиянең әһәмияте аның исеменнән үк күренеп тора һәм ул үз сүзен үтемле итеп җиткерә килә. Бу — 18 яшеннән сугышка китеп, Владикавказны, Кубаньны, Кырым, Украина, Көнбатыш Пруссияне азат итүдә катнашып, контузияләр ала-ала, Берлингача барып җиткән солдатның тынычлык хакына әлегәчә көрәшүе. Ысулы гына башка.

— Сугыштан мин бу дөньядагы теләсә-нинди көч куллануны күрә алмас дәрәҗәгә җитеп чыктым. Шулчагында үз-үземә сүз бирдем: мондый кан коюлар кабатланмасын өчен гомер буе көрәшергә! Әгәр дә минем иҗатымны баштанаяк күзәтеп чыксагыз, сез анда Бөек Ватан сугышы темасына багышланган бер генә эш тә күрмәссез. Мин бары хезмәт батырлыклары, яңа тормыш төзү өчен барган көрәшне, сугыш вакытында җимерелгән шәһәрләрнең, авылларның яңабаштан торгызылуы, яңарышы хакында гына яздым. Графикада да шушы тема эшләремдә үтәли йөри: тынычлык, үзара тату яшәү… — ди күкрәген өч сугышчан орден һәм 15

тән артык медаль бизәгән ветеран.

Сынчылыктан кала, сәнгатьнең кулы ятардай бөтен өлкәләрендә эшләп чыгарга өлгергән рәссамның гарәби язу белән виртуозларча эш итүе әле бернәрсә, ә менә рус милләтеннән булып та, әлеге язуны 70 яшендә генә үзләштерә башлап, дөньяга танылуы — үзе бер могҗиза! Бәхетенә, янәшәсендә бу эшнең бөтен нечкәлекләрен белгән хаттат Нәҗип Нәккаш була. Эшне ул Коръән сатып алудан, рус телендәге тәрҗемәсен укып, аны өйрәнүдән башлый. Аллаһның 25 илчесе — Адәмнән башлап, Мөхәммәд пәйгамбәргә кадәр булган шәкел шул эзләнү-өйрәнүләр нәтиҗәсендә туа да. Тора-бара ачыклана, баксаң, моңа хәтта шәрык илләрендәге хаттатлар да игътибар бирмәгән булган икән. Шулай итеп, көнбатышның реалист рәссамы, эшләрен интуитив рәвештә тудыра башлый. Галимнәр, ислам белгечләре әйтүенә караганда, мөмкин булмаган эш эшләнә. Шәрыкнең элгәре еллардагы иң яхшы каллиграфия үрнәкләре көнбатыш классик сәнгатенең үрнәкләре белән кушыла. Рәссам үз иҗатында моңа кадәр аңа бөтенләй ят, әмма рухи яктан якын булган катламны ача һәм шәркый дөньяга үтеп керә. Туграларында ул гарәби язу аша сурәтләнгән кешенең холкын, аның теге яки бу ягын күрсәтергә омтыла. Нәтиҗәдә, үзенчәлекле психологик сурәт-тугра барлыкка килә.

Фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, ислам белгече Г.Балтанова В.Попов турында язганда, көнбатыш белән шәрыкне берләштерә алган Рерих, Гумилёв кебек шәхесләр белән янәшә куярлык Евразия күләмендәге фигура булып үсеп килүен ассызыклаган иде. Гомумән, рәссамның каллиграфияләрен өйрәнгән тикшерүчеләр аның әлеге юнәлешнең нигезләрен камил итеп өйрәнеп кенә калмыйча, каллиграфияне яңа техник һәм интеллектуаль баскычка, ниндидер галәми биеклеккә күтәрүен билгеләп узалар. «Эрмитаж» Дәүләт музее генераль директоры, ислам дине белгече Б.Пиотровский исә, В.Попов ислам каллиграфия сәнгатен заманча цивилизацияара аспектка алып чыкты, дип күрсәтә.

...90 яшь тулган көнне дә өендә котлаулар кабул итеп кенә утырасы итмәде Владимир Александрович. Көн кичкә авышуга, Мәскәү поездына, тимер юл вокзалына озаттык без аны. Мөфтияткә чакырганнар. Иранда узган каллиграфия һәм Коръән күргәзмәсе вакытында «беренче рус каллиграфы» хакында тапшырулар эшләргә дип, Мәскәүдән махсус Иранга барган культуролог Җәннәт Сергей Маркус каршылаган аны башкалада. Бергәләп Дәүләт тарих музеенда мәшһүр бурят сынчысы Даши Намдаковның «Күчмә кеше. Җир белән күк арасында» дигән күргәзмәсендә булганнар. Гомер буе дәрвиш урынына илләр гизгән рәссам монда да җаны теләгәнне тапкан.

P.S. *Ә юбилей күргәзмәсен — Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап киләсе елга уздырырга җыена ветеран-рәссам. Анда Владимир Поповның тулаем иҗаты да тәкъдим ителер, дип өметләник.* ■

АФӘРИН, «ИДЕЛ»!

Моннан нәкъ 25 ел элек – 1989 елның июлендә – «Идел» журналының беренче саны дөнья күрде. Хәтерләсәгез, хөрмәтле укучылар, тәүге журнал тышлыгының эчке ягына мондый сүзләр язылган иде: «КПСС Үзәк Комитеты Секретариаты, партиянең Татарстан өлкә комитеты тәкъдиме буенча, Казанда яшьләр өчен татар һәм рус телләрендә «Идел» журналы чыгара башлау турында карар кабул итте. Яңарыш чорының билгесе булган «Идел» журналы заманыбыз гамен чагылдырсын, рухи тормышыбызга ямь өстәсен, кадерле дуслар!»

«Идел» журналының беренче саны чыккач. Дус-ишләр, хезмәттәшләр вә каләмдәшләр – Идел елгасының аръягындагы тугайлыкта. 1989 ел, июль. Фото беренче тапкыр басыла.

Күпме еллар зур көрәш белән яулап алган «Идел»ебезнең тәүге саны Әмирхан Еники, Нури Арсланов кебек могтәбәр әдипләребезнең фатихасы белән ачыла. Әлеге аксакалларыбызның, шулай ук «Идел»гә бар вөҗүдләре белән хәерхаһ булган Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиев кебек күренекле каләм әһелләребезнең, журналның киләчәгенә зур өметләр баглап, тирән мәгънә салып әйткән сүзләрен бүген дә дулкынланмыйча уку мөмкин түгел.

Әмирхан ЕНИКИ: «Сабыр иткән — морадына җиткән, диләр. Ә сабырлык бездә җитәрлек. Менә дистәләрчә еллар ялварып йөри торгач, ниһаять, яшьләр журналын чыгарырга рөхсәт алдык: сугышка хәтле яшәгән «Авыл яшьләре» урынына хәзер «Идел» чыгачак.

«Идел»нең бурычлары бик зур. Бигрәк тә милли җирлегеннән аерыла башлаган яшьләребездә туган телгә мәхәббәт уяту, тарихыбызга һәм милли культурабызга аларның игътибарын көчәйтү, журналның башка күп эшләре рәтеннән, үзенә лаеклы урынны алырга тиеш».

Нури АРСЛАНОВ: «Горурланырга хакыбыз бар — татар әдәбиятының чишмә башында моннан 800 еллар чамасы элек язылган «Кыйссаи Йосыф» әсәре тора. Андый поэма, әлбәттә, буш җирдә туа алмый. Аңарчы ук безнең әдәбият булган, тик тарихның зәһәр җилләре, янгыннары аларны тараткан, юкка чыгарган.

Безнең чорларда матбугат булганда гына әдәбият үсә, ныгый ала. Шуңа күрә патша хөкүмәте теше-тырнагы белән татар басма сүзен буарга теләгән. Әмма бишенче елдан соң ул инде аны тыя алмый. Илнең төрле шәһәрләрендә татар телендә дистәләгән газета-журналлар дөньяга чыкты.

Әмма Сталин һәм аңардан соң килгән идарәчеләр, төрле сәбәпләргә сылтанып, безнең газета-журналларны яптылар. Татар халкына маңкорт кавемгә әверелү куркынычы яный башлады.

Ниһаять, яшьләр өчен чыгып килгән журналларның берсе яңадан безгә әйләнеп кайтты. Халык әйтмешли, аккан су юлын табар... Афәрин, «Идел»!»

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ: «Без егерме биш ел элек шигъри дөньяга тәпи басканда бу журнал булырга тиеш иде. Ул хакта җыелыштан — җыелышка, язучылар съездыннан съездына сүз йөрде. Безнең яшьлек шушы журналсыз ятим үсте. Ятимлекнең нәрсә икәнен яхшы беләм. Мөлдерәмә күзләребез белән бердәнбер «Казан утлары»на карап тордык. «Идел»нең кайтуы — яңа буынның эти-әниле булуы кебек вакыйга!»

Разил ВӘЛИЕВ: «Бу көнне озак, бик озак көттек без. Көттек кенә түгел, аны якынайту өчен кулдан килгән кадәр көч тә куйдык кебек... Моннан төгәл егерме ел элек, 1969 елның язында булып узган татар язучыларының VII съезды әле дә күз алдында тора. Университет тулай торагында җыелышып, без — студентлар таңга кадәр йокламыйча съезд делегатларына мөрәҗәгать яздык. Үтенечебез дә, таләбебез дә бары тик бер — яшьләр журналы ачу иде.

Ахыры нәрсә белән бетте, дисезме? Нәрсә булсын, икенче көнне үк һәммәбезне аерым-аерым чакырып «мунча керттеләр», укудан куу белән янадылар. Ә без беркавем аптырап-югалып тордык та, һушыбызга килгәч, тагын үзебезнекен тәкрарларга тотындык.

«Идел» журналы бик озак көттереп, бик зур газаплар белән дөньяга килде. Шуңа күрә ул безгә аерата кадерле дә. Әдәбият ишеген шакучы яшьләр «Иделйорт»ка изге ният, саф күңел, олы максат белән генә аяк бассыннар, аның кадерен тагын да арттырсыннар иде».

Фәиз ЗӨЛКАРНӘЙ*,
ЯҢА ДӘВЕР БЕЗДӘН ЯҢА ЭШЛӘР КӨТӘ

Озак еллар аранда ябылып яткан атларны күргәнегез бармы? Капканы ачып куйсаң да, чыгып китәргә җөрьәт итмичә, бер почмакта өерелеп тора алар. Ябык капканы бәреп ачып чыгып

китү турында сүз булырга да мөмкин түгел.

Әмма берәр гаярь тай табылып, хәвефле ирек кочагына атылса — бөтенесе ябырылып аңа иярер, тагылган кебек шуның артыннан йөгерер.

Мин атлар турында сөйләмим, мин татар матбугаты турында сөйлим.

1989 елда, әнә шундый гаярь тай сыман, «Идел» журналы торгынлык заманасыннан калган аран киртәләрен бәреп чыкты да, хакыйкать менә бу тарафта ул дигәндәй, тарих каршысына томырылды...

Яңа дәвер бездән яңа эшләр көтә.

«Идел»нең яңа дәвердәге төп максатлары:

— иҗтимагый фикердә, гуманитар фәннәрдә яңа алымнар, караш, идеяләр булдыру эшенә җигелү;

— дөньяга яңача караучы, фикерләүче яшь иҗатчылар, галимнәр, идарәчеләр — милләтнең яңа төр элитасын үстерүгә булышлык итү;

— татар халкының менталитетын үзгәртү, аны коллык сыйфатларыннан арындыра бару сыман гаять авыр эшкә өлеш кертү.

Әйе, Империянең авыр диварлары — коллык баскан татарны. Үзенең нинди йөк күтәреп торуын да белмәс хәлдә ул. Алып ташлыйк ул коллык ташларын.

Без эшләмәсәк, бу эшне кем эшләр?

(«Идел» һәм татар милләте», «Идел», № 7, 1994)

*Фәиз Зөлкарнәй (1951-1997) — шагыйрь, тәнкыйтьче, әдәбият белгече һәм мөхәррир, 1990 ел ахырыннан вафатына кадәр (18 июль,1997 ел) «Идел» журналының баш мөхәррире булып эшләде. Авторның язмасы кыскартып бирелә. *(Ред. искәрмәсе.)*

Ләбиб ЛЕРОН

БЕЗ «ИДЕЛ»ДӘН ЧЫКТЫК, «ИДЕЛ»ДӘН!

(«Идел» журналының тәүге саны басылуга 25 ел тулу уңае илә)

Каршысына килеп, рәхмәт әйтеп,
Мин «Идел»гә башым иялам.
Күп кардәшем, каләмдәшем кебек:
— Мин «Идел»дән чыктым! —
диялам...

Әле кайчан гына яп-яшь идек —
Бәйге томкан тайлардан идек,
Зәйдуллалар, Зөлкарнәйләр* белән
Бер «Идел»дә кайнаган идек!

Шигырь арты шигырь язылган чак,
Бәхәс арты бәхәс туган мәл...
Без заманны селтәп орган вакыт,
Дөнья безне арттан куган мәл!

«Ил! Тел!» — диеп оран салган еллар,
«Азатлык!» дип аваз биргән чор...
...Ирек даулап йөргән ул көннәрнең
Сурәтләре җанга иңгән чор!

Иделләрне күпме кичтек икән,
Колачладык күпме суларын?! —
Дулкыннарын кочтык ничә тапкыр...
Истән чыкмый менә шулары!

Без «Идел»дә кайнап-шаулап үстек,
Без «Идел»дән күчтек — Ил-көнгә...
Бүген менә мин «Идел»гә килдем,
Баш ияргә килдем «Идел»гә!

Минем кебек, безнең кебек шулай
Кабат-кабат яшьләр килсеннәр:
Еллар түгел, хәтта чорлар үткәч,
«Без «Идел»дән чыктык!», дисеннәр...
Безнең кебек яшьнәп йөрсеннәр!

29 июнь, 2014 ел

Римзил ВӘЛИЕВ,
«Идел» журналының беренче баш мөхәррире

БУЫННАР ЧЫЛБЫРЫН ЯЛГАУЧЫ БАСМА

Һәр заманның үзе тудырган басмалары, мәдәни ачышлары була. Әлбәттә, электән чыгып килүче газит-журналлар да яңа шартларда үзгәреп яши ала. Ләкин барыбер һәр чорның кайгы-шатлыкларын, хыял-өметләрен чагылдыручы иҗат төркемнәре, милли басмалар тарихка үз сүзләре белән керә. «Нур», «Шура», «Әль-Ислах», «Яшен», «Ялт-Йолт» басмаларының һәркайсы тулы бер чорны, мөһим темаларны һәм атаклы шәхесләрне чагылдыра.

«Идел» журналының чыга башлавы татар җәмгыятендә яңа мәдәни процессларга юл ачты. Үзенә күрә кызык заман иде ул. Милли үсеш-күтәрелешнең кайнап торган чагы. Азатлыкка, яңа сүзгә, яңа көнгә сусау көчле иде. Озак еллар торгынлык бакчасында бикләнеп яшәгәнлектән, яңа тормыш, яңалык үзе бик кызыклы иде. Үзәк матбугатта һәм «Агитатор

*«Зәйдуллалар, Зөлкарнәйләр» дигәндә, Ркаил Зәйдулла белән Газинур Морат һәм агалы-энеле Фәиз белән Ләис Зөлкарнәйләр күздә тотыла. *(Автор искәрмәсе.)*

блокноты»нда эшләп килгәннән соң, мин кайнар канлы һәм максималист милли яшьләр арасына килеп эләктем. Ә эштә, иҗади мөнәсәбәтләрдә кемнең кем икәнлеге бик тиз ачыла. Иҗат яшьләренең социаль-әхлакый йөзен якыннан өйрәнү үзе бер дөнья булды.

«Идел»дә эшләвем белән горурланам, аның өчен шатланып һәм борчылып яшим. Безнең буын менә шушы басмада эшләп, газетаның журналдан, журналның китаптан аермасын аңларга өйрәнде.

«Идел» ул һәрвакыт алга таба ага. Артка юл юк!

Марат ЗАКИР,
1993-2001 елларда «Идел» журналының бүлек мөхәррире

ТАНСЫК ЖУРНАЛ

Совет гаскәрләренең Әфганстандагы чикләнгән контингенты 1989 елның февралендә илгә чыгарылды. Безнең, ягъни «Әфган»нан чыккан соңгы «призыв»ның әле 7-8 ай чамасы армиядә хезмәт итеп бетерәсе бар иде. Ленинградка (хәзер — Санкт-Петербург)

эләктем. Озакламый оборона министры, махсус фәрман чыгарып, минем кебек «әфган»чыларны кыска вакытлы ялга җибәрде.

Казан, педагогия институтының тулай торагы, туган як, туганнар, сөйгән яр... — ике атналык ял, комга сеңгән судай, күз ачып йомганчы юкка да чыкты...

1989 елның июле иде бу — зыялы Казан гөр килә! — «Идел» журналының беренче саны дөнья күргән! Шуны кулга төшерү нияте белән, редакциягә юл тоттым. Биредә эшләүче Фәиз Зөлкарнәев, Газинур Моратов, Ркаил Зәйдуллиннар белән хәтта кул биреп күрешкән кеше ләбаса мин! Өстәвенә, мәктәптә укыганда Фәиз абый белән хатлар алыштык, беренче шигырь вә хикәяләремне дә «Ялкын»да ул дөньяга чыгарды... Озын сүзнең кыскасы шул: Фәиз абый миңа: «Менә, синең бәхеткә генә калган икән, соңгысы», — дип журнал бирде... Кош тоткандай сөенеп, вокзалга «очтым», чөнки поезд кузгалырга санаулы вакыт калган иде...

...«Идел» полкташ татар егетләре арасында кулдан-кулга йөрде. Күрше полклардан да: «Ике генә сәгатькә» — дип укырга сорап торалар иде. Һәм, шулай итеп, көннәрдән-беркөнне журналым... юкка да чыкты.

Мөгаен, «Идел»нең беренче саны Ленинградка иң әүвәле минем белән барып ирешкәндер дә әле. Кем белә?..

30 июнь, 2014 ел

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН,
«Идел» журналының баш мөхәррире

ҮЗЕБЕЗНЕҢ «ИДЕЛ» БИТ УЛ!

«И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел буе имин йорт...
Кендек каным тамган йорт...»
(«Идегәй» дастаны)

Туган ил, газиз елга... Адәм баласын гомере буе мәңгелек җирсү озата бара. Кендек каның тамган җирдән — дәүләтең, милләтең, нәселең, гаиләңнән дә газиз нәрсә була алмый. Нәкъ менә шуңа да элек-электән безнең милләтнең, Идел-йортның туендыручысы да, озатып калучысы, каршы алучысы, көрештерүчесе һәм аның шатлык-куанычларына, кайгысагышларына шаһит булган Идел дә — хөрмәт белән телгә алына, исеме әсәрләргә керә, җырларда җырлана... «Идел» альманахы, «Идел» журналы дөньяга килү дә — әнә шул Идел йортны, Идел-дәрьяны олылау, үткәннәргә хөрмәт, киләчәккә өмет билгесе ул. Татарның яшь талантларын дөньяга чыгару, аларны милләттәшләребезгә генә түгел, дөнья күләмендә таныту, шушы сәләтле яшьләргә төрле яклап ярдәм итү — төп максатын шулай билгеләгән журнал инде егерме биш ел кыйбласына тугры калып, милли җанлы укучыларны сөендерүен дәвам итә. Киләчәк елларда да Идел-йортта иминлек хөкем сөрүен, мәгърур Идел елгасының саекмавын, «Идел» журналының нәүбәттәге саннары чыгуын телик!

Үзебезнең «Идел» бит ул!

1июль, 2014 ел ■

«Идел» журналы редакциясенең бүгенге коллективы. Сулдан уңга: Альбина Гомәрова, Рөстәм Галиуллин, Галина Зәйнуллина, Гөлназ Мөхәммәтгалиева, Наил Ишмөхәммәтов, Алмаз Минһаҗев, Рузия Сафиуллина, Рәйсә Борһаниева, Вәсилә Гыйматдинова, Рүзәл Мөхәммәтшин, Энҗе Басыйрова, Ландыш Заһретдинова

ЮРИСТ КИҢӘШЕ

Хөрмәтле редакция! Мин бик четерекле ситуациягә очрадым. Әниебез үлгәнгә тиздән ярты ел булачак. Әниебезнең Казан шәһәрендә өч бүлмәле фатиры һәм Осиново бистәсендә бакчасы бар иде. Без гаиләдә ике бала — мин һәм кече сеңлем. Соңгы вакытта чирле әнине Фәридә сеңлем карады. Әни белән безнең аралар соңгы елларда бик суынган иде, бәлки, үпкәләткән чакларым да булгандыр. Әнинең кырыкларын уздыргач, Фәридә әни язып калдырган васыятьнамәне күрсәтте. Әнинең бар булган милке сеңлемә калдырылган, дип күрсәтелгән анда. Мин әнидән соң калган милекне без сеңлем белән тыныч кына тигез итеп бүлербез, дип уйлаган идем. Ул бакча йорты заманында минем куллар белән торгызылган иде, ләбаса. Аннары әнинең соңгы елларда зиһене дә тарала башлаган иде, хәтерен югалта иде, гомумән, 90 яшьлек карчык шундый васыять кәгазен үзе яза алмас иде, бу сеңлем кулы белән эшләнгән эш. Мин судка мөрәҗәгать итәргә ниятлим. Суд аркылы бу мәсьәләне ничек хәл итеп була? Ярдәм итсәгез иде....

Фәрит Йосыпов,
Казан-Әлмәт.



Сорауларга юридик фәннәр кандидаты Таңсылу САБИРОВА җавап бирә:

— Хөрмәтле Фәрит әфәнде! Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында милекне мирас итеп алуның ике төре каралган — васыятьнамә буенча һәм закон буенча мирас итеп алу (1111 маддә). Әниегез васыятьнамә язып калдырмаган булса, дөрестән дә, әниегездән калган милекне сез сеңлегез белән бертигез өлешләрдә кабул итеп ала алыр идегез. Әмма нотариуста тиешле рәвештә теркәлгән васыятьнамә бар икән, мирас әлеге кәгазьдә теркәлгәнчә бүленергә тиеш. Әмма хатыгыздан күренгәнчә, әлеге васыятьнамәнең әниегез тарафыннан үз иреге белән язылуына сезнең шигегез бар, аны сеңлегез ялгыштырган дип саныйсыз, димәк. Бу очракта, мәсьәләне хәл итүнең бердәнбер юлы — судка мөрәҗәгать итү. Һәм моның өчен судка васыятьнамәне яраксыз килешү дип тану турындагы гариза язарга кирәк булачак.

Васыятьнамә — беряклы килешү дип санала. Димәк, васыятьнамәгә дә законда яраксыз килешү турындагы гомум нормалар кагыла. Аннан тыш, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында суд тарафыннан васыятьнамәне яраксыз килешү дип тану турындагы маддәне күздә тотарга кирәк (1131 маддә). Шулай ук сезнең очракта васыятьнамәне яраксыз килешү дип тану турындагы гариза язганда РФ Гражданлык кодексының 177 маддәсенә мөрәҗәгать итү дөрес булыр. Әлеге маддәдә кылган гамәлләренең мәгънәсенә төшенергә сәләтсез һәм алар белән идарә итә алмаучы затлар тарафыннан кылынган килешүләрне яраксыз дип тану турындагы норма теркәлгән.

Димәк, хөрмәтле Фәрит әфәнде, сезнең максат — судта әниегез васыятьнамәсенең әниегез ирегеннән башка язылуын исбат итү, васыятьнамәне язган вакытта әниегезнең кылган гамәлләренең мәгънәсенә төшенә алмавын дәлилләү. Сезнең сүзләрегезгә кара-

ганда, әниегезнең соңгы елларда зиһенен югалтып, хәтерен җуйган чаклары булган. Бу авыруларны дәлилләүче табиб белешмәләре яисә әниегезнең поликлиникада саклана торган медицина китабы булса, аларны, һичшиксез, судка язылган гариза белән бергә тапшырырга кирәк. Суд, үз чиратында, бу белешмәләрне өйрәнеп, хөкем карарын сезнең файдага чыгарырга мөмкин.

Бакча йортын үз кулларым белән төзедем, дидегез. Моны исбат итүче язма дәлилләр сездә, мөгаен, юктыр. Бу очракта судта шаһит күрсәтмәләре исәпкә алыначак. Йортны сезнең белән бергә төзүчеләр, сезнең әлеге эштә катнашканыгызны күргән кешеләр судта шаһит булырга мөмкин. Аларның барысын да судка шаһит буларак җәлеп итә аласыз.

Хөрмәтле Фәрит әфәнде! Бик мәшәкатьле суд процессында сезгә уңышлар телибез!

Исәнмесез, хөрмәтле редакция! Май санындагы «Мирас һәм варис»та бер сорауга җавап итеп, Сез болай дип язган идегез: «Кеше вафат булган көннән алып, аның милкен алты ай эчендә мирас итеп кабул итәргә кирәк». Абыйның вафатына — ике ел. Гаиләсе булмау сәбәпле, бөтен милке апам белән миңа калды. Абыемның мирасын — ул да булса фатирның ½ өлешен — үз исемемә яздырырга вакыт табалмыйм һаман. Закон буенча каралган срокларны уздырып, мине фатирсыз калдырырга мөмкиннәрме? Миңа кая мөрәҗәгать итеп карарга була? Үзем Чистай шәһәрендә яшим. Алдан ук зур рәхмәт Сезгә!

Гүзәл Зөбәерова, 41 яшь,
Чистай.

- Хөрмәтле Гүзәл ханым! Россия Федерациясенең 1154 маддәсенә күз салудан башлыйк: мирас ачылу көненнән (ягъни гражданин вафат булган көннән) алып, алты ай эчендә варислар тарафыннан мирас кабул ителергә тиеш. Ләкин мирасны кабул итү белән мираска кабул ителгән милекне рәсмиләштерү арасында аерма бар. Мирасны кабул итү чарасы вафат булучының яшәү урынына караган нотариуста уздырыла: тиешле документларны нотариуска тапшырып, мирас суммасыннан 1% тәшкил иткән салым түләгәннән соң, нотариус, үз чиратында, мираска хокукларыгыз теркәлгән таныкнамә бирергә тиеш. Бу чаралар, алда әйтелгәнчә, алты ай эчендә башкарылырга тиеш.

Гүзәл ханым, үз вакытында нотариустан мондый таныкнамәне алгансыз икән, борчылырга сәбәп юк. Чөнки Россия Федерациясенең Гражданлык кодексының 1152 маддәсенең 4 өлешендә каралганча, тиешле рәвештә мираска кабул ителгән милек закон буенча варисныкы дип санала. Әлеге милекне законлы рәвештә рәсмиләштерүнең (мәсәлән, фатирны теркәүнең вакытлары чикләнмәгән. Димәк, Сез теләсә кайсы вакытта абыегыздан калган фатирны үз исемегезгә яздырырга хокуклы. Моның өчен фатир урнашкан урынга караган теркәү органнарына нотариус биргән таныкнамәне, фатирга кагылышлы техник документларны тапшырырга кирәк булачак. Тиешле дәүләт салымнарын түләргә дә туры киләчәк.

Уңышлар Сезгә! ■

Редакциядән: Хөрмәтле укучылар, мираска бәйле нинди сорауларыгыз бар — языгыз, мөрәҗәгать итегез. Төпле киңәш бирергә без һәрвакыт әзер!

Мирасворд





Чыңгыз ханның өлкән улы

Озынлык үлчәү берәмлеге

1908-1909 елларда Казанда чыккан сатирик журнал

Шәрык поэзиясендә ике юллык шигырь

Иң борынгы төрки язма

...диңгез

Өй, йорт, бина (иск.)

... Каргалый

Алтын Урда шәһәре

Гаскәр (иск.)

Пистолет

Эре сырлы игәү

Х.Туфан поэмасы

Борынгы грек шагыйре

Капма-каршы мәгънәле сүзләр

Кәҗә бәтие (диал.)

Тын океандагы утрау

Хәсрәүнең сөйгәне

Гарәп хәрефе

Урта гасыр Болгар каласы

Юртак, аргамак

Дан, дәрәҗә

һәрвакыт, гел (иск.)

Кагылышлы, мөнәсәбәтле (иск.)

Борынгы әрмән каласы

Коньяк җимеше

Монгол кылычы

Алишер... (үзбәк шагыйре)

Композитор ... Френкель

Дошманнан бедән якшәмбегә кадәр

Югары мәдәнияткә ия борынгы халык

Җырчы ... Сафиуллина

Әзербайҗандагы шәһәр

Гарәпләрдә борынгы кыллы уен коралы

Җәнлек әзерләү

Грек хәрефе

Совет автомобиле

Балетмейстер ... Таһиров

Стройның, фронтның уң яки сул ягы

Нәсел «җебе»

Крепость корылмасы

Күз кабаклары читендәге төкләр

Рәис Габдулла төзеде.

6 нчы сандагы мирасворднең җаваплары

Сулдан уңга: сөлге, хан, Ра, фәс, аркан, калта, сукно, Наум, кон, уй, сфинкс, тума, Екатеринбург, кирт, әл, алафа, каек, лабаз, алпар, ар, әле, Ает, Кук, Аниш.

Өстән аска: селте, чүлмәк, ук, Лу, «Кармак», Абрек, Сафин, Атилла, Окс, ер, Азат, Лист, офорт, аел, Ани, балпан, ерак, аран, көбә, көрәш, Клаус, улҗа, Акатуй, нам, тугрик.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ / ИЮЛЬ

475 ел элек (1539)

● Мөхәммәдъяр (1497-1549) «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге») поэмасын иҗат итә.

260 ел элек (1754)

● Шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари (1754-1834) дөньяга килә.

240 ел элек (1774)

● 23 июльдә Емельян Пугачев җитәкләгән баш күтәрүчеләр гаскәре Казанны яулап ала.

150 ел элек (1864)

● 2 июльдә сәяси эшлекле, педагог, татар-башкорт халык җырларын җыеп туплаучы Гайсә Еникиев (1864-1931) дөньяга килә.

95 ел элек (1919)

● Галимҗан Ибраһимов (1887-1938), яшерен эш итү һәм дошманны өйрәнү нияте белән, махсус күрсәтмә буенча Колчак армиясе тылында разведкада йөри.

90 ел элек (1924)

● 5 июльдә композитор Аллаһияр Вәлиуллин (1924-1972) дөньяга килә.

85 ел элек (1929)

● Казандагы «Шәрык-кино» ширкате татар руханилары тормышына багышланган«Койрыклы йолдыз» исемле кинокомедия төшерүгә керешә.

75 ел элек (1939)

● «Совет әдәбияты» журналында Таҗи Гыйззәтнең«Атаклы кызлар» («Кыю кызлар») пьесасы басыла.

45 ел элек (1969)

● Италиянең күренекле балалар әдибе Джованни Родари Казанда татар әдипләре белән очраша.

25 ел элек (1989)

● Татарстан китап нәшриятында Шиһабетдин Мәрҗанинең«Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле китабы 50 мең данәдә дөнья күрә.

● «Идел» журналының беренче саны чыга.

....

ИРИК МУСИН

1966 елның 20 октябрендә Казахстанның Петропавловск шәһәрендә туа. 1991 елда Чаллы сәнгать көллиятен тәмамлый. Күп нәрсәгә остазлары Манзя Василий Петрович, Семыкин Виктор Романовичлардан өйрәнә.

«Рәсем ясарга өйрәнү һәм материалны танып белү өчен ифрат зур тырышлык таләп ителә. Шул ук вакытта рәссамның төп бурычы — уйлау сәләтен арттыру». Иҗатының башлангыч чорында ук Мәскәүдә (2010) һәм Берлинда (2011) узган халыкара конкурсларда җиңүләр яулаган Ирик Мусинның бу фикере белән кемдер килешер, кемдер — юк.

«Карт тал янында». 2011. Киндер, майлы буяу

Әмма аның эшләренә салынган уй-фикер, мәгънә тирәнлеге бераүне дә битараф калдырмас.

Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Ирик Мусинның иҗади эшләре Түбән Сынлы сәнгать музеенда, Россиядә һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

«Эскәмиядә». 2013. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

Зариф Мөэминовның Беренче Бөтендөнья сугышыннан һәм әсирлектән җибәргән хатлары, «Солдат йөрәге» исемле автобиографик повесте

Гаяз Исхакыйның моңарчы киң даирәгә билгеле булмаган, тулаем дөнья күрмәгән «Солдат» романы

Тәлгат Галиуллин. Мөһаҗирләр һәм татар шигърияте

Сәмига Сәүбанова. Җәлилнең соңгы мәхәббәте

Индекс:
Татарстанда – 54132
Чит төбәкләрдә – 70275

Икенче ярты еллыкка язылу бәясе – 420 сум
Редакциядә язылу бәясе – 319 сум

4 612750 670172